
# ШУРА

№ 49
2025



2007111458313 7

Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте

ДИНИ АЛЬМАНАХ

1908 елдан бирле нәшер ителә

# ЭЧТӘЛЕК


Җомга хотбәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4
Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9

ВӘГАЗЬЛӘР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Юлларда сак булыйк! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Коръәнне яттан өйрәнү җиңел, хәтердә саклау кыен . . . . 20
Шәригать нәрсә ул? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Үзеңә теләгәнне кардәшеңә дә телә . . . . . . . . . . . . . 29
Аллаһыга тәвәккәл кылу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Аллаһыга шөкер итү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39
Хәләл табыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
Малыбызда бәрәкәт булсын дисәк . . . . . . . . . . . . . . . 53
Мәүлид ән-Нәби . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 60
Шәригать чыганагы буларак Коръән . . . . . . . . . . . . . 65
Вакыт илә бәхет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
Экстремизм корбаны булма! . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77
Өлкәннәр белән яхшы мөгамәлә . . . . . . . . . . . . . . . . 83
Ата-ананың баласы каршындагы бурычлары . . . . . . . . . . 91

НӘРСӘ? КАЙДА? КАЙЧАН? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Март-май . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 98

**«ШУРА» дини альманах, № 49** **12+**

июль–сентябрь 2025
мөхәррам–рабигыль-ахыр 1447

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте
420021, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бушлай таратыла.
2013 елның июленнән чыга.
Басма кварталга бер тапкыр чыга.

**БАШ РЕДАКТОР:**
Хамматов Л. Г.

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Хәмидуллин Р. Ә.
Мөбарәков Б. Р.
Фәизов И. Ә.

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**МӨХӘРРИР:**
Маннанова Р. Р.

**ДИЗАЙНЕР:**
Хәйретдинов И. Р.

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Гарифуллин И. Ф.

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
Мисырда сакланып калган иң борынгы мимбәрнең сызмасы (Кус шәһәре, XII гасыр). Рәсемнең авторы Prisse d'Avennes, 1807–1879 / unsplash.com/photos/mnVAKvLKizA.

Альманах Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан республикасы буенча идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ № ТУ16-01077 номеры белән теркәлде.

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нче йорт
Тел.: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: izdat@huzur.ru
Сайт: huzur.ru

*Типографиянең адресы:*
*«Карти» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420095, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Химград территориясы, 201 нче йорт, 1006 нчы бина.*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 17.06.2025
Чыгу көне: 03.07.2025

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый.*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аятьсүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала.*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание
на татарском языке

## Җомга хотбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي هَدَانَا لِهَذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا اللهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللَّهِ۞ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللهُ۞ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ۞ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللهِ۞ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ۞ دَاعِينَا إِلَى اللهِ۞ صَلَّى اللهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ۞ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ۞ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ۞ وَعَلَى بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ۞ رِضْوَانُ اللهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللهِ! ۞ اِتَّقُوا اللهَ وَ أَطِيعُوهُ۞ إِنَّ اللهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ۞

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللَّهِ:

_______________________________ ۞

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّي اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ:

_______________________________ ۞

Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:

أَلَا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلَامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ۞ كَلَامُ اللهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللهُ تَبَارَكَ وَ تَعَالَى فِي الْكَلَامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ۞ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللهِ الْإِسْلَامُ۞

Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ۞ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:

اَلْحَمْدُ لِلّٰه حَمْدَ الْكَامِلِينَ وَالصَّلَوٰةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِينَ وَ الْآخِرِينَ۞ مُحَمَّدٍ وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ۞ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ۞ فَقَالَ عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:

إِنَّ اللهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً۞ اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞ اَللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا بَارَكْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞

اَللّٰهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ۞ سَيِّدِنَا أَبِى بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُمْ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْبَاقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللّٰهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ۞ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةَ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللّٰهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللّٰهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللّٰهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللّٰهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ[1] ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلَامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاةِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وهَوَائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:

إِنَّ اللّٰهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ۞ وَلَذِكْرُ اللّٰهِ أَكْبَرُ وَاللّٰهِ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ۞

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:**

---

1 Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин» дип әйтә.

Әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһил-ләҙии һәдәәнә лиһәәҙәә вә мәә күннәә линәһтәдийә ләү ләә эн һәдәәнәллаһ. Вә мәә тәүфиикый вәгътисаамий илләә билләәһ. Фә сүбхәәнәл-ләҙии каалә фии китәәбиһил-кәриими әстәгыйҙү билләәһи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләә эн йәшәә-әллаһ». Нәшһәдү эн ләә иләәһә илләллаһу. Вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Шәһәәдәтән мүнҗийәтән мин гаҙәбилләһи. Вә нәшһәдү әннә сәййидәнә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһү. Дәәгыыйнәә иләл-лаһи. Салләллаһу тәгаалә галәйһи вә галәә әүләәдиһи вә әзвәәҗиһи вә галәә хуләфәә-иһир-раашидиинәл мүршидиинәл мәһдиййинә мин бәгъдиһи. Вә үзәраа-иһил кәәмилиинә фии гаһдиһи. Хусуусан минһүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мү'миниинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гусмәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаһи тәгаалә галәйһим әҗмәгыйнә.

Әмма бәгъде: фә йәә гыйбәдәллаһ! Иттәкуллаһә вә әтыыйгууһу. Иннәллаһә мәгал-ләҙиинәт-тәкау, вәл-ләҙиинә һүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаһу газзә вә җәллә фии китәәбиһил кәриими әстәгыыйҙү билләһи: ____________________________________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ____________________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәгеләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмүллаһил мәликил газиизил галләәми, кәмәә каалләллаһу тәбәәракә вә тәгаалә фил-кәләәми. Вә иҙәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әнсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйҙү билләһи: «Иннәд-диинә гыйңдәллаһил Исләәм».

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мүʼминиинә вәл мүʼминәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәррраахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмин.

**Соңыннан, басып, икенче хотбә буларак, киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхаамәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә газзә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәлләҙиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати ҙәвил кадрил җәлиййи вәш-шәрафил галиййи сәййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гусмәәнә вә Галиййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мүкәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлииләйнис сәгыыйдәйни әш-шәһиидәйни сәййидинәл Хәсәни вә сәййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мүʼминиинә вәл мүʼминәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл

әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин[1]. Вәхҙүл мән хәҙәләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфириинә вәл мүкыыймиинә вәл хәәдыйриинә вәл гаа-ибиинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

«Иннәллаһә йә’мүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и ҙил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәҙәккәруун. Вәләҙикруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгуун».

## Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:

Безне туры юлга күндергән Аллаһыга мактау булсын.[2] Аннан башка безне берәү дә (туры юлга) күндерә алмый.

Коръәни Кәримдә: **«Әмма Аллаһы теләми торып, сез тели алмас-сыз. Һичшиксез, Аллаһы – Белүче, Хикмәт иясе»**, – дип әйтүче Аллаһы – барлык кимчелекләрдән дә Пакь.

Без бердәнбер булган Аллаһыдан башка илаһның юклыгына һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аның Расүле һәм колы булуына шаһитлык итәбез. Без Пәйгамбәребез, аның балалары, хатыннары,

---

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин» дип әйтә.

[2] 3 тапкыр әйтелә.

элек яшәп киткән изгеләребез һәм һидаять юлында булган һәркем өчен, Аллаһының рәхмәтен сорыйбыз.

Һәм аның турыдан-туры хәлифәләре – мөэминнәрнең хакимнәренә: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәдән Аллаһы риза булсын. Кыямәт көнендә барлык пәйгамбәрләргә һәм табигыйннәргә Аллаһының ризалыгы һәм рәхмәте булсын.

Моннан соң Аллаһыга гыйбадәт кылучылар Аңа итагать итсен.

> **«Һичшиксез, Аллаһы –** [гөнаһлардан] **курыккан һәм** [Раббыларының ризалыгын гына өмет итеп] **игелекле гамәлләр кылган кешеләр белән».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:128

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: ____________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: ______________________________________________________________

**Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:**

Дөреслектә, иң дөрес һәм төзек сөйләм – ул Аллаһының Сөйләме. Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйтүенчә:

> **«Коръән укылган чакта, аны тыңлагыз һәм дәшми торыгыз, – бәлки, сез** [Аллаһы тарафыннан] **рәхмәт ителерсез»;**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:204

> **«Һичшиксез, Аллаһы хозурында** [хакыйкый һәм кабул ителгән] **дин – Ислам** [дине генә]**».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:19

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.**

Без Аллаһыдан барыбыз өчен дә рәхмәтен иңдерүен сорыйбыз. Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәм ике дөньяда да булачак. Син – Ишетүче, Якын һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы. Пәйгамбәрләргә сәламнәр һәм Аллаһының рәхмәте булсын. Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһыга мактаулар булсын.

**Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:**

Аллаһыга мактаулар, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм аңа иярүчеләргә сәламнәребез һәм Аллаһының рәхмәте булсын.

Аллаһы Тәгалә Изге Китабыбызда әйткәнчә:

> **«Һичшиксез, Аллаһы һәм фәрештәләре Нәби салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтәләр. Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм** [«Ий, Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] **сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:56

Йә, Аллаһы, тугры хәлифәләр: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәгә һәм җәннәт белән шатландырылган алты сәхабәгә, Расүлебезнең югары дәрәҗәдә булган абыйлары – Хәмзә бине Габделмотталиб һәм Габбас бине Габделмотталибка, шәһит булып киткән сөекле оныклары Хәсән белән Хөсәенгә рәхмәтеңне иңдер. Сәхабәләр һәм табигыйннәр өчен Кыямәт көнендә Аллаһының рәхмәтен, ризалыгын ирештер.

Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәмең ике дөньяда да булачак. Дөреслектә, Син – догаларыбызны Ишетүче һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы!

Йә, Аллаһы, динебез Исламга ярдәм итүчеләргә Син дә ярдәм ит (өч тапкыр әйтелә). Мөэминнәрне җәберләүчеләрне көчсезләндер. Безгә, галимнәргә, юлчыларга, исәннәргә һәм үлеләргә – пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәтенә тынычлык һәм тәртип билгелә.

**Иң соңыннан, «Әгуүҙү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

> **«Һичшиксез, Аллаһы** [һәрнәрсәне аңлатыр өчен, индергән китабында] **гадел булырга, изгелек кылырга һәм** [бигрәк тә] **якын туганнарга** [мохтаҗ булган нәрсәләрен] **бирергә** [һәм туганлык җепләрен ныгытуны] **әмер итә.** [Зина кебек] **Фәхешлектән,** [көферлек, ширек һәм шуның кебек дин кабул итмәгән] **тыелганнан һәм** [кешеләргә] **җәберзолым кылудан тыя. Сез акылга килерсез дип, сезне үгетли».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:90

Аллаһыны зикер итегез. Хакыйкатьтә, Ул сезнең ни кылганнарыгызны белә.

# Вәгазьләр

*4 июль вәгазе,*

*мөхәррам аеның 9 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Юлларда сак булыйк!

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Раббыбыз бер һәм Ул – Аллаһы! Расүлебез – Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм! Игътикадыбыз – Аллаһыдан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк һәм Мөхәммәд – Аның хак расүле һәм илсече икәненә шәһадәт китерәбез. Имам әт-Тахавий үзенең «Гакыйдә» китабында: «Аллаһы Тәгалә – Бар кылучы, Барлыкка китерүче, һәм Аның бу исем-сыйфаты әле дөньяда берни дә булмаганда, берәр мәхлук булганчы ук бар иде. Ул – бер әйбер дә булмаганда ук Барлыкка китерүче», – дип яза.

Чыннан да, без – Раббыбыз барлыкка китергән затлар гына. Һәм без бер секунд та Аллаһысыз яши алмыйбыз. Ул безне бер мизгелгә дә Үзенең игътибарыннан, тәрбиясеннән калдырмый. Әлхәмдүлилләһ! Һәрвакыт, нинди генә хәлдә булса да, мөселман моны истә тотарга тиеш. Эштәме син, өйдәме, машина йөртәсеңме, җәяү йөрисеңме, ятып торасың яки йөгерәсеңме, изгелектә яки гөнаһлы юлдасыңмы – бу дөньяда Раббыбыз Аллаһыдан яшеренеп, качып булмый! Шуңа күрә, даими рәвештә Бөек Аллаһыдан ярдәм һәм рәхимлелек сорыйк. Ул – һәр яхшылыкның чыганагы һәм һәр явызлыктан саклаучы.

Хөрмәтле мөселман кардәшләрем! Бүген без үзебезнең куркынычсызлыгыбыз турында сөйләшербез. Ул теманы төрле яклап ачыкларга тырышырбыз. Бу җомгага кемдер җәяү, кемдер велосипедта, кемдер машинада, автобуста килгәндер. Без һәр мизгелдә Раббыбызга мохтаҗ, дип әйттек. Транспортка утыргач, кайсыбыз:

اَللّٰهُمَّ اَنْزِلْنِى مُنْزَلًا مُبَارَكًا وَ أَنْتَ خَيرُ الْمُنْزِلِينَ

«Аллаһүммә, әнзилнии мүнзәлән мүбәәракән вә әнтә хайрүл-мүнзилиин», ягъни: «Ий Аллаһым! Мине мөбарәк урынга ирештер, чөнки Син – иң яхшы урнаштыручысың», – дигән доганы укыды? Яки машинага утырганда «Бисмилләһ» әйтеп, «Аятел-Көрсине» өч, биш яки җиде тапкыр укып юлга чыкты?

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм юлга чыкканда болай дога кыла торган булган: «Ий Аллаһым! Сиңа таба юнәлдем һәм Синең ярдәмеңә таянам. Ий Аллаһым! Миңа тәкъвалык бир, гөнаһларымны гафу ит һәм, кайсы якка борылсам да, мине изге эшләргә юнәлт». Шулай ук, «Бисмилләһ» әйтеп, болай дияргә була:

سُبْحَانَ الَّذِي سَخَّرَ لَنَا هَٰذَا وَمَا كُنَّا لَهُ مُقْرِنِينَ

**«Моны безгә буйсындырган Зат** [барча кимчелек сыйфатлардан ерак һәм] **пакь. Безнең моңа көчебез җитмәс иде».**

«Әз-Зүхруф / Зиннәтләнү», 43:13

Ислам дине кешеләрнең тереклеген, сәламәтлеген һәм җәмгыятьтә тәртипне саклауга чакыра. Шуңа да, юлга чыгар алдыннан, машинагызны тикшерегез. Бу – Аллаһының нигъмәте, аны сакларга кирәк. Бар да яхшы икәненә инангач, Аллаһыга тәвәккәл кылып, кузгалырга була. Ни өчен шулаймы? Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Башта дөяңне бәйләп куй, аннан соң тәвәккәл кылырсың», – дип әйткән. Башта бөтен әйбергә сәбәбен кыл, шуннан соң «Аллаһыга тапшырдым, ахырын хәерле кыл» дип, эшкә керешергә була.

Икенче мәсьәлә – юлда тәртипле булу! Бу да Аллаһыга итагать итүнең бер төре. Ислам дине юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуны тыя, чөнки алар кешеләрнең тереклеген һәм мал-мөлкәтен сакларга ярдәм итә. Боларга салкын карау, светофорның кызыл яки яшел төсләренә игътибар итмәү – үзегезгә

дә, башкаларга да зур куркынычлык тудыра. Бер тапкыр, ләкин мәңгелеккә ялгышып була! Шуны онытмасак иде.

Шәригать белгечләре мөселман кешесенә юл кагыйдәләрен үтәү тиешле дип әйтәләр, чөнки алар кешеләрнең иминлеген, сәламәтлеген һәм транспорт чараларын саклауны тәэмин итә. Динебез кеше гомеренең әһәмиятен һәм башкаларга зарар китерүнең никадәр зур золымлык икәнен ассызыклый, шуңа күрә әлеге кагыйдәләрне саклау – мөселманның бурычы. Шуңа күрә, бик каты ашыксагыз да, каядыр соңга калсагыз да, тизлекне арттырганчы, юл билгеләрен бозганчы, уйлагыз: башкаларның сәламәтлеген куркыныч астына куясыгыз киләме сезнең?!

Мөселман үзенә дә, башкаларга да зыян китерергә тиеш түгел! ПДД, ягъни юлда йөрү кагыйдәләрен, бозу – хокукый җаваплылык кына түгел, ә кешеләргә зыян китергән очракта – Аллаһы алдында гөнаһка керү дә. Онытмыйк: мөселман кешесе кануннарны бозганда ике тапкыр җавап бирә: дөньяда – ил кануннары буенча; ә Кыямәт көнендә Аллаһы алдында сорау булачак.

Шәригать кешеләрнең иминлеге өчен җаваплылыкны ассызыклый. Коръән һәм хәдисләр башкаларга зыян китерүнең гөнаһ икәнлеген күрсәтә, моңа игътибарсызлык яки юл кагыйдәләрен бозу нәтиҗәсендәге аварияләр дә керә.

Ислам галимнәре мөселманнарның, мөселман булмаган илләрдә яшәгәндә, шул илләрнең кануннарын бозуга хокукы юклыгын ассызыклый. Ислам нормалары буенча, юллар, парклар кебек җәмгыяви урыннар башкаларга зыян китермичә генә файдаланылырга тиеш. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Зыян китерү дә, зыянга җавап итеп зыян китерү дә ярамый», – дип әйтеп калдырган.

Әлбәттә, вәгазебезне без мәчеткә машина белән дә, җәяү дә килдек, дип башладык. Юл кагыйдәләрен үтәү бурычы машина йөртүчеләргә генә түгел, җәяүлеләргә дә карый. Мәсәлән, юлны дөрес кичеп чыгу: җәяүлеләр

өчен билгеләнгән урыннарда (переходлар, светофорлар) гына кичәргә ярый. Кагыйдәне бозып, машина йөртүчеләрне куркыныч астына куеп, тиешле булмаган җирдән чыкканда, юл һәлакәте китереп чыгарырга мөмкинбез. Бу очракта да нәтиҗәсе төрле була ала: үзебезнең һәлак булуыбыз яки инвалид калуыбыз бар. Ә иң мөһиме – машина йөртүчене дә бик авыр хәлгә куябыз.

Бу вәгазьне юкка гына җәй көнендә сөйләмибез. Бозлавык юк дип, чабабыз, ял итеп каласы килә дип, урманнарда учаклар ягабыз, төнгә кадәр йөрибез. Җәй – матур вакыт, ял итү, табигатьтә булу, көннәрдән ләззәт алу вакыты. Боларның һәрберсендә дә куркынычлык барлыгын онытмасак иде. Шуңа күрә һәрберебез сак булырга, уяу булырга һәм үзебезне, якыннарыбызны һәм тирә-юнебезне сакларга тиешбез.

Җәен, әлбәттә, күпләребез урманнарга ял итәргә барабыз. Ләкин шуны онытмагыз: урман – безнең байлыгыбыз, аны саклау – һәрберебезнең бурычы. Урманда булганда берничә кагыйдәне истән чыгармасак иде:

1. Урманда учак ягу тыелган булса, бу кагыйдәне бозмыйк. Учакны махсус урында ягыйк, сак булыйк, янәшәдә коры үлән булмасын. Учакны сүндерү өчен, су сибәргә яки җир белән күмәргә була.

2. Ничек кенә булмасын, арабызда тәмәке тартучылар да юк түгел. Урманда тәмәке тартмагыз, чөнки сүндерелмәгән тәмәке төпчеге зур янгынга китерергә мөмкин.

3. Урманда пыяла шешәләр калдырмагыз, кояш нурлары алар аша үтеп, ут чыгарырга мөмкин. Гомумән, инде мөселман табигатьтә булсынмы, башка урында булсынмы, үзеннән соң бернинди чүп-чар калдырырга тиеш түгел.

Шулай ук җәй – су коену, ял итү вакыты. Хөрмәтле кардәшләрем! Җәен сулыкларда коену – бик күңелле шөгыль, ләкин сулыкта коену да куркыныч булырга мөмкин. Балаларны өлкәннәрсез коендырмагыз. Һәрвакыт аларны күзәтеп торыгыз. Балаларны рөхсәт ителмәгән урыннарда, тирән сулыкларда коендырмагыз. Сулыкны пычратмагыз, чүп-чарны махсус урыннарга ташлагыз. Сулыкларны чиста тоту – ул безнең сәламәтлегебезне саклау дигән сүз.

Хөрмәтле җәмәгать! Җәй көне төнге вакытта урамда йөрү арта. Ләкин төнлә урамда җинаятьләрнең артуын да онытмаска кирәк.

Раббыбыз Аллаһы Тәгалә юкка гына болай дип әйтмәгән:

وَمِن شَرِّ غَاسِقٍ إِذَا وَقَبَ

«[Караңгылыгы һәрнәрсә өстенә төшеп] **Каплаган чакта куе караңгылык зарарыннан» (Аллаһыга сыенамын», – дип әйт»).**

«Әл-Фәләкъ / Таң алды», 113:3

Төнлә урамда ялгыз йөрмәгез. Гомумән, шәригатебез буенча кич белән йөрү кагыйдәләрен кабат искә төшерегез әле бер.

Кадерле мөселманнар! Җәй көне куркынычсызлык мәсьәләләренә җитди карасак, үзебезне дә, якыннарыбызны да төрле бәлаләрдән саклый алырбыз. Бигрәк тә, монда утырган әтиләр, бу мәсьәләне кайгыртырга тырышыгыз һәм үзегезнең хәләл җефетләрегезгә дә җиткерегез!

Транспорт чарасын йөртергә 18 яшьтән генә рөхсәт бирелә, моны онытмасак иде. Кызганыч, республикабызда ел саен 10–15 яшьлек балалар мотоцикл, самокат, питбайк кебек транспортта юл фаҗигаләренә эләгә. Нәтиҗәдә, кайсысы гомерлек күрмәс яки үз аякларында йөри алмас булып кала, ә кайсысының гомере өзелә... Балаларыбызны мондый куркыныч «уенчыклардан» саклыйк. Алар бар җаваплылыкны аңлап бетерми, моны уенчык дип кенә кабул итә шул. Әмма балаларыбыз өчен без җаваплы. Алар өчен без бу дөньяда да, ахирәт дөньясында да җавап тотабыз. Шулай ук бүгенге көндә яшьләр арасында таралган тагын бер бик начар гадәт бар. Алар интернетта аны «тренд» дип кенә атый: балалар, берәр машина килгәнен качып көтеп торып, алдыннан ук йөгереп чыгып китәргә тиешләр. Алар моны «беги или умри» уены дип атыйлар. Машинага иң якын йөгереп чыккан бала җиңүче була. Һәм моны әле алар видеога да төшереп торалар. Ишеткәнсездер, инде берничә бала шушы ахмаклык аркасында машина астына эләкте. Шуңа күрә

балаларга кирәкмәгән транспорт чаралары алмагыз, интернет челтәрендә нәрсә караганын, кем белән аралашканын тикшереп торырга тырышыгыз. Балаларыбыз белән күбрәк сөйләшик. «Минем балам андый түгел», – дип уйлап утырмагыз, бу хакта барыбер сөйләшегез, кулсыз-аяксыз кешеләрнең нинди авыр тормыш алып баруын аңлатырга тырышыгыз.

Сөйләнгән нәсыйхәтләргә колак салсагыз иде, хөрмәтле кардәшләрем. Аллаһы Тәгалә юлларда, сулыкларда һәм башка җирләрдә дә исән-имин булуыбызны насыйп итсә иде. Җәй айларыннан сәламәтлегебез, тәнебез өчен бары көч-куәт җыеп калыйк. Әмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*ТР МДНнең Дәгъват бүлеге*

*11 июль вәгазе,*

*мөхәррам аеның 16 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Коръәнне яттан өйрәнү җиңел, хәтердә саклау кыен

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Газиз дин кардәшләрем, Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

بَلْ هُوَ آيَاتٌ بَيِّنَاتٌ فِي صُدُورِ الَّذِينَ أُوتُوا الْعِلْمَ ۚ وَمَا يَجْحَدُ بِآيَاتِنَا إِلَّا الظَّالِمُونَ

«[Башка китаплардан аермалы буларак, бер өстенлеккә ия булган] **Ул** [Коръән] **– гыйлем бирелгән** [хафиз һәм галим] **кешеләрнең күкрәкләрендә булган ап-ачык аятьләр.** [Шул сәбәпле ул үзгәртелүгә дучар ителә алмый. Башка китаплар исә, кәгазьләрдән генә укылганнары өчен, бик җиңел үзгәртелә алганнар]. **Безнең аятьләребезне залимнәр генә инкяр итә».**

«Әл-Ганкәбут / Үрмәкүч», 29:49

Аллаһы Тәгалә дин тотучыларның күкрәкләрен ачып, уку вакытында хакыйкатьне кабул итү өчен, Коръәни Кәримне ятлауны шушы өммәт өчен җиңеләйтте.

وَلَقَدْ يَسَّرْنَا الْقُرْآنَ لِلذِّكْرِ فَهَلْ مِن مُّدَّكِرٍ

**«Без Коръәнне үгет алынсын дип бик җиңел иттек, ләкин үгет алучылар бармы?»**

«Әл-Камәр / Ай», 54:22

Мәшһүр табигыйн, галим, имам Катадә бине Дигамә хәзрәтләре болай дип әйткән булган: «Сезгә кадәр яшәгән кавемнәр изге сүзләрне китаптан укыдылар, әгәр аларның үзләре белән китаплары булмаса, алар аны укый алмадылар, чөнки яттан белмиләр иде. Аллаһы Тәгалә безнең өммәткә бүтәннәргә бирмәгәнне биргән – ул Коръәнне саклауны».

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Коръән аятьләре иңгәч, ул аларны сәхабәләргә укып барган, алар исә аятьләрне ятлап, истә калдырганнар яки язып алганнар. Аннан соң бу сәхабәләр әлеге аятьләрне якыннарына, бүтән сәхабәләргә өйрәткәннәр. Шулай итеп Коръәни Кәрим язуда һәм хәтердә сакланып, телдән телгә һәм язма рәвештә дә таратылган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үлгәннән соң, Коръән аятьләре бер китап рәвешендә җыелган, без аны Коръән мосхафы дибез.

Имам Әбү Хәсән әл-Мәвәрди (Аллаһының рәхмәтендә булсын) билгеләп узганча: «Коръәннең могҗизаларының берсе, кешеләрнең кайсы телдә сөйләшүләренә бәйсез рәвештә, аның бар кеше өчен дә җиңел ятлануыннан гыйбарәт. Бер генә китап та Коръән ятланган кебек ятланмый. Бу – аңа Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән үзенчәлек, Ул аны шуның белән башка китаплардан аерып тора». Дөрестән дә, бүгенге көндә дә күрәбез: күпме кешеләр, гарәп телен белмәсәләр дә, Коръәнне яттан беләләр.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Коръән укуның, өйрәнүнең һәм ятлауның әһәмияте, файдасы хакында бик күп сөйләгән. Мәсәлән: «Коръән укыгыз, чынлыкта, Кыямәт көнендә ул аны укыган кешеләр өчен яклаучы булыр»[1].

Аллаһы Тәгалә Коръәнне яттан белүчеләрне бу дөньда да, ахирәттә дә бөек дәрәҗәләргә күтәрә. Бу бөек дәрәҗәләр Коръәнне өйрәнгән кешегә генә

[1] Имам Мөслим.

түгел, шундый ук бүләк Кыямәт көнендә аның әти-әниләренә дә булачак, чөнки алар, көчләрен кызганмыйча, үз балаларын Коръәнне укырга, ятларга дәртләндереп тәрбияләгәннәр. Бу хакта хәдистә әйтелә: «Коръәнне укыган һәм аның белән гамәл кылган кешенең ата-анасына Кыямәт көнендә таҗ киертелер. Шул таҗның нуры кояш нурларыннан да яктырак булыр. Шулай булгач, бу кешенең үзе хакында ни уйлыйсыз (ягъни аның үзенә нинди нигъмәтләр бирелер соң)?»[1]

Сәхабәләр, аларның хатыннары һәм балалары да Коръәнне ятлауга бик зур игътибар бирә торган булган, аны төнге намазларында күп итеп укыганнар. Һәм сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, сәхабәләрнең йортлары янынннан үткәндә, аларның Коръән укыган тавышларын ишетеп, тыңлап тора торган булган.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Көнчелек ике очракта гына рөхсәт ителә: Коръәнне яттан өйрәнеп, үзен аны көне-төне укуга багышлаучы ир кешегә карата һәм Аллаһы Тәгалә биргән малын көне-төне дин юлында таратучы ир кешегә карата», – дип әйткән[2].

Янә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Коръән – ул бәйләми калдырылган дөя кебек. Дөяне бәйләп куймасаң, ул кача, Коръәнне укып кабатлап тормасаң, аны онытасың»[3].

Коръәни Кәримне ятлау аны һәрвакыт укып һәм кабатлап торган кешегә җиңелрәк бирелә. Әгәр кеше сирәк укыса, ятлаганын кабатламаса, аны өйрәнү авыр булып тоелачак, һәм ятлаган сүрәләр дә тиз онытылырга мөмкин, ә Коръәнне оныту гөнаһ саналырга мөмкин. Гәрчә даими кабатлау онытмау өчен иң яхшы ысул булып торса да, оныту кабатлап тормаган очракта гына булмый. Оныту ике төрле була:

1 Имам Әбү Давыд.

2 Имам әл-Бохари.

3 Имам Мөслим.

1. Кеше калебенең дөньяга нык бәйләнгәне сәбәпле, Коръәни Кәримне укуга һәм кабатлауга игътибарсызлык итүгә китерүе. Онытуның шушы төре тәнкыйтьләнә.

2. Кешенең аз укуы һәм кабатламавы сәбәпле түгел, ә картаю, зиһеннең начараюы һ. б. сәбәпләр белән оныту.

Коръән өйрәнүнең әһәмиятен ассызыклап, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Коръәннең бер генә хәрефе дә булмаган кеше җимерелгән өйгә тиң»[1]. Ягъни, Коръәнне өйрәнмәгән, аның белән гамәл кылмаган кешенең йөрәген Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм еланнар, чаяннар белән тулган җимерелгән өй белән чагыштыра.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Фәнил хәзрәт Закиров,*

*Балтач районы Сосна авылы мәчетенең имам-хатыйбы*

[1] Имам әт-Тирмизи.

*18 июль вәгазе,*

*мөхәррам аеның 23 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Шәригать нәрсә ул?

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Хөрмәтле мөселманнар! Бүген җомга намазына дип җыелдык. Мәчеткә килгәнче, намаз укырга кирәклеген белеп, тәһарәтләндек, кемдер госел алып килде. Мәчеткә кергәндә, уң аяк белән кереп, кирәкле догаларны укып, матур гына азанны көтеп утырдык. Аннары, азаннан соң, бөтенебез торып дүрт рәкәгать сөннәт укып, кабаттан азан әйтеп, менә, инде вәгазь тыңлый башладык. Уйланыйк әле: бу гамәлләрне без кайдан белеп шул рәвешле эшлибез? Ни өчен шундый тәртип, ни өчен шундый гамәлләр? Ә кем безгә шушы укыган намазыбызны өйрәтте? Ни өчен аларны шулай укыйбыз? Намаз эчендә шундый-шундый сүзләр кулланабыз? Болар бөтенесе дә безнең фикһ, ягъни Ислам хокукы, Ислам шәригате фәнендә өйрәнелә.

Без, чыннан да, көн саен кыла торган гыйбадәтләребезнең ни өчен нәкъ менә шулай кылынганын уйлаган бармы икән? Ягъни, ничек кылынганын гына түгел, ни өчен нәкъ менә шулай кылынганын уйлаган бармы? Һәм ни өчен кайбер башка җирләрдә намаз уку рәвеше аерылып тора, кайбер җирләрдә корбан чалу вәҗиб түгел икән һәм башка мәсьәләләр турында уйлап караган бардыр. Болар барысы да Ислам диненең тарихына, һәм бигрәк тә шушы өлкәне өйрәнә торган фәннәргә кайтып кала. Бу очракта Ислам шәригате тарихы фәне күз алдында тотыла. Шәригать дип күп әйтергә, күп ишетергә туры киләдер. Ә нәрсә соң ул шәригать? «Әт-Тәшригъ» сүзе

«шәррагә» фигыленнән ясалган мәсдар булып тора, ул үзе «әш-шәригаһ» сүзеннән алынган. «Әш-шәригаһ» сүзенең берничә мәгънәсе бар. Һәм беренчесе – туры юл. Мәсәлән, Раббыбыз болай дип әйтә:

ثُمَّ جَعَلْنَاكَ عَلَىٰ شَرِيعَةٍ مِّنَ الْأَمْرِ فَاتَّبِعْهَا

**«Шуннан соң Без сине** [дингә кагылышлы] **эштә бер шәригатькә** [илаһи бер юлга] **урнаштырдык. Син шуңа ияр...»**

«Әл-Җәсия / Тезләнеп торучылар», 45:18

«Шәригать» дип динебездәге кануннарны, дини кагыйдәләрне атыйбыз. Раббыбыз Аллаһы бу сүзне Коръәндә дә шушы мәгънәдә китерә:

شَرَعَ لَكُم مِّنَ الدِّينِ مَا وَصَّىٰ بِهِ نُوحًا وَالَّذِي أَوْحَيْنَا إِلَيْكَ وَمَا وَصَّيْنَا بِهِ إِبْرَاهِيمَ وَمُوسَىٰ وَعِيسَىٰ ۖ أَنْ أَقِيمُوا الدِّينَ وَلَا تَتَفَرَّقُوا فِيهِ ۚ

**«**[Исламда яшәп, һәм ялгышлыкның үзенә юл табуына мөмкинлек бирмичә] **Динне тотыгыз һәм** [кайсыгыз иман китереп, кайсыгыз инкяр итеп] **анда аерылмагыз!» – дип, Нухка** [галәйһиссәлам] **васыять иткән нәрсәне дә, Без сиңа вәхи иткән нәрсәне дә, Без Ибраһимга, Мусага һәм Гайсәгә** [галәйһимүссәлам] **әмер иткән нәрсәне дә Ул сезгә дә дин итте».**

«Әш-Шура / Киңәш», 42:13

«Шәрага ләкүм», ягъни «Ул сезгә канун буларак билгеләде», дип килә әлеге аятьтә. Шулай итеп, «әт-тәшригъ» сүзе «кануннар билгеләү һәм нормаларны аңлату» дигәнне аңлата. Ислам кануннары (шәригать) бары тик Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм тормышында гына формалашкан һәм бары тик аның аша гына килеп чыккан, чөнки Бөек Раббыбыз Үз Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән башка һичкемгә канун чыгару хокукын бирмәгән. Шәригать нормалары вәхи – Коръән һәм Сөннәт (Пәйгамбәребезнең гамәле) – нигезендә билгеләнгән.

Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм тормышында Исламның төп кагыйдәләре һәм хөкемнәре расланган, аңлаешсыз хөкемнәр ачыкланган, мотлак хөкемнәр, гомуми кагыйдәләр билгеләнгән. Кайбер әмерләр үзгәртелгән, шулай ук кайбер хөкемнәрнең сәбәпләре күрсәтелгән – бу мөселманнарга киләчәктә гомуми кагыйдәләр чыгарырга (иҗмагъ), охшаш мәсьәләләр хакында хөкем итәргә (кыяс) мөмкинлек бирде.

Башкача әйткәндә, Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм чорында Ислам дине кануның нигезе һәм төп принциплары ныгытылды. Шуңа да Раббыбыз болай дип әйтте:

فَإِن تَنَازَعْتُمْ فِي شَيْءٍ فَرُدُّوهُ إِلَى اللَّهِ وَالرَّسُولِ إِن كُنتُمْ تُؤْمِنُونَ بِاللَّهِ وَالْيَوْمِ الْآخِرِ ۚ

**«Әгәр сез Аллаһыга һәм Ахирәт көненә ышансагыз,** [дингә кагылышлы] **берәр нәрсә турында** [үзара] **сүз көрәштергән очракта, аны Аллаһыга һәм** [үзе яныгызда булса] **Расүлгә кайтарыгыз».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:59

«Аллаһыга кайтару» – Аның Китабына (Коръәнгә) мөрәҗәгать итүне, «Расүлгә кайтару» Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм исән чакта аның үзенә, ә вафатыннан соң аның Сөннәтенә мөрәҗәгать итүне аңлата: «Сезгә ике нәрсә калдырдым, аларга тотынсагыз, беркайчан да адашмассыз. Бу – Аллаһының Китабы (Коръән) һәм Аның Пәйгамбәренең Сөннәте».

Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм дөньядан киткән вакытка, Ислам кануны тулысынча формалашкан иде. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм вафатыннан соң, сәхабәләр һәм алдагы галимнәрнең иҗтиһад юлы белән яңа кагыйдәләр билгеләве – чынлыкта яңа канун чыгару түгел, ә:

— Коръән һәм Сөннәттәге нигез принципларын яңа очракларга куллану;

— Китап һәм Сөннәттән яңа хөкемнәр чыгару;

— охшаш очракларны чагыштыру (кыяс) кебек ысуллар белән хөкем бирү.

Бу үз чиратында динебездә теге яки бу мәсьәләгә карата заманча җавап табу ысулын мөмкин кыла. Шуңа күрә бу фәнни дисциплина – Ислам шәригате тарихы – Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм чоры вакыйгаларын гына тикшерү белән чикләнми, ә Ислам хокукында бүгенге көнгә кадәр булган үзгәрешләрне, шулай ук күренекле фәкыйһлар һәм мөҗтәһидләр эшчәнлеген, аларның Ислам хокукы үсешенә керткән өлешен дә өйрәнә. Ислам кануныңың эволюциясе – бу мөселман хокукының тарихи үсешен, аның төрле чорлардагы үзенчәлекләрен һәм фәкыйһларның аның формалашуындагы ролен өйрәнә торган фәнни дисциплина.

Шушы юл динебездә бик күп галимнәрне тәрбияли. Пәйгамбәрләр мирас итеп динар, дирһәмнәр түгел, гыйлем калдырганнарын бик яхшы беләбез. Шуңа күрә галимнәребез пәйгамбәрләрнең варисы булып тора да. Шул сәбәпле, сәхабәләрдән бу юлны – табигыйннәр, алардан тәбге-табигыйннәр бу ысулларны алганнар. Сораулар арту белән, аны өйрәнүче галимнәр саны да артып кына торган. Бүгенге көндә дә шушы галимнәребез мирасын өйрәнүче олуг имамнарыбыз, галимнәребез бар. Алар ярдәмендә без, Коръәнне яттан белмәсәк тә, тәфсир гыйлемен, гарәп телен, 400 меңләп хәдис белмәсәк тә, намаз уку, ураза тоту кагыйдәләрен беләбез. Боларның барысы да шушы галимнәребез хезмәте аша гына билгеле.

Аллаһы бирсә, алдагы җомгаларда шәригатебезнең тарихы турында сөйләшүне дәвам итәрбез. Бүгене вәгазебездә иң мөһиме – шәригатебезнең Аллаһының кануны икәнен аңлап калырга. Теләсә кемнең «мин динне беләм» дип кенә, дин белән манипуляцияләр ясамаска тиешлеген аңлап калсак иде. Безне туры юлдан – галимнәребез юлыннан – тайпылдыручылар, «Коръәндә бит бар да язылган» дип әйтүчеләр дә күп булыр. Әмма бу Пәйгамбәребез һәм аның сәхабәләре, алардан соң килгән табигыйннәр юлы түгел. Шуны онытмасак иде. Әмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*ТР МДНнең Дәгъват бүлеге*

*25 июль вәгазе,*

*мөхәррам аеның 30 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Үзеңә теләгәнне кардәшеңә дә телә

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барлык мактауларыбыз, хәмед-сәналәребез, шөкраналарыбыз Раббыбыз Аллаһыга булсын! Күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез, сәламнәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә һәм аның әһле бәйтенә ирешсен!

Тормыш тәрәккыят кыла, һәрдаим алга бара, ниндидер ачышлар ясала, үзгәрешләр була. Фән-техниканың үсеше, алга киткән вакытларында тормышыбызның әхлакый яклары да үзгәрешләр кичерә. Дөнья ялтыравыгына алданып, рухи кыйммәтләр икенче планга күчкән заманада, кардәшләребез арасындагы мөнәсәбәтләр суынуын, туганлык җепләренең өзелүен, бер-береңә ярдәм итмәүне, вәгъдә бозуны һ. б. шундый күренешләрне күрү бик аяныч. Югыйсә Коръәни Кәримдә Аллаһы Раббыбыз:

إِنَّمَا الْمُؤْمِنُونَ إِخْوَةٌ

**«Һичшиксез, мөэминнәр – кардәшләр»,** – дип әйтә.

«Әл-Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:10

Бу бөек сүзләр белән Хак Тәгалә мөэминнәрнең йөрәкләрен бәйләде. Мөэмин-мөселман, кайда гына булуына карамастан, Аллаһыга ышануын

югалтмыйча, үзенең кардәшен яратырга, үзенә теләгәнне кардәшенә дә теләргә, бердәм булып, ярдәмләшеп яшәргә бурычлы.

Хәзрәти Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһедән килгән мәшһүр хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кардәшенә дә үзенә теләгәнне теләмичә, берегез дә иманлы булмаячак», – дигән.

Һәрберебезнең дә яхшы тормышта яшисе, тәмле ризыклар ашыйсы, хәләл нигъмәтләр кулланасы килә. Шул ук вакытта, иманыбыз нык, камил булса, без бу әйберләрне туганнарыбызга, кардәшләребезгә дә теләр идек. Тик, кызганыч, җәмгыятебездә булган көнчелек, хөсетлек, нәфрәт аркасында, туган белән туган аралашмый, күрше күршенең хәлен белми. Әле алай гына да түгел, кардәшебезнең абынуын күрсәк, шатланабыз: «Аңа Аллаһының ачуы төшкән», – дип тел-теш тидерәбез. Кәеф-сафа корып йөргәндә, бер-беребезгә елмаеп, еш кына «кардәш, брат, ахи» дип әйтәбез. Тик кардәшебезгә, я булмаса туганыбызга авырлык, сынау килгәч, аның ягына борылу түгел, хәлен дә сорамыйбыз, аның белән араларны өзәбез, шактый вакыт аралашмый яшибез. Туганлык, кардәшлек хисләре шунда сынала да инде.

Имам әл-Бохари һәм Мөслим хәдисләр җыентыкларында Расүли Әкрамның: «Мөэмин-мөселманга үзенең кардәше белән араны 3 көннән артыкка өзү рөхсәт ителми», – дигән хәдисе китерелә. Өч көн, җәмәгать! Өч көн! Авыл имамы булгач, күрше-тирә йортларда яшәүче кардәшләребезнең хәлен белергә кергәч, туган туганы белән гомер буе аралашмаганы билгеле булды. Кардәшләребез, якыннарыбыз белән дус-тату булып яшәр урынга, бер-беребезгә ямьсез сүзләр әйтеп, якыннарыбызны үпкәләтәбез, рәнҗетәбез. Егылган кешене кулыннан тартып торгызасы урында, киресенчә, аны гөнаһ сазлыгына батырабыз, җәһәннәмгә этәрәбез. Аллаһының Илчесе галәйһиссәләм: «Аллаһы Тәгаләнең барлыгына, берлегенә инанып, Кыямәт көненең шиксез булуына ышанган кеше хәерле сүз сөйләсен яки дәшмәсен», – дигән. Уйламыйча әйтелгән сүзнең әсәре (эзе) бу дөньяда кешенең калебендә кала, һәм ахирәттә дә Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә бездән моның өчен сораячак.

Шатлык килгәндә дә, кайгы-хәсрәт, борчулар булганда да, без бергә булырга тиешлебез. Шул вакытта гына кеше үзен рухи һәм бәдәни яктан, ягъни җан һәм сәламәтлек ягыннан, көчле тояр. Туганнарыбыз, кардәшләребез белән араларны төзек тоту өстебездә торган гаять зур бер вазифа. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Туганлык (кардәшлек) җепләрен өзүче җәннәткә кермәс», – дигән. Бу хәдистән аңлашылганча, туганлык (кардәшлек) җепләре – ул Аллаһы Раббыбызның рәхмәтенә илтә торган олы бер юл. Әгәр дә якыннарыбыз белән нәсел, кардәшлек җепләре өзелсә, Аллаһының рәхмәтенә ирешә торган юлыбыз нинди булыр? Аның төзеклегенә хилафлык килмәсме?

Аллаһы Раббыбызның Кыяматтә йөзләребезне якты кылуын, гөнаһларыбызны ярлыкавын телибез икән, кардәшләребез алдында булган дүрт хакны үтәргә ашыгыйк. Аның беренчесе – сәламләшү. Өч көн араны өзү турындагы хәдиснең дәвамында: «Араларында беренче булып сәлам бирүчесе – иң хәерлесе», – диелә. Тәкәбберлеген җиңеп, беренче булып кул биреп исәнләшкән кешене Аллаһы ярата. Икенчесе – зыян салмау. Үпкәләткән, рәнҗеткән кешегә җавап итеп үч сакламау – киң күңелле, сабыр кешеләрнең сыйфаты. Аллаһы Тәгалә бу хакта «Фуссыйләт» сүрәсенең 34–35 нче аятьләрендә бәян итә:

وَلَا تَسْتَوِي الْحَسَنَةُ وَلَا السَّيِّئَةُ ۚ ادْفَعْ بِالَّتِي هِيَ أَحْسَنُ فَإِذَا الَّذِي بَيْنَكَ وَبَيْنَهُ عَدَاوَةٌ كَأَنَّهُ وَلِيٌّ حَمِيمٌ ﴿٣٤﴾ وَمَا يُلَقَّاهَا إِلَّا الَّذِينَ صَبَرُوا وَمَا يُلَقَّاهَا إِلَّا ذُو حَظٍّ عَظِيمٍ ﴿٣٥﴾

> «**Яхшылык белән явызлык тиң түгел. Син** [кайбер дошманнарыңнан күргән явыз мөгамәләне күрмәмешкә салышып, яхшылык белән җавап кайтару белән түгел, явызлык кылганга игелек кылу кебек] **иң яхшы мөгамәлә белән кайтар, шулвакыт сиңа дошман булган кеше**

**гүяки шәфкатьле бер дус** [булыр]**. Әмма бу** [шәрәфле сыйфат] **сабыр иткән кешеләргә генә бирелер. Бу зур бер насыйп иясе булганнарга гына бирелер».**

«Фуссыйләт / Аңлатылды», 41:34–35

Өченчесе – кардәшебезгә, туганыбызга мөмкин кадәр чын күңелдән ярдәм итик. Үзебезнең нәфесебез белән сөйләшик, Аллаһы каршында күңелебездәге булган ният, гамәлләребезне дөреслик. Матди яки физик ярдәмне туган-кардәшләребезгә күрсәтүдән башлыйк. Кардәшләребез алдында булган дүртенче хак – гафу итә белү. Әшәкелекләр эшләгән кешегә Аллаһы Тәгаләнең җәзасын теләү, аңа ләгънәт кылу киң күңеллелек булып саналмый. Аллаһы Раббыбыздан кешеләрне гафу итә белүне сорыйк.

Мөхтәрәм җәмәгать, искә алынган аяте-кәлимәләрне, хәдисләрне тормышыбызга кертергә тырышыйк! Шуның берсен генә булса да алып гамәл кыла башласак, җәмгыятебезгә, кешеләргә күпме файда китерер идек. Арабызда булган көнчелек, тәкәбберлек, нәфрәт учаклары аз гына булса да кимер иде. Арабызда Ислам дине өндәгән бер-беребезне ярату, хөрмәт итү хисләре ныгыр иде.

Хөрмәтле дин кардәшләребез! Бу вәгазебез беренче чиратта үзебезгә, аннан, минбәрләрдән ишетелгәндә, һәрбарчабызга да үгет-нәсыйхәт булып, иманыбызны камилләп, файда китерсә иде. Бер-беребез арасында өлфәт мәхәббәт, ихтирам хисләре, дуслык, татулык, Аллаһы ризалыгы өчен ярату хисләре булсын! Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел

тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рәис хәзрәт Нигъмәтҗанов,*

*Апас районының Кормаш авылы мәчете имам-хатыйбы*

*1 август вәгазе,*

*сафәр аеның 7 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Аллаһыга тәвәккәл кылу

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барлык мактауларыбыз – галәмнәрнең Раббысы Аллаһы Тәгаләгә. Галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелгән сөекле расүлебез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салаватшәрифләребез барып ирешсен.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримдә кешеләрдәге кайбер сыйфатларны яратуын, ә кайбер сыйфатларны яратмавы турында хәбәр итә. Бу без игътибар итәргә тиешле мәгълүмат. Мисал өчен, Аллаһы Тәгалә сабыр итүчеләрне, пакьләнүчеләрне, тәкъвалык ияләрен, Аллаһыга тәвәккәл кылучыларны, тәүбә итүчеләрне, гадел булганнарны, яхшы гамәлләр кылучыларны ярата. Чиктән ашканнарны, бозыклык таратучыларны, кяфер һәм гөнаһ кылудан туктамаган гөнаһлы кешене, залимнәрне, тәкәббер һәм мактанчык кешеләрне, исраф итүчеләрне, хыянәтче һәм кадерне белмәүчене Аллаһы Раббыбыз сөйми.

Бүгенге вәгазебездә искә аласы килгән сыйфат – ул Аллаһыга тәвәккәл кылу. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَلِلَّهِ غَيْبُ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَإِلَيْهِ يُرْجَعُ الْأَمْرُ كُلُّهُ فَاعْبُدْهُ وَتَوَكَّلْ عَلَيْهِ ۚ وَمَا رَبُّكَ بِغَافِلٍ عَمَّا تَعْمَلُونَ

**«Күкләрдәге вә җирдәге** [бөтен яшерен] **гаиб нәрсәләр Аңа билгеле.** [Расүлем!] **Эшләрнең бөтенесе Аңа кайтарылачак. Аңа гына гыйбадәт кыл һәм** [дошманнарыңнан сине коткаруы өчен] **Аңа гына тәвәккәл кыл. Раббың бит сезнең ни кылганнарыгыздан гафил түгел».**

«Һуд», 11:123

Шулай ук башка аятьтә болай ди:

وَتَوَكَّلْ عَلَى اللَّهِ ۚ وَكَفَىٰ بِاللَّهِ وَكِيلًا

**«...һәм Аллаһыга таян. Бер Яклаучы буларак Аллаһы җитә».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:81

وَمَن يَتَوَكَّلْ عَلَى اللَّهِ فَهُوَ حَسْبُهُ ۚ إِنَّ اللَّهَ بَالِغُ أَمْرِهِ ۚ قَدْ جَعَلَ اللَّهُ لِكُلِّ شَيْءٍ قَدْرًا

**«...Кем дә кем Аллаһыга тәвәккәл кыла, аңа Ул җитә. Һичшиксез, Аллаһы һәрнәрсә өчен** [ул әле бар булганчы] **бер үлчәм куйган».**

«Әт-Талак», 65:3

Күрәбез, бу аятьләрдә сүз Аллаһыга тәвәккәл кылу турында бара. Ә бу ни димәк? Аллаһыга тәвәккәл кылу эшләрне Аңа тапшыруны һәм Аннан гына ярдәм өмет итүне аңлата. Икенче аңлатма буенча, Аллаһыга тәвәккәл кылу – ул йөрәкнең, файдалы нәрсәне өмет итеп һәм зарардан саклауны сорап, Аллаһыга таянуы. Ул – йөрәк гамәле һәм Аллаһыга гыйбадәт кылуның бер төре.

Имам Әхмәд рахимәһуллаһи болай дип әйткән: «Тәвәккәл кылу – ул йөрәк гамәле. Аны сүзләр һәм эшләр белән күрсәтеп булмый».

Аллаһыга тәвәккәл кылучы кеше, эшләренең ахыры нәрсә белән төгәлләнүенә карамастан, күңеле белән риза була һәм үзен тыныч тота. Хәтта ул теләгән максатына ирешмәсә дә, зарланмый.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Кем дә кем иң хөрмәтле кеше булырга теләсә, Аллаһыдан курыксын. Кем дә кем иң көчле кеше булырга теләсә, Аллаһыга эшен тапшырсын».

Аллаһыга дөрес итеп тәвәккәл кылучы кеше ике сыйфатка ия булырга тиеш:

*Беренчесе* – максатка ирешү өчен бөтен сәбәпләрне дә кылу. Аллаһыга дөрес тәвәккәл кылу һәрвакытта да сәбәбен күрү, көч түгү, тырышлык күрсәтүгә бәйле. Кем дә кем ризык яки уңышка ирешүне теләсә, шул Аллаһыга тәвәккәл кылып, тырышлык күрсәтергә тиеш.

Кайбер кешеләр Аллаһыга тәвәккәл кылуны сәбәбен күрмичә, дога кылып утыру гына дип аңлый. Бу ялгыш фикер. Сәбәпне калдырып, Аллаһыдан нәрсә дә булса өмет итү – ул хыяллану гына, ә Аңа тәвәккәл кылу булмый. Бу хакта Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисендә шулай ди: «Әгәр дә сез Аллаһыга тиешле дәрәҗәдә тәвәккәл кылсагыз, Ул сезне кошларны ризыкландырган кебек ризыкландырыр иде. Алар иртә белән карыннары ач килеш очып чыгып китәләр, ә кич белән карыннары тук хәлдә кайталар».

Ягъни кошлар ризыкны Аллаһыдан өмет итә, ләкин шуның белән бергә алар ризык та эзли, тырышлык куя. Шулай ук Аллаһыга тәвәккәл кылучы кеше дә, максатына ирешү өчен бөтен сәбәбен кылып, нәтиҗәсен Аллаһыдан көтәргә тиеш. Әгәр дә кеше шушы рәвешле Раббысына таянса, ул курку белән кайгы хисен кичермәячәк.

Бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына бер кеше килә дә: «Ий Аллаһының Илчесе! Дөямне бәйләп, Аллаһыга тапшырыйммы яки бәйләмичә Аллаһыга тапшырыйммы?» – дип сорый. Расүлебез: «Дөяңне бәйлә, ә аннан соң Аллаһыга тапшыр», – дип җавап бирә. Ягъни бу кеше, дөясен бәйләмичә, Аллаһыга тәвәккәл кылдым дип кенә калдырса, әлбәттә,

дөя югалырга яки качарга мөмкин иде. Һәм ул Расүлебездән бу хакта киңәш сорый. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам исә безгә дөрес итеп тәвәккәл кылуның асылын аңлата: башта үз кулыңнан килгәнен эшлә дә, сәбәбен күр дә, ә калганын инде Аллаһыга тапшыр, Ул ни кушкан булса, шул булыр.

*Икенче сыйфат* – нәтиҗәне йөрәк белән Аллаһыдан көтү. Дөреслектә, кеше, максатына ирешү өчен, нихәтле генә сәбәп кылмасын, аның уңышка ирешүе нәтиҗәдә бары Аллаһыга бәйле. Шуңа күрә мөселман кешесе сәбәпкә түгел, ә Аллаһыга таянырга, ярдәмне Аннан өмет итәргә тиеш. Кем дә кем, Аллаһыга таянмыйча, тулысынча сәбәпләргә генә таянса, ул сәбәпне Аллаһыдан өстен куйган була. Ислам динендә икесен дә берләштерү таләп ителә: сәбәпләрне күрү дә, Аллаһыга таяну да.

Газиз дин кардәшләрем, тәвәккәл кылу – Аллаһыга ышануның бер билгесе. Аллаһыга тәвәккәл кылучы кеше Аллаһының ярдәмче, авырлыктан коткаручы Зат булуына ышана. Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَعَلَى اللَّهِ فَتَوَكَّلُوا إِن كُنتُم مُّؤْمِنِينَ

**«Әгәр** [Аллаһының сүзенә] **ышанган кешеләр булсагыз, Аллаһыга гына тәвәккәл итегез».**

«Әл-Маидә / Табын», 5:23

Раббыбыз тәвәккәл кылучы кешеләрне ярата. Коръәндә болай диелә:

فَإِذَا عَزَمْتَ فَتَوَكَّلْ عَلَى اللَّهِ ۚ إِنَّ اللَّهَ يُحِبُّ الْمُتَوَكِّلِينَ

**«Әмма** [ныклы] **карарга килсәң, шунда ук Аллаһыга тапшыр. Һичшиксез, Аллаһы** [бөтен эшләрдә Аңа] **тәвәккәл итүчеләрне сөя».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:159

Тәвәккәл кылучы кешене Аллаһы Тәгалә зарардан саклый. Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтә:

«Кем дә кем өеннән чыкканда:

بِاسْمِ اللَّهِ، تَوَكَّلْتُ على اللَّهِ، وَلاَ حَوْلَ وَلاَ قُوَّةَ إِلاَّ بِاللَّهِ

«Бисмил-Ләәһи тәвәккәлтү галәл-Лааһи, вә ләә хәүлә вә ләә куввәтә иллә бил-Ләәһ» [Аллаһының исеме белән, Аңа (гына) тәвәккәл кылдым, куәт һәм көч бер Аллаһыдан гына], – дисә, аңа: «Ул туры юлга кертелде, зарар аннан читләштерелде, ул зарардан сакланды һәм шайтаннар аннан ерагайды», – дип әйтелә. Ә шайтан башка шайтанга: «Ничек син туры юлга кертелгән, аннан зарар читләштерелгән һәм зарардан сакланган кешегә берәр нәрсә эшли аласың?!» – ди».

Аллаһы Тәгалә бездә Үзе сөя торган сыйфатларны булдырырга ярдәм итсен, Үзе сөймәгән сыйфатлардан арындырсын. Эшләребезне бер Үзенә тапшырып, дөньябыз өчен дә, ахирәтебез өчен дә хәерле нәтиҗәләргә ирешергә насыйп итсен! Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Алмаз хәзрәт Гаянов,*

*Саба районының Байлар Сабасы Үзәк мәчете имам-хатыйбы*

*8 август вәгазе,*

*сафәр аеның 14 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Аллаһыга шөкер итү

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, әгәр дә без динебезгә гомумән карасак, аның ике өлештән торганын күрәбез: беренче өлеше – шөкер итү, ә икенче өлеше – сабыр итү. Бу сыйфатларның икесе дә кешене Аллаһыга якынайта һәм ахирәттә аны зур дәрәҗәләргә күтәрә. Мөселман шөкер итсә дә, сабырлык күрсәтсә дә, Аллаһыдан әҗер ала һәм аның гөнаһлары ярлыкана.

Коръән аятьләреннән дә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләреннән дә без динебезнең шушы ике өлештән торганын күрәбез. Аллаһы Тәгалә «әш-Шура» сүрәсендә әйтә:

إِنَّ فِي ذَٰلِكَ لَآيَاتٍ لِّكُلِّ صَبَّارٍ شَكُورٍ

**«Һичшиксез, сабыр иткән һәм** [бөтен тырышлыгын Аллаһы Тәгаләнең аятьләренә карауга һәм нигъмәтләре турында фикерләүгә сарыф итеп] **шөкер иткән һәр** [иманлы] **кеше өчен монда билгеләр бар».**

«Әш-Шура / Киңәш», 42:33

Яки кыска гына «әл-Гаср» сүрәсендә дә без динебезнең шөкер һәм сабырлыктан торганын күрәбез. Коръәндәге кыйссаларда да Аллаһы Тәгалә безгә пәйгамбәрләрнең сабыр һәм Раббыларына шөкер итүчеләрдән булуларын үрнәк һәм дәрес итеп китерә.

Сөекле Пәйгабәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләренә килсәк, хәзрәти Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе сөйләвенчә, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дип әйткән: «Иман ике өлештән торадыр. Беренче яртысы – сабырлыктан, ә икенче яртысы – шөкердән»[1].

Хәзрәти Әбү Яхъя Соһәйб бине Синән радыяллаһу ганһе китергән башка бер хәдистә Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә: «Нинди гаҗәп бу мөэминнең хәле! Аның белән ни генә булса да, гел хәерлегә була, һәм бу бары тик мөэмингә генә бирелде. Әгәр аңа шатлык ирешсә, ул шөкер итә, һәм бу аның өчен хәерле була. Әгәр аңа берәр зарар ирешсә, ул сабыр итә, һәм бу да аңа хәерле була»[2]. Ягъни, мөэмин шөкер итсә дә, ул әҗер ала һәм аның гөнаһлары ярлыкана, сабыр итсә дә, ул әҗер ала һәм аның гөнаһлары ярлыкана. Шуңа күрә һәрбер авырлык мөэмингә Аллаһының рәхмәте булып килә, ә кяфергә газап булып килә, чөнки ул кайгы-хәсрәттән кала бернигә дә ирешми.

Димәк, диннең мөһим бер өлеше – ул шөкер итү. Нәрсә соң ул шөкер итү? «Шөкер» – гарәп сүзе, аның асылы – Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән нигъмәтләрне танып, Аңа хәмде-сәна кылу, олылау.

Шөкер – ул яхшылыкка яхшылык белән кайтару яки, ким дигәндә, сүз белән рәхмәтеңне белдерү. Әгәр дә кеше аңа эшләнгән яхшылыкны танымаса яки шөкер-рәхмәтләрен белдермәсә, бу гадел булырмы? Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кешеләргә шөкер кылмаучы Аллаһыга да шөкер кылмас», – дип әйткән. Ягъни, әгәр дә кеше башкалардан килгән яхшылыкны танымаса, аңламаса, ул инде Аллаһыдан килгән яхшылыкны да танымас һәм күрмәс, боларга бары тик үзем генә ирештем дияр.

Янә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кемдер сезгә изгелек кылса, аңа тиешле хәерлелек белән кайтарыгыз. Әгәр бирер нәрсә

[1] Имам әл-Бәйһакый, имам әд-Дәйләми.

[2] Имам Мөслим.

тапмасагыз, аңа хәерлелек теләп дога кылыгыз, хәтта дога белән хакымны кайтардым дигән уй килгәнчегә кадәр», – дип әйткән[1].

Мөселман, изгелек кылганда, шул кешедән берәр яхшылык өмет итеп түгел, ә Аллаһыдан хәерлелек өмет итеп, ихлас рәвештә эшләргә тиеш. Кайбер кешеләр, үпкәләп: «Мин аңа күпме изгелек кылдым, ә ул миңа рәхмәт дип тә әйтмәде, эшләгән изгелегемне инкяр итте», – дип, киләчәктә изгелек кылудан өметләрен өзәләр. Ни өчен? Чөнки изгелек Аллаһыдан әҗер өмет итеп түгел, ә кешеләрдән рәхмәт ишетү, алар шөкер кылсыннар өчен эшләнде. Изгелеген Аллаһы ризалы өчен эшләгән кеше кешеләрдән рәхмәт көтми, чөнки Аллаһы инде аңа тиешле әҗерен, савабын түләде. Теге кеше рәхмәт әйтсә, әлбәттә, күңел күтәрелә, әйтмәсә – күңелендә үпкә юк. Коръәндә төрле пәйгамбәрләрнең халыкларына әйткән мондый сүзе китерелә:

وَمَا أَسْأَلُكُمْ عَلَيْهِ مِنْ أَجْرٍ ۖ إِنْ أَجْرِيَ إِلَّا عَلَىٰ رَبِّ الْعَالَمِينَ

**«Мин бит сездән моның өчен түләү сорамыйм. Минем әҗерем – Аллаһыда гына».**

«Әш-Шүгәра / Шагыйрьләр», 26:109, 127, 145, 164, 180

Аллаһы Тәгалә Коръәндә бездән Аңа шөкер итүебезне таләп итә:

وَاشْكُرُوا لِي وَلَا تَكْفُرُونِ

**«Миңа шөкер итегез,** [әмеремә буйсынмыйча, нигъмәтләремне күрмәгәндәй] **Миңа карата шөкерсез булмагыз».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:152

قُلْ هُوَ الَّذِي أَنشَأَكُمْ وَجَعَلَ لَكُمُ السَّمْعَ وَالْأَبْصَارَ وَالْأَفْئِدَةَ ۖ قَلِيلًا مَّا تَشْكُرُونَ

---

[1] Имам Әбү Давыд, имам ән-Нәсаи, имам Әхмәд.

«[Расүлем!] **Әйт: «Ул – бар итүче, сезгә ишетү куәте, күзләр һәм йөрәкләр бирүче. Сез бик аз шөкер кыласыз».**

«Әл-Мүльк / Хөкемдарлык», 67:23

Аллаһыга шөкер итү ничек була соң ул? Әллә шөкер кылу – ул «Аллаһыга шөкер», «Аллаһыга шөкер» дип сөйләнеп йөрүме? Бу шөкернең беренче өлеше генә әле, ягъни нигъмәтнең Аллаһыдан икәнен тану. Ә киңрәк итеп карaганда, Аллаһыга шөкер итү – ул Аллаһы Тәгалә сиңа биргән нигъмәтләрне кулланып, Аллаһыга якынаю нияте белән изгелек кылу, Аны зурлау вә бөекләү һәм бу изгелек өчен әҗерне Аллаһыдан гына өмет итү.

Изгелекнең нәрсә икәнлеген, без Раббыбызны ничек бөекләргә тиешлеген Аллаһы Тәгалә Коръәндә күрсәткән, һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм моны мөселманнарга аңлаткан. Мәсәлән, Аллаһыга шөкер – ул Аллаһыга сәҗдә кылып намаз уку, кергән байлыктан садака бирү. Сәламәтлек өчен шөкер – ураза тоту; байлыгың, сәламәтлегең булса – хаҗ кылу. Шөкер – ул шулай ук Аллаһы биргән күзләр белән Коръән уку; Аллаһы биргән колак белән остаздан белем алу; Аллаһы биргән тел белән Аны мактап зикерләр әйтү; Аллаһы биргән тән көчен кулланып, бер зәгыйфькә коедан су алып бирү; Аллаһы биргән машина белән юлчыны утыртып бару… Бу рәвешле шөкер кылуларга бик күп мисаллар китерергә була.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, Аллаһы Тәгалә бездән рәхмәтле булуны Ул моңа мохтаҗ булганы өчен таләп итми. Шөкер кылганда без Аңа буйсынабыз. Аллаһы Раббыбыз без шөкер кылганда калебләребездә ихласлылыкны һәм Аңа булган омтылышны күрергә тели. Һәм шуннан чыгып, Ул безгә бәя бирә. Күңелдә булган иманны, ихласлылыкны, Аллаһыга булган омтылышны һәм мәхәббәтне без бары тик шөкер кылганда гына күрсәтә алабыз.

Аллаһы Тәгалә гамәлнең зур яки кечкенә булуына түгел, ә бу гамәлне кешенең нинди ният белән кылуына һәм ихласлылык дәрәҗәсенә карый. Ният кечкенә гамәлне зур итәргә, ә зур гамәлне юк итәргә мөмкин. Аллаһыга

буйсынып, гыйбадәт кылып, изгелек кылып, без Аңа шөкер кылабыз, бу шөкеребезгә җавап итеп Аллаһы безгә шөкер кыла. Изгелеккә – изгелек.

Аллаһы Тәгалә изгелек кылучыга шөкер кылып, кылган изгелегенең бөтен хәерен изгелек итеп үзенә үк кире кайтара. Әҗер-савабы, ярлыкавы, бәрәкәте, ризалыгы һәм нигъмәтнең артуы белән кире кайтара Ул. Бу хакта Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَمَن يَشْكُرْ فَإِنَّمَا يَشْكُرُ لِنَفْسِهِ

**«Кем дә кем шөкер итсә, үз файдасына шөкер иткән булыр».**

«Локман», 31:12

Яки:

وَإِذْ تَأَذَّنَ رَبُّكُمْ لَئِن شَكَرْتُمْ لَأَزِيدَنَّكُمْ

**«Раббыгыз: «Әгәр** [иман китереп, изге гамәлләр кылып, Минем сезне дошманнарыгыздан коткару нигъмәтемә] **шөкер итсәгез, һичшиксез, сезгә** [нигъмәтләрне тагын да] **арттырачакмын ...» – дип игълан итте».**

«Ибраһим», 14:7

Раббыбызның шөкер сүзе белән бер үк тамырдан булган күркәм исеме бар. Ул – Әш-Шәкүүр – күп итеп Шөкер кылучы. Ягъни, Аллаһы изгелек һәм шөкер кылучыга ул кылган изгелеккә караганда әҗерен күпкә арттырып кайтара. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Адәм баласының һәр кылган изгелеге арттырыла, бер изге гамәл уннан алып җиде йөз тапкыр эшләнгән кебек булыр», – дип әйткән[1]. Ягъни, бер изгелек кылдың, ә әҗерен ун тапкыр яки тагы да күбрәк эшләгән кебек итеп аласың, дигән сүз. Шуңа тагы Аллаһының ярлыкавы, бәрәкәте һәм булган нигъмәтнең арттырылуы белән кайтарыла. Аллаһы Тәгалә юмарт һәм рәхмәте киң булган Зат.

[1] Имам әл-Бохари, имам Мөслим.

Менә шушы буладыр Аллаһыга шөкер кылу, һәм менә шушы шөкер кылу безнең өстебезгә Раббыбыз тарафыннан бурыч итеп йөкләтелгән.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Марат хәзрәт Сәйфетдинов,*
*Балтачның Үзәк мәчете имамы*

*15 август вәгазе,*

*сафәр аеның 21 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Хәләл табыш

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Бөтен галәмнәрне юктан бар итеп, шушы галәмдәге булган бөтен барлыкларны да хәрәкәткә китереп, кылган догаларыбызны кабуллардан кылып, һәр көнне Үз нигъмәтләреннән безне нигъмәтләндереп торып, безне ризыкландырып торып, һәр көнне төрле сынауларын биреп, шушы сынауларга карата Үзенең рәхмәтен, Үзенең ярдәмен, Үзенең шифасын биреп һәм, әлбәттә, бер Үзе генә гыйбадәткә лаеклы булган Хак Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә мактауларыбыз һәм даннарыбыз булсын. Әмин.

Газиз дин кардәшләрем, бүген без бик әһәмиятле бер темага, хәләл табыш хакында сөйләшербез. Хәләл табыш – ул безнең иманыбызның нигезе, рухи байлыгыбызның һәм җәмгыятьтәге урыныбызның мөһим өлеше. Безнең тормышыбызда хәләл юл белән табылган акча, хәләл эш, хәләл ризыгыбыз нинди зур урынга ия булуын, Исламдагы дини принципларга ни дәрәҗәдә туры килергә тиешлеген аңлатырга тырышачакбыз.

Беренчедән, мөселман өчен хәләл белән харамны аеру бик мөһим, чөнки белә торып харам белән туклану мөселман кешесен гөнаһка алып бара. Аллаһы Тәгалә дә Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне җир йөзенә барлык кешеләргә дә хәләлне харамнан, яхшыны яманнан аерырга өйрәтү өчен җибәрде:

يَأْمُرُهُم بِالْمَعْرُوفِ وَيَنْهَاهُمْ عَنِ الْمُنكَرِ وَيُحِلُّ لَهُمُ الطَّيِّبَاتِ وَيُحَرِّمُ
عَلَيْهِمُ الْخَبَائِثَ وَيَضَعُ عَنْهُمْ إِصْرَهُمْ وَالْأَغْلَالَ الَّتِي كَانَتْ عَلَيْهِمْ

**«...Ул** [Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм] **аларны** [иман һәм гыйбадәтләр кебек] **яхшылыкка өнди,** [көферлек һәм гөнаһлар кебек] **начарлыклардан тыя, пакь нәрсәләрне** [Аллаһы исеме белән чалынган хайваннарны һәм нәҗес булмаган бөтен ризыкны] **аларга хәләл итә,** [кан, үләксә һәм риба кебек матди һәм рухи] **кабахәт нәрсәләрне исә аларга харам кыла, авыр йөкләрен һәм моңарчы өсләрендә** [муеннарына салынган] **булган богауларны** [авыр җаваплылыкларны] **алардан ала...»**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:157

Шуңа да гаиләбезнең иминлеген, бәхетен саклап каласыбыз килсә, безгә гаиләбезгә харам ризык, харам акчалар алып кайтудан сак булырга кирәк.

Исламда хәләл табыш алу – һәр мөселман өчен изге бурыч. Раббыбыз безгә хәләл ризык, хәләл мал белән генә тукланырга куша. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

وَكُلُوا مِمَّا رَزَقَكُمُ اللَّهُ حَلَالًا طَيِّبًا ۚ وَاتَّقُوا اللَّهَ الَّذِي أَنتُم بِهِ مُؤْمِنُونَ

**«Аллаһының сезне ризыкландырган нәрсәләреннән хәләл һәм хуш булганын ашагыз һәм Аллаһыдан куркыгыз, сез бит – Аңа иман китерүчеләр».**

«Әл-Маидә / Табын», 5:88

Акча табу юлыбыз хәләл (рөхсәт ителгән) булмаса, кергән малыбыз да харам булыр, ә инде ул акчага алган ризык ничек итеп хәләл була алсын? Ә мөселман кешесе өчен гаиләсен нинди ризык белән тәэмин итүе бик тә мөһим булырга тиеш.

*1. Байлык – адәм баласы өчен бик зур сынау.*

Бүген күп кенә кешеләр, байлыкка омтылып, үзендәге барлык кешелек сыйфатларын югалта бара. Гадилеген генә түгел, мөлкәт җыям дип, алар намусын да сата, үзенә тиеш булмаганын, золымлык кылып, көчсезләрдән тартып та ала. Баеган саен, аларның нәфесләре артканнан-арта бара, чөнки мул, бай тормышка бер ияләшкәч, аннан аерыласылары килми. Шуңа да андыйлар акча эшләү ысулының барысы да кулай дип уйлый. Шул рәвешле, байлыкның, муллыкның безнең өчен бик зур сынауга әйләнүе дә бар.

كُلُّ نَفْسٍ ذَائِقَةُ الْمَوْتِ ۗ وَنَبْلُوكُم بِالشَّرِّ وَالْخَيْرِ فِتْنَةً ۖ وَإِلَيْنَا تُرْجَعُونَ

**«Һәр җан иясе үлемне татыячак. Без, коткы салыр өчен, сезне** [авыру һәм фәкыйрьлек кебек] **яманлык белән дә,** [саулык һәм байлык кебек] **яхшылык белән дә сыныйбыз. Әмма** [ахырда, хисап һәм җәза өчен] **Безгә кайтарылачаксыз»,** – ди Аллаһы Тәгалә «Пәйгамбәрләр» сүрәсендә.

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:35

Аллаһы Тәгалә бу аятендә байлыкта кешеләр өчен бик зур сынау да, имтихан да барлыгын бәян кыла. Һәм ул сынау фәкыйрьлек, мохтаҗлык сынавыннан авыррак та булырга мөмкин. Малың арта башлагач, иң авыры – гадилекне саклап калу һәм тәкәбберлек сыйфатын калебкә кертмәү.

Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үз өммәтен кисәткән: «Аллаһы белән ант итәм: мин сезнең өчен фәкыйрьлектән курыкмыйм. Әмма, сезгә кадәр булган кавемнәргә ачылган кебек, сезнең өчен дә бу дөнья ачылып, сез аның артыннан куып, бер-берегез белән узыша башларсыз, һәм шушы вакытлыча гына булган дөньяга алдану, сезгә кадәр яшәгән кавемнәрне харап иткән кебек, сезне дә харап итәр, дип куркам»[1].

[1] Имам әл-Бохари, № 2988.

Бүгенге көндә бу хәдиснең чынга ашуын күрәбез инде. Мал җыюда бер-беребез белән ярыша-ярыша барлык чикләрне дә уздык. Тапкан малыбызның хараммы яки хәләлме булуы хакында уйланып та карамыйбыз, иң мөһиме – булсын. Бу вакытлыча булган дөньяга алданмыйк, акчага табынмыйча, хәләл кәсеп белән хәләл мал табарга өйрәник!

*2. Хәләл кәсеп, хәләл эш.*

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай дигән: «Әгәр дә сез Аллаһыга тиешле дәрәҗәдә тәвәккәл кылсагыз, Ул сезне кошларны ризыкландырган кебек ризыкландырыр иде. Алар иртә белән карыннары ач килеш чыгып китәләр, ә кич белән карыннары тук хәлдә кайталар»[1].

Бу хәдисне уйланыбрак укысак, үзебез өчен бик зур файдалар табарбыз.

Беренчесе – күңелне Аллаһы белән бәйләү, Аңа ышану һәм таяну, бар эшләребездә дә Аннан ярдәм сорау. Һәм: «Йә Раббым, бу тормышта үз урынымны табарга ярдәм итсәң иде, миңа ошаган һөнәрне күрсәтсәң иде, хәләл кәсеп юлларын ачсаң иде», – дип дога кылырга өйрәнү.

Икенчесе – сәбәпләр кылу. Хәдистә әйтелгәнчә, кардәшләрем, кошлар иртә белән торалар да: «Бүген ашарга юктыр инде, һава торышы да начар, төшеп калган ризыклар да күренми», – дип ояларында гына ятмыйлар бит. Алар, тәвәккәл кылып, бер җиргә барып карыйлар, анда булмаса, икенче агачка кунып, анда берәр җимеш булмасмы дип эзлиләр һәм барыбер ни дә булса табалар. Хәтта кышкы салкында да, һичбер нәрсә үсмәгән вакытта да, тук булып кайталар: я кешеләр җимлек куйган булалар, я ипи валчыклары төшеп калган була; кичкә тулы ашказаны белән кайтып керәләр. Безгә дә, кошлардан гыйбрәт алып, хәдис белән гамәл кылып, төрле өлкәләрдә эшләп карарга һәм үзебез өчен хәләл кәсеп итү юлын табарга кирәк.

[1] Имам әт-Тирмизи.

Аллаһы Тәгалә «әт-Талак» сүрәсенең 3 нче аятендә болай ди:

وَمَن يَتَوَكَّلْ عَلَى اللَّهِ فَهُوَ حَسْبُهُ ۚ إِنَّ اللَّهَ بَالِغُ أَمْرِهِ ۚ قَدْ جَعَلَ اللَّهُ لِكُلِّ شَيْءٍ قَدْرًا

**«...Кем дә кем Аллаһыга тәвәккәл кыла, аңа Ул җитә. Һичшиксез, Аллаһы һәрнәрсә өчен** [ул әле бар булганчы] **бер үлчәм куйган».**

«Әт-Талак», 65:3

*3. Риба – гөнаһ.*

Хәзерге җәмгыятьтә иң киң таралган тыелган табышларның берсе – риба. Ул еш кына процентка акча бирү яки кредитка товар сату белән күрсәтелә. Риба сәүдә өлкәсендә бик киң таралган. Һәрбер зур сату үзәкләрендә кредит оешмалары вәкилләре утыра, алар теләсә нинди товарны – иң арзаныннан иң кыйммәтлесенә кадәр – төрле вакыт аралыгына һәм теләсә нинди процентка кредитка алырга тәкъдим итәләр. Кибет витриналарыннан сатып алучыларга «иң кирәкле» товарлар өчен түләүне бүлеп, «кечкенә» процентка алу тәкъдиме белән реклама плакатлары карый.

Кибет киштәләрендәге товарлар төрлелегеннән бүген сатып алучылар кайсысына карарга да белми, ләкин гаилә бюджетында калган акча күләме аларга үзләренә ошаган товарны сатып алырга мөмкинлек бирми. Һәм күпчелек очракта кешеләр бик үк кирәкле дә булмаган әйбер сатып алырга тели. Шуңа да карамастан, аны сатып алу теләге акылны җиңә, һәм кешеләр, кредитның харам икәнен белә торып, бу әйберне кредитка алалар.

Сәүдә һәм кредит оешмаларының намуссыз хуҗалары кешеләрнең игътибарсызлыгыннан файдаланалар. Алар мондый табышның рөхсәт ителүенә һәм кешеләрнең аларга соңгы тиен түләвенә игътибар итмиләр. Кызганыч, күп кенә мөселманнар да, үз-үзләрен тыя алмыйча, шайтанның вәсвәсәсенә бирелеп, кредитлар, ссудалар һ. б. ала.

Хәзрәти Габдуллаһ бине Габбас радыяллаһу ганһүмә тапшырган хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: «Рибачылыктан алынган һәм кеше тарафыннан сарыф ителгән бер дирһәм утыз алты тапкыр зина кылган кешенең гөнаһыннан авыррак»[1].

Газиз дин кардәшләрем, уйланыйк, мондый коточкыч гөнаһка күп кенә мөселманнар игътибар итмиләр һәм рибаның төрле төренә тартылалар. Ә бит рөхсәт ителгән ризык һәм мал табу турыдан-туры дин тотучының гыйбадәте, шул исәптән аның догасының кабул ителүенә дә бәйле. Янә хәзрәти Габдуллаһ бине Габбас радыяллаһу ганһүмәдән риваять ителә: «Бервакыт бер җыелышта Сәгъд бине Әбү Вәккас радыяллаһу ганһе урынынннан торып: «Йә Аллаһының Илчесе, Аллаһы Тәгаләдән минем догаларына җавап алучы кешеләрдән булуымны сорачы», – диде. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам аңа болай җавап кайтарды: «Йә Сәгъд, бары тик яхшыны һәм рөхсәт ителгәнне генә аша, һәм син ялваруларына җавап алучы кешеләрдән булырсың. Җанымның Хуҗасы булган Аллаһы белән ант итеп әйтәм: әгәр кеше карынына бер кисәк тыелган (харам) ризык ташласа, аның гамәлләре кырык көн дәвамында кабул ителмәячәк. Рибачылык һәм харам белән үстерелгән кешенең тәне җәһәннәм утына гына лаек»[2].

Бу хәдистән күренгәнчә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дога кабул булуның төп шартларыннан рөхсәт ителгән ризыкны атаган, ә тыелганны куллану – догаларыбызның кабул ителмәвенең төп сәбәбе дип әйткән. Ул шулай ук тыелган һәм риба җимешләрен кулланучы кешенең җәһәннәм утына төшәргә лаеклы булуын ассызыклаган.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

الَّذِينَ يَأْكُلُونَ الرِّبَا لَا يَقُومُونَ إِلَّا كَمَا يَقُومُ الَّذِي يَتَخَبَّطُهُ الشَّيْطَانُ مِنَ الْمَسِّ ۚ ذَٰلِكَ بِأَنَّهُمْ قَالُوا إِنَّمَا الْبَيْعُ مِثْلُ الرِّبَا ۗ وَأَحَلَّ اللَّهُ الْبَيْعَ وَحَرَّمَ الرِّبَا ۚ

---

[1] Имам әл-Бәйһакый, «Шүгаб әл-иман», 5130.

[2] Имам әт-Табарани, «Мүгъҗәм әл-әүсат», 6495.

فَمَن جَاءَهُ مَوْعِظَةٌ مِّن رَّبِّهِ فَانتَهَىٰ فَلَهُ مَا سَلَفَ وَأَمْرُهُ إِلَى اللَّهِ ۖ وَمَنْ عَادَ فَأُولَٰئِكَ أَصْحَابُ النَّارِ ۖ هُمْ فِيهَا خَالِدُونَ

**«Риба ашаучылар** [каберләреннән] **шайтан сугып еккан тиле кеше газапланган кебек кубарылырлар. Бу** [җәза] **аларга: «Сату-алу да риба кебек бит», – дигәннәре өчен. Хәлбуки, Аллаһы сату-алуны хәләл итте,** [акчаны акчага алыштырганда яки бер үк төрле малларны алмашканда] **рибаны исә харам кылды. Кем дә кем Раббысыннан аңа** [рибаны тыйган] **үгет-нәсыйхәт килгәннән соң,** [аңа ияреп, ялгышыннан] **ваз кичә, үткән нәрсә – аның үзе өчен** [рибадан алганнары соралмый]**. Аның эше – Аллаһыга** [калдырыла]**. Кем дә кем** [рибаны хәләл дип кабул итү фикеренә] **кайта, алар – Ут әһелләре. Алар – анда мәңге калучылар».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:275

Монда Аллаһы Тәгалә эшмәкәрлекне рөхсәт итә, әмма процентлы риба эшләрен тыя. Бу кешенең эшләү рәвешенә дә кагыла. Әгәр кеше, эшлим дип, кемнедер рәнҗетеп, кемнеңдер малын урлап яки исерткеч эчемлекләр сатып мал туплый икән, аның тапкан малы харам дигән сүз.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, безгә шелтәләнгән, тыелган күренешләргә мөнәсәбәтебезне үзгәртергә һәм Аллаһы Тәгалә билгеләгән чикләрне бозуның «зарурлыгына» сәбәпләр эзләмәскә кирәк. Һич онытырга ярамый: тыелган гамәлләрнең таралуы Кыямәт көнендә беркем өчен дә аклану булмаячак.

Шуңа күрә, газиз дин кардәшләрем, Аллаһы Тәгаләдән хәләл тормыш сорыйк. Аллаһы Тәгалә шушы сөйләгәннәрдән файда алырга насыйп итсен. Тормышыбызда фәкать хәләл ризык, хәләл кәсеп, хәләл мал гына булып, харамнан, рибачылыктан тыелып яшәргә насыйп кылсын. Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Альберт хәзрәт Мортазин,*

*Лаеш районының Пәрәү авылы мәчете имам-хатыйбы*

*22 август вәгазе,*

*сафәр аеның 28 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Малыбызда бәрәкәт булсын дисәк

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча мактауларыбыз галәмнәрне барлыкка китереп, аннан соң да бер генә мизгелгә дә Үзенең игътибарыннан калдырмаган, кешелек, җәнлек һәм башка бик күп төрле мәхлукатны барлыкка китереп, тәрбия кылып торган Раббыбыз Аллаһыга булсын! Шулай ук әйткән салаватларыбыз сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафага барып ирешсен!

Хөрмәтле мөселман кардәшләребез! Шөкер, без сезнең белән матур көзләргә якынлаштык: алтын башакларга тулы иген кырларыбыз, бакчаларыбызда – җәй буе үстергән яшелчә, җиләк-җимешләребез.

Шушы урында тукталып, бер вакыйга сөйләп үтәм: бервакыт олуг галим Ибраһим бине Әдһәм янына бер кеше килеп: «Мин күп гөнаһ кылам. Аларны кылмас өчен, миңа бер киңәш бирче», – дип сорый. Ибраһим бине Әдһәм: «Гөнаһ кылырга теләсәң, Аның ризыкларын ашама», – дип җавап кайтара. Бу кеше: «Моны ничек аңларга?» – дип сорый. Галим: «Гөнаһ кылмакчы булсаң, бар, кыл! Ләкин Аллаһы ризыгын ашама һәм Аның ризыкларыннан файдаланма», – дип җавап кайтара. Бу кеше яшь кенә бер егет була. Ул аптырап: «Мин моны ничек эшләрмен икән соң, бар нәрсә дә Аллаһы тарафыннан бирелгән бит?» – дип сорый. Ибне Әдһәм: «Аның ризыгын ашасаң, гөнаһ кылуның мәгънәсе бармы?» – дип сорый. Егет: «Дөрес әйтәсең шул. Миңа икенче киңәш бирче», – ди. Ибне Әдһәм дәвам итеп, болай дип әйтә: «Әгәр

Аллаһы каршында гөнаһ кылсаң, шул ук вакытта Аның ризыгын ашасаң һәм Аның суын эчсәң, ким дигәндә, Аның җирендә гөнаһ кылма». Бу егет: «Бу беренче киңәштән дә катлаулырак, чөнки барлык җир дә – Аллаһыныкы», – дип әйтә. Ибне Әдһәм: «Аның ризыгын ашаганда һәм Аның җирендә булганда, Аллаһы каршында гөнаһлы булырга мөмкинме?» – дип нәтиҗә ясап куя.

Чыннан да, дин кардәшләрем, без Аллаһының җирендә яшибез, Аллаһы биргән ризыклар белән тукланабыз, һәм шул ук вакытта Аллаһы каршында гөнаһлы булырга оялмыйбыз кебек. Ә Раббыбыз, шушы җир белән файдаланганыбыз өчен, анда нидер үстергән, төзегәнебез өчен, бездән Үзенә берәр нәрсә сораганы бармы? Юк бит, җәмәгать. Әгәр дә без, бу җирне файдаланып, анда берәр төрле үсемлекләр, җимешләр үстерсәк, Раббыбыздан бердәнбер әмер – мохтаҗ кешеләр турында онытмыйча, аларга да өлеш чыгар. Әйе, бүген без сезнең белән гошер садакасы турында сөйләшербез. Татарча без «гошер садакасы» дип сөйләшсәк тә, әмма гошерне садака белән бутарга кирәкми. Гошер – ул садака гына түгел, ул зәкятнең бер бүлеме. Башта зәкят хакында искә төшерик.

Гомумән, гарәп телендә «әз-зәкят» сүзенең мәгънәсе – «чистарыну» һәм «арту»; шәригатебездә исә ул билгеле бер нисабка ия булган кешенең мал-мөлкәтеннән билгеләнгән бер өлешне мохтаҗ булган мөселманнарга тапшыруны аңлата. Зәкят бары тик Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен бирелә.

Раббыбыз Аллаһы Тәгалә зәкят сүзен Коръәндә күп тапкырлар искә ала. Бу аның әһәмиятлелегенә басым ясый. Һәм гарәп телендә зәкят сүзе чистарынуны белдерә, дидек. Бу Коръәндә дә чагыла, мәсәлән:

قَدْ أَفْلَحَ مَن زَكَّاهَا

**«**[Нәфесен яхшы якка үзгәртеп, гөнаһлардан ерак тотып] **Аны арындырган кеше уңышка ирешкән».**

«Әш-Шәмс / Кояш», 91:9

Әлеге аятьне тулырак итеп карап киткәндә, Раббыбыз «Кояш» сүрәсендә болай дип әйтә: **«Җан һәм аны** [сөйләшү, ишетү кебек сәләтләргә ия сурәттә] **төзек кылучы** [Зат] **белән** [ант итмәен]**! Һәм аның күңеленә бозыклыкны һәм тәкъвалыкны салучы** [Зат белән]**.** [Шушындый әһәмиятле нәрсәләр белән ант итәмен, нәфесен яхшы якка үзгәртеп, гөнаһлардан ерак тотып] **Аны арындырган кеше уңышка ирешкән. Аны** [фасикълык баткаклыгы эчендә] **яшергән кеше зарар күргән».**

Димәк, күңелен пакьләп торучы мөселманнар уңышка ирешер, дип әйтә Раббыбыз. Әмма бу күңелгә генә карамый, бу безнең бөтен тормышыбызга кагыладыр. Шуңа да мәҗбүри булган садака да динебездә «зәкят» дип аталды, һәм аны Раббыбыз Аллаһы Тәгалә Үзе үк Коръәндә шулай диде:

وَأَقِيمُوا الصَّلَاةَ وَآتُوا الزَّكَاةَ وَارْكَعُوا مَعَ الرَّاكِعِينَ

> **«Намазны** [бөтен рөкеннәре белән җиренә җиткереп] **башкарыгыз,** [малларыгыздан] **зәкят бирегез һәм рөкүгъ кылучылар** [мөселманнар] **белән рөкүгъ кылыгыз».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:43

Һәм зәкятнең шулай аталуына килгәндә, галимнәребез моның ике хикмәтен күрсәтә:

1. Зәкят биргән кешенең малы, байлыгы чистарына.
2. Зәкят биргән кешенең малы артып барачак.

Зәкят – Аллаһы Тәгалә фарыз кылган бурычларның берсе, Ислам нигезләренең берсе. Аллаһы Тәгалә зәкятне Коръәни Кәримдә фарыз кылды. Фарызны үтәгән кеше олуг саваплы була, үтәмәгән кеше олуг гөнаһка ия, ә аны инкяр иткән кеше диннән чыга.

Шуңа да зәкятне без Раббыбыз ризалыгы өчен дип, бу гыйбадәткә тиешле игътибарны биреп башкарырга тиешбез. Бөтен гамәлне дә Раббыбыз ризалыгы өчен башкара башласак, аларны тормышка ашыру җиңелрәк була.

Чөнки без бу дөнья малына ябышкан, береккән, без аны яратабыз. Һәм аның белән бүлешкәндә, кемгәдер авыррак булырга мөмкин. Әмма бу маллардан да зуррак бүләк бар – Раббыбызның бездән риза булуы. Моны онытмасак иде.

Күп кенә галимнәребез, бигрәк тә фикһ галимнәре, зәкятне динебез нигезләре арасында өченче урынга куялар, ягъни: шәһадәт, намаз һәм аннан соң зәкят чыгару. Моңа югарыда китергән аять кебек башка аятьләр дә ишарә ясап тора, Раббыбыз Коръәндә зәкятне намаз белән бергә 32 урында искә ала: «Намаз укыгыз һәм зәкят чыгарыгыз», – ди.

Гошер зәкяте иген, барлык яшелчә-җимешләрдән һәм балдан билгеләнә. Бу зәкят төренең тиешлелегенә дәлил итеп галимнәребез Коръәндәге әлеге аятьне китерәләр:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا أَنفِقُوا مِن طَيِّبَاتِ مَا كَسَبْتُمْ وَمِمَّا أَخْرَجْنَا لَكُم مِّنَ الْأَرْضِ ۖ وَلَا تَيَمَّمُوا الْخَبِيثَ مِنْهُ تُنفِقُونَ وَلَسْتُم بِآخِذِيهِ إِلَّا أَن تُغْمِضُوا فِيهِ ۚ وَاعْلَمُوا أَنَّ اللَّهَ غَنِيٌّ حَمِيدٌ ﴿٢٦٧﴾

> **«Ий иман китерүчеләр!** [Кәсеп итеп] **Тапканнарыгызның иң яхшыларын** [хәләлләрен] **һәм Безнең сезнең өчен җирдән чыгарган нәрсәләребездән** [садака итеп] **сарыф итегез. Үзегезгә биргән чакта күзегезне йомып кына алырдай яраксыз нәрсәне бирергә тырышмагыз. Белегез, һичшиксез, Аллаһы –** [беркемгә дә Мохтаҗ булмаучы] **Бай, Мактауга лаеклы».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:267

Димәк, газиз дин кардәшләрем, әгәр кеше ниндидер яшелчәләр, җиләк-җимешләр үстерә икән, аннан бер өлешен чыгарып, мохтаҗларга бирү аның өчен вәҗиб була башлый. Җиләкләр, яшелчәләр бакчада да, кырда да яки парникларда да үстерелергә мөмкин – барысыннан да өлеш чыгарылырга тиеш. Үстерүче кеше фәкыйрьме, баймы – анысы мөһим түгел.

Ягъни кеше үзе мохтаҗ булса да, әмма Аллаһының рәхмәте белән бакчасында бәрәңге, кабак булса да үстерә алган икән, ул шуның бер өлешен гошер итеп бирә; һәм, үзенә кирәк булса, башкалардан шулай ук гошер кабул итеп ала ала.

Гошер итеп җыелган уңышның уннан бер яки егермедән бер өлеше бирелә. Әгәр дә кеше җиләк-җимешләрне үзе көч куеп, үзе су сибеп үстерә икән, ул егермедән бер өлешен мохтаҗларга чыгара. Мәсәлән, 20 капчык бәрәңгенең берсен бирә. Ә әгәр дә бу тәрбия таләп итми торган төр үсемлек булса, мәсәлән, аны утыртып җибәрдең дә, ул үзеннән-үзе үсә, аны утарга да кирәкми, суын да сибәргә кирәкми, яңгыр гына җитә икән, мондый очракта уннан бер өлешне мохтаҗларга чыгарырга кирәк (мәсәлән, 10 чиләктән 1 чиләк). Балның шулай ук уннан бер өлеше мохтаҗларга гошер итеп бирелергә тиеш.

Үстергән кайбер җимешләребез тиз өлгерә һәм аның вакыты да тиз чыга, алар тиз бозыла. Бу очракта аларны җыеп алу белән үк гошер чыгарырга мөмкин. Мәсәлән, синең бер чиләк җиләк уңышың бар икән, аның да бер өлешен, аз чыкса да, гошер итеп бирергә була. Күрше-күлән, дусларыбызны сыйларга мөмкин. Әгәр ниндидер җимешне гошер итеп бирү уңайсыз булса яки кеше аннан гошер чыгарырга өлгерми калса, ул шуның бәясен санап чыгарып, гошерне акчалата да тапшыра ала. Шулай ук уңыштан как ясап, киптереп яки тозлап та (тозлы кыяр, кәбестә) гошерне чыгарырга мөмкин, бу да дөрес булыр, иншәАллаһ.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, гошерне кемгә бирергә ярый соң? Кабатлап китәм: гошер – ул зәкят, садака түгел, аны без садака биргән кебек кенә бирергә тиеш түгел. Аның үз кагыйдәләре бар. Ягъни, зәкятне кемнәргә чыгарырга тиешле булса, гошерне дә шуларга бирергә ярый, зәкяткә нинди чикләр куелса, гошергә дә шулар карый. Димәк: гошерне үз әти-әниеңә, әби-бабаларыңа, балалар-оныкларыңа бирә алмыйсың, чөнки бу туганнар болай да бер-берсен тәэмин итәргә тиешле. Әмма бер туган һәм туганнан

туган абый-апа, сеңелләреңә яки абзый-апаларыңа (русча әйткәндә дядя һәм тетя), күршеләреңә бирергә ярый. Гошер алучы кеше зәкят алырга хокуклы булырга тиеш: бай (ягъни нисаб күләменә ия, зәкят бирүче кеше) булмаска; үз акылында булган, балигълыкка ирешкән мөселман булырга тиеш.

Газиз дин кардәшләрем, безнең алган бар нигъмәтләребез, үстерә алган уңышларыбыз – барысы да Аллаһы Раббыбызның рәхмәте генә. Куркыныч корылык килсә, суларыбыз кипсә, нинди генә акчалар түләргә риза булсак та, без берни үстерә алмас идек. Шуңа да, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтебезне белдереп, киләчәктә дә Аның бу нигъмәтенә ирешү, уңышлы булу өчен, Аның боерыгына буйсынып, гошерләребезне бирергә тырышыйк. Шул ук вакытта без бит мохтаҗ булган якыннарыбыз, күршеләребез, авылдашларыбыз яки мәдрәсә шәкертләренә ярдәм итәбез. Аларның рәхмәтләрен, изге догаларын ишетәбез, җәмгыятебездә дуслык ныгый. Гошер садакасы безнең күңелне саранлыктан, комсызлыктан арындыра, мәрхәмәтлелек һәм юмартлык сыйфатларын үстерергә булыша.

Инкыйлабка кадәр татар авылларында гошер садакасын җыю гадәти күренеш булган, совет чорында ул онытылып торса да, әлхәмдүлилләһ, бүген һәрберебез аерым, үзе теләгән кешесенә дә гошер тапшыра ала, андый кешене тапмыйм дисә, мәдрәсәләргә ярдәм итәсе килсә, Диния нәзарәте республикабыз буенча гошер садакасын җыюны оештыра. Мәсәлән, Татарстан мөселманнары тарафыннан 2017 елда – 160 тонна, 2018 елда – 600 тонна, ә 2023 елда – 827 тонна гошер садакасы җыелган. Гадәттә, безнең җирлектә гошерне бәрәңге алганнан соң җыя башлыйлар. Мәсәлән, Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды бу эшне бик җентекләп башкара. Алар ярдәмендә мәчетләребездә халыктан яшелчә-җимешләр кабул итеалә һәм соңыннан мәдрәсәләр, мохтаҗ мөселман гаиләләренә таратып бирелә.

Газиз дин кардәшләрем, югарыда без «әл-Бәкара» сүрәсенең 267 нче аятен, ягъни гошер садакасын түләү турындагы аятьне, искә алган идек. Без, әлбәттә, нәфесебезгә ияреп, фәкыйрьлек килер дип яки бу бит мин тырышып

үстергән бәрәңгеләр дип, артка да чигенер идек. Шуңа да Раббыбыз аннан соңгы аятьтә болай дип дәвам итә:

الشَّيْطَانُ يَعِدُكُمُ الْفَقْرَ وَيَأْمُرُكُم بِالْفَحْشَاءِ ۖ وَاللَّهُ يَعِدُكُم مَّغْفِرَةً مِّنْهُ وَفَضْلًا ۗ وَاللَّهُ وَاسِعٌ عَلِيمٌ

**«Шайтан** [күңелегезгә вәсвәсә салып] **сезгә фәкыйрьлек вәгъдә итә һәм** [котыртып] **яманлыкны** [саранлыкны] **боера. Аллаһы исә** [иң яраткан нәрсәләрегезне Аның юлында биргән очракта] **сезгә Үз катыннан мәгъфирәт һәм фазыл вәгъдә итә. Аллаһы – чиксез Мәрхәмәт** [һәм Белемнәр иясе]**,** [һәрнәрсәне] **Белүче».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:268

Раббыбыз Аллаһының вәгъдәсе хак! Гошер садакаларыбызны вакытында биреп, тапшырып, өстебездән бу бурычны да төшерергә насыйп булсын. Аллаһы Тәгалә безгә бәрәкәтле мал биреп, байлык биреп, безне садакалар, зәкятләр бирүчеләр рәтеннән кылса иде. Әмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев,*

*Арча районы Хәсәншәех авылы мәчете имам-хатыйбы*

*29 август вәгазе,*

*рабигыль-әүвәл аеның 6 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Мәүлид ән-Нәби

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Бөтен галәмнәрнең Тәрбиячесе булган Аллаһы Раббыбызга биниһая хәмед-сәна, шөкраналарыбыз булса иде. Безнең өчен һәр хәлебездә иң күркәм үрнәк булган нурлы пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренә, аның хөрмәтле әһленә, сәхабәләренә күңел түрләребездән чыккан сәламнәребез, салаватларыбыз һәм һәртөрле изге догаларыбыз булса иде.

Газиз дин кардәшләрем, рабигыль-әүвәл аеның 11 нән 12 нә булган киче – Ислам дөньясында зур тантана, бөтен дөнья мөселманнарының мөбарәк бәйрәме. Бу төнне сөекле пәйгамбәребез хәзрәти Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм дөньяга килгән. Рабигыль-әүвәл аенда мөселманнар күркәм мәҗлесләрдә җыелып, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең яшәү рәвеше, әхлагы турындагы аять-хәдисләрне укыйлар, салаватлар әйтәләр, догалар кылалар.

Мәүлид бәйрәмен (Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең туган көненә багышланган мәҗлес) беренче тапкыр XII–XIII гасырларда Ирбил шәһәрендә үткәрә башлаганнар. Шул шәһәрнең ихласлы хакиме Малик Мөзәффәр Әбү Сәгыйд Күкбүре Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне бик сөйгән һәм аның шәфәгатен өмет итеп, касыйдәләрне (Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышында булган

әһәмиятле вакыйгалар турындагы поэмаларны) укыр өчен диндар галимнәрне үзе янына җыйган. Шулай итеп, Мәүлидкә нигез салган.

Касыйдәләрне гарәп һәм үз телләрендә укыйлар. Мәүлид бәйрәмендә төрле ризыклар әзерләнә, мохтаҗларга, ятимнәргә садакалар, киемнәр бирелә. Бу изге гамәлләрне кылган мөселманнар савапка ирешер, иншәАллаһ.

Кызганычка, кайбер кешеләр, Коръәнне һәм хәдисләрне дөрес аңламыйча, Мәүлидне уздыру куркыныч бидгать дип әйтәләр. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм аның сәхабәләре заманында Мәүлид бәйрәме бер дә үткәрелмәгән, диләр. Моңа дәлил итеп, пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисен китерәләр: «Насаралар Гайсәне олылаган кебек, мине алай олыламагыз», – ягъни илаһилаштырмагыз. Бу хәдискә таянып, Мәүлидне Раштуага тиңлиләр яки потка табыну белән чагыштыралар. Әлеге фикер дөреслеккә туры килми. Беренчедән, сәхабәләр заманында билгеләнгән көнне җыелырга һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышы турында сөйләргә, ишетергә ихтыяҗ булмаган, чөнки Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тарафдарлары аны һәр көнне күргәннәр һәм һәрвакыт аның янында булганнар. Бер тапкыр Аллаһы Тәгаләнең Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәти Гомәр бине әл-Хаттаб радыяллаһу ганһедән: «Син Аллаһыдан соң кемне күбрәк яратасың?» – дип сораган. Сәхабә: «Алдан үземне, аннары сине, йә Расүлуллаһ», – дип җавап биргән. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Йә Гомәр, синең ихласлыгың зәгыйфь», – дигән. Шуннан соң Гомәр бине әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе: «Алай булгач, Аллаһыдан соң дөньядагы бөтен нәрсәдән күбрәк сине яратам!» – дигән. «Менә хәзер инде синең ихласлыгың көчле», – дип әйткән Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм.

Ибне Һишам Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышы турындагы китабында: «Сәхабәләр Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмне шулкадәр нык яратканнар ки, хәтта азанда «Мөхәммәд

Расүлуллаһ» дигән сүзләр яңгырагач, аларның күңелләре Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата мәхәббәт белән тула һәм алар елый башлыйлар иде», – дип язган. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең вафатыннан соң, һәрвакыт мөселманнарны намазга чакыручы Биләл радыяллаһу ганһе исемле сәхабә нәкъ менә шушы сәбәп аркасында азан әйтүен дәвам итә алмаган.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм гади кеше булмаган, ул бөтен мәхлуклар өчен Аллаһы Тәгаләнең сайланган Расүле иде. Аллаһы Раббыбыз Коръәндә болай дип әйтә:

إِنَّ اللَّهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ ۚ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيمًا

«**Һичшиксез, Аллаһы һәм фәрештәләре Нәби салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтәләр.** [Шулай итеп, Аллаһы Тәгалә аңа рәхмәтләр һәм бәрәкәтләр яудыра, фәрештәләр исә аңа югары теләге белән дога кылып, шәрәф казана һәм аның зикере белән бәрәкәтләнәләр]**. Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм** [«Ий Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] **сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:56

Мөхтәрәм җәмәгать, шуны онытмыйк! Әгәр без сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Сөннәтенә иярсәк, аның тормышыннан үрнәк алып яшәсәк, иншәАллаһ, Раббыбызның рәхмәтенә һәм ризалыгына ирешербез. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

قُلْ إِن كُنتُمْ تُحِبُّونَ اللَّهَ فَاتَّبِعُونِي يُحْبِبْكُمُ اللَّهُ وَيَغْفِرْ لَكُمْ ذُنُوبَكُمْ

«[Расүлем!] **Әйт: «Әгәр сез Аллаһыны сөясез икән, миңа иярегез, шулвакыт Аллаһы да сезне сөячәк һәм гөнаһларыгызны гафу итәчәк».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:31

Икенчедән, Мәүлидне Гайсә галәйһиссәламне олылау, «илаһилаштыру» белән чагыштыру, бер сүз белән әйткәндә, наданлык булыр иде. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең туган көненә багышланган нинди дә булса чараларны үткәрүне потка табыну белән бер дигән сүзләр Ислам динен мәсхәрә итү була. Мондый сүзләрне фәкать белемсез, надан кешеләр яисә Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең дошманнары гына әйтә ала.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе дә туган көнендә, ягъни дүшәмбе көнне, ураза тота торган булган. Аннан: «Йә Расүлуллаһ, ни өчен син дүшәмбе көнне ураза тотасың?» – дип сораганнар. Пәйгамбәребез: «Мин бу көнне тудым һәм бу көнне миңа вәхи иңдерелде»[1], – дигән. Белгәнебезчә, ураза тоту – ул Ислам терәкләренең берсе. Моннан күренә ки, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең туган көнен гыйбадәттә үткәргән.

Хөрмәтле мөселманнар! Фәнни әдәбиятта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм турындагы беренче шигъри әсәрләрне төрки шагыйрьләр иҗат иткән дип санала. Рәсәй мөселманнары арасында төрек шагыйре Сөләйман Чәләбинең Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә багышланган «Вәсиләтүн-нәҗәт» исемле поэмасы (1409 ел) киң таралган булган. Әлеге поэма 1917 елга кадәр Казанда алты тапкыр нәшер ителгән. Татар телендә дә мәүлидләр язылган. Бу әсәрләрне шагыйрьләр генә түгел, ә мәдрәсәдәге остаз һәм шәкертләр дә иҗат иткән. Мәсәлән, Казанда 1861 елда «Мәүлиден-нәби» («Хәзрәти Расүлнең дөньяга килгәнен һәм дөньядан күчкәнен бәян иткән мөбарәк китаптыр») дип исемләнгән шигъри әсәр бастырылган. Бу әсәрләрне бик матур итеп көйләп укыганнар.

Бүгенге көндә Мәүлидне бәйрәм итү гадәтләре кайтарыла башлады. Авылларда гына түгел, шәһәрләрдә дә Мәүлидләрне уздыралар. Күпчелек галимнәребез: «Мәүлид уку – Исламның бик яхшы һәм файдалы гадәте.

[1] Имам Мөслим.

Ул мөэминнәр арасындагы аралашу, аларның иманы өчен ышандыргыч дәрес, кешеләр йөрәгендә Аллаһыга һәм Аның соңгы расүле Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата мәхәббәт уяту», – дигәннәр.

XX гасыр башында татар телендә иҗат ителгән мәүлид касыйдәсендә шундый юллар бар:

*Укылырса Мәүлиддә махсус касыйдә һәр заман,*
*Ул Расүлнең рухы хуш-нуд булачактыр бел, фәлән.*

Мәүлид бәйрәмендә укылган дога, аять, хәдисләр, мөнәҗәтләребез өчен генә түгел, Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен кылынган барлык изге гамәлләребез өчен, сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең рух-шәрифләре шат булса иде. Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*
*Казанның Саләх мәчете имам-хатыйбы*

*5 сентябрь вәгазе,*

*рабигыль-әүвәл аеның 13 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Шәригать чыганагы буларак Коръән

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Раббыбыз Үзенең Китабында болай дип әйтә:

إِنَّا نَحْنُ نَزَّلْنَا الذِّكْرَ وَإِنَّا لَهُ لَحَافِظُونَ

**«Һичшиксез,** [алар инкяр иткән] **Коръәнне Без иңдердек һәм Без** [бүтән китапларыбыз арасыннан] **аны** [гына үзгәртелү, югалудан] **саклыйбыз».**

«Әл-Хиҗр», 15:9

Әйе, бу сүзләр бөек Коръән турында. Әлеге Китап – тормышыбызның, яшәешебезнең нигезе. Алай гына түгел, Бөек Раббыбыз Коръәни Кәримне Ислам диненең нигезе итеп кылды. Бүген шушы бөек Китап турында сөйләшеп, кайбер мәгълүматны искә төшереп китик.

Коръән Раббыбыздан Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Җәбраил фәрештә галәйһиссәлам аша иңде. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам аны сәхабәләренә өйрәтте, әйтеп яздырды. Сәхабәләр аны соңыннан Пәйгамбәрнең үзенә укып күрсәтә торган булганнар. Шул рәвешле Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм, алар берәр хата, ялгышлык җибәрсә, шунда ук әйтә, төзәтә алган. Раббыбыз Коръәндә һәрнәрсә турында гыйлем урнаштырды, туры юлны күрсәтте. Коръән – хикмәт чыганагы,

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аллаһының Илчесе икәнлегенә дәлил, акыл ияләре өчен яктылык чыганагы.

Галимнәребез Коръәнгә түбәндәге аңлатманы бирәләр: «Ул – Аллаһы Тәгаләнең барлыкка китерелмәгән Сөйләме, могҗиза; пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең йөрәгенә иңгән; аны уку – гыйбадәт; ике тышлык арасында язылган, тәвәтүр ысулы белән тапшырылган, иң кыска сүрәсе дә кабатланмас булып тора (Коръәннең иң кыска сүрәсенә дә тиңдәш бернәрсә язып булмый)». Нәрсә ул тәвәтүр ысулы? Тәвәтүр – тапшыручылар арасында ялганлау турында сүз куешу мөмкин булмаган хәлдә, теге яки бу хәбәрне бөтен нечкәлекләренә кадәр буыннан-буынга тапшыру дигән сүз.

Газиз дин кардәшләрем, Коръән – хикмәт чыганагы, дидек. Чөнки Коръәнне белүче кеше шәригатьнең гомуми белемнәренә дә ия була ала. Раббыбыз Коръәндә Пәйгамбәребезгә болай ди:

وَنَزَّلْنَا عَلَيْكَ الْكِتَابَ تِبْيَانًا لِّكُلِّ شَيْءٍ وَهُدًى وَرَحْمَةً وَبُشْرَىٰ لِلْمُسْلِمِينَ

**«Без бу Китапны сиңа** [дин мәсьәләсендә кешеләр мохтаҗ булган] **барлык нәрсәнең бәяны, мөселманнар өчен һидаять, бер рәхмәт һәм бер сөенеч итеп иңдердек».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:89

مَّا فَرَّطْنَا فِي الْكِتَابِ مِن شَيْءٍ

**«Без Китапта һичбер нәрсәне төшереп калдырмадык».**

«Әл-Әнгам / Терлек», 6:38

Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай дип әйтә: «Бу Коръән – Аллаһының ныклы арканы, ачык яктылык, файдалы дәва, аңа тотынган кешегә саклану чарасы, аңа ияргән кеше өчен котылу. Ул, аны төзәтсеннәр өчен дип, (нәрсәгә дә булса) яраклашмый;

шелтәләнүдән куркып, хакыйкатьтән читләшми, һәм еш укылганнан һич тә зәгыйфьләнми».

Пәйгамбәребезнең сәхабәсе Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Белем алырга теләсәгез – Коръәнне өйрәнегез, чөнки анда беренчеләрнең дә, соңгыларның да белеме бар».

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм ошбу Китаптагы Аллаһының әмерләрен безгә аңлатып биргән, тәфсир кылган. Шуңа күрә пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә буйсыну – ул Аллаһы Тәгаләгә буйсыну. Аллаһыга буйсынудан да олы буйсыну юк.

Әлбәттә, без, гади кешеләр, Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә белән турыдан-туры аралашып, Аның әмерләрен белә алмыйбыз. Шулай ук хәзерге вакытта Аллаһы Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә мөрәҗәгать итү дә мөмкин түгел. Димәк, безгә Коръән белән Сөннәткә һәм шушы Коръәнне, Сөннәтне тирәнтен өйрәнеп, Пәйгамбәребез әйткәнчә, сәхабә, табигыйннәр, олуг галимнәргә ияреpгә кала.

Коръән аятьләре арасында, әйткәнебезчә, ачык булган һәм мәгънәләре ачыкланып бетмәгәннәре дә бар.

Ачык булган мәсьәләләргә килгәндә, ул хөкемнәр Коръәндә һәм хәдисләрдә ачык күрсәтелгән, һәм кеше аларны үзе дә белергә мөмкин. Алар өчен иҗтиһад (яңа хөкем чыгару) кирәкми.

Ләкин, әйткәнебезчә, чишелеше катлаулы булган хөкемнәр дә бар. Аларга килгәндә, гади халык тирән гыйлемле олуг галимнәрнең фикеренә иярә.

Галим кешеләр артыннан иярүне шәригатьтә «тәкълид» дип атыйлар, ул «кемдер артыннан бару, иярү» дигәнне аңлата. Без аны үз тормышыбызда көндәлек кылабыз: табибларга барып, беребез дә: «Мине шулай итеп дәвала, мин медицина китапларында шулайрак укыдым», – дип; яки адвокатка: «Мине судта яклаганда шушы рәвешле якла», – кебек сүзләрне әйтмибездер!

Гаделлек белән уйлап караганда, Коръән аятьләрен үзебез аңлаганча тәфсир кылу – бик куркыныч, чөнки анда адашу мөмкинлеге бик зур. Ә икенче юлга килгәндә, имам-мөҗтәһидләр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә һәм сәхабәләр заманына якынрак яшәгәннәр, шуңа күрә аларга Коръәнне аңлау җиңелрәк булган. Икенчедән, безнең белемебез һәм истә калдыру сәләтебез аларның белемнәре белән чагыштыргысыз. Без, еш кына кибеткә бер-ике әйбер алырга дип чыгып китеп тә, барып җиткәч, ни кирәклеген озак кына искә төшерә алмыйча басып торабыз. Яки берәрегезгә хәзер 5–6 урынлы бер-ике сан әйтсәм, кайсыгыз шуны, башка онытмаслык итеп, истә калдыра ала? Шуңа да яраткан мисалым бар, сезгә дә шуны китерәсем килә: елга кайсы урында чистарак? Чишмәгә якын урынындамы, әллә инде берничә дистә чакрым киткәчме? Әлбәттә, чыккан урынында, чишмәгә якын булган урынында. Шуңа да, имам-мөҗтәһидләребезгә, ягъни мәзһәб галимнәренә, ышаныч күпкә зуррак булырга тиеш.

Коръән хакында сөйләшүебезне дәвам иткәндә, аның турында берничә кызыклы мәгълүматны искә алып китик. Мәсәлән, Коръән Аллаһыдан иңдерелгән башка китаплар кебек тулы бер язма буларак иңмәгән.

وَقُرْآنًا فَرَقْنَاهُ لِتَقْرَأَهُ عَلَى النَّاسِ عَلَىٰ مُكْثٍ وَنَزَّلْنَاهُ تَنزِيلًا

**«Без, Коръәнне син аны кешеләргә ашыкмыйча укысын өчен, бүлгәләдек һәм аны өлешләп иңдердек».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:106

Коръән Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, Муса галәйһиссәламгә Тәүрат берьюлы бер тулы китап булып иңгән кебек, иңмәде. Өлешләп-өлешләп, ниндидер вакыйгаларга бәйле булып та иңде. Мәсәлән, **«Синнән ятимнәр турында сорыйлар»** («Әл-Бәкара / Сыер», 2:220); **«**[Расүлем!] [Байлар] **Синнән** [малларын] **ничек сарыф итәргә кирәклеген сорыйлар»** («Әл-Бәкара / Сыер», 2:215), **«Синнән ганимәтләр турында сорыйлар»**

(«Әл-Әнфәл / Табышлар», 8:1) кебек аятьләр үзләре үк аларның кайсы вакытта, нинди сорауга җавап буларак иңгәннәрен күрсәтә.

Шулай ук Коръәннең беренче булып иңгән аятьләрен дә барыбыз да яхшы беләбез, бу «әл-Галәк» сүрәсенең беренче биш аяте, алар Хира мәгарәсендә иңә. Коръәннең соңгы булып иңгән аяте буенча берничә төрле фикер бар. Бер төркем галимнәр Коръәннең соңгы иңгән аяте дип «әл-Маидә» сүрәсенең 3 нче аятен атыйлар:

الْيَوْمَ أَكْمَلْتُ لَكُمْ دِينَكُمْ

**«Бүген сезнең өчен динегезне камил иттем...»**

«Әл-Маидә / Табын», 5:3

Шулай ук Коръәндәге аятьләрне Мәккә чоры һәм Мәдинә чоры аятьләренә бүлеп өйрәнәләр. Коръәнне өйрәнүче галимнәр арасында боларга карата берничә фикер бар. Иң киң таралганы: Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәдинәгә күчкәнчегә кадәр иңгән аятьләр – Мәккә чорына, ә һиҗрәттән соңгылар Мәдинә чорына карый. Аларның һәр икесенә хас аерым үзенчәлекләре дә бар. Мәсәлән, эчтәлек аермалары: Мәдинә аятьләре күпчелек очракта дини әмерләрне (фарызларны, тыюларны), җәза чараларын һәм гаделлек принципларын аңлата. Мәккә аятьләре Аллаһының барлыгына дәлилләр, бер Аллаһыга гына гыйбадәт кылырга чакыру, күпаллалыкка тәнкыйть, күңелләрне пакьләү, әхлакка өндәү турында.

Коръән аятьләре иңә генә башлаган вакытта гарәпләр мөшрикләр булган. Алар үзләре үк ясаган потларга табынган. Аларда ахирәт тормышы, Кыямәт көне, җәннәт һәм җәһәннәм турында белем булмаган. Шуңа күрә алар мирас бүлү, сату-алуга караган һәм башка шәригать кагыйдәләрен кабул итәргә әзер булмаган. Аларның хәле, беренче чиратта, күпаллалыкка ышанудан һәм явыз гадәтләрдән арынуны таләп иткән. Шуңа күрә Аллаһы Тәгалә аларга Кыямәт көненең куркынычлыгын, җәннәт нигъмәтләрен һәм

җәһәннәм газабын, элекке кавемнәр турында вакыйгалар, кыйссалар, шулай ук үзләре һәм тирә-якның барлыкка килүе турында уйландыра торган аятьләр иңдергән. Яки, мәсәлән, Мәккә аятьләрендә күбрәк «Ий кешеләр!» яки «Ий Адәм балалары!» дип мөрәҗәгать ителсә, Мәдинә аятьләрендә күпчелек очракта «Ий иман китергән бәндәләр!» дип әйтелә.

Вәгаземнең азагында кабаттан Аллаһының Китабы турында гомуми итеп әйтәсем килә: Коръән – Аллаһының Китабы, аны уку гыйбадәт була. Без бөтенебез дә галим-мөҗтәһидләр була алмабыз. Әмма безнең өчен бу Китапны өйрәнеп, аның буенча кануннар чыгарып калдырган, безнең өчен эшне җиңеләйткән олуг галимнәребез булган. Безгә, гади мөселманнарга, гарәпчә хәрефләрне өйрәнеп, акрын-акрын аны укырга өйрәнәсе иде әле. Һәрбер укылган хәрефе өчен 10 әҗер язылачак диде Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм. Раббыбыз шушы кечкенә эшләрдән булса да безгә башлауны насыйп итсә иде. Әмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*ТР МДНнең Дәгъват бүлеге*

*12 сентябрь вәгазе,*

*рабигыль-әүвәл аеның 20 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Вакыт илә бәхет

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Хак Аллаһы Тәгаләгә бар мактауларыбыз, шөкраналарыбыз булса иде! Аңа гына тәвәккәл кылабыз вә үзебезнең нәфесебездә булган яманлыклардан бары Аңа гына сыенабыз. Вә Аллаһы Тәгаләдән бу дөньяда да, ахирәттә дә бары тик яхшылыклар гына сорыйбыз. Аллаһы Тәгаләдән башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк икәнлегенә шәһадәт китерәбез. Барча гыйбадәт, сәҗдә, дога Аллаһы Сөбеханә вә Тәгаләгә генә юнәлергә тиеш икәнен таныйбыз. Һәм иң яхшы үрнәк булып торган Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең дә Аллаһы Тәгаләнең илчесе, расүле вә колы икәненә шәһадәт китерәбез. Ул шәхес үз тормышында Коръәнне кулланып, күркәм Ислам динен күрсәтеп китә алды.

Хөрмәтле җәмәгать, Аллаһы Тәгалә безнең бәндәчелек белән белеп, белми кылган гөнаһларыбызны кичерсен, ошбу җомга көннәребезне мөбарәк әйләсен!

Безнең Ислам динебез кешенең бу дөньяда бәхетле булуына күп ишарәләр кыла. Ул кешенең ничек итеп бәхеткә ирешә ала алганын күрсәтә ала. Әлбәттә, без бу бәхетне төрле юллар белән сорый алабыз һәм иң кимендә «Фатиха» сүрәсен укыганда болай дип әйтәбез:

اهدِنَا الصِّرَاطَ المُستَقِيمَ

**«**[Ий Раббыбыз!] **Безне туры юлга күндер»**.

«Фатиха / Ачучы», 1:5

Шушы туры юлда барган вакытта, без Ислам динендәге кайбер кадерле булган әйберләр белән танышабыз. Бүген без Коръән аятьләреннән, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләреннән вә сәхабәләрнең тормыш рәвешеннән билгеле булган бер нигъмәт – вакыт нигъмәте – турында сөйләшеп китәрбез.

Вакыт нигъмәте кешеләрне бу дөньяда үзләрен бәхетле итеп хис итәргә ярдәм итә. Ничек? Әгәр дә кеше бу дөньяда үзенең төп морад-максатларын, көненең ни рәвешле үтәсен, вакытын нигә сарыф итәсен белә икән, шул вакытта ул үзен эшендә, акча туплавында, гаиләсендә, үзенең гомерендә бәхетле тоя башлый, ягъни аларның тәмен сизә башлый. Әгәр кеше үзенең морадын югалтса: эшендә ни өчен эшләгәнен аңламаса, кәсебен нинди ният белән башкарганын белмәсә, гаиләсендә, гомерендә һ. б. өлкәләрдә үзенең төп мәгънәсен югалтса, шулвакытта, һичшиксез, үзенең яшәү тәмен дә югалта башлый.

Хәсән әл-Басри исемле мәшһүр табигыйн: «Ий адәм баласы, син бары тик көннәр. Һәм бер көн китү белән, синең җәсәдеңнән дә бер өлеш киткән сыман», – дип әйткән. Ягъни, бер көн үтү белән, безнең гомернең дә бер өлеше кими. Кадерле җәмәгать, бу һичшиксез шулай. Безнең картлыгыбыз килә, ә яшьлегебез китә. Без тырыша-тырыша сәламәтлегебезне, көннәребезне сарыф итеп, мал-мөлкәт кәсеп итәбез. Ә вакытны тотып карап булмый. Аның үткәнен кесәбездәге мал-мөлкәткә карап, гаиләбезгә карап кына тоеп, чамалап була. Шуларга вакытны күп сарыф итеп, без тормышыбызны сарыф иткән шикелле булабыз.

Әгәр дә кешенең күпмедер мал-мөлкәте булып, ни дә булса кылырга мөмкинчелекләре бар икән, һәм ул аларны дөрес юлда кулланса, менә шушы вакытта кеше үзен чын мәгънәсендә бәхетле итеп сизә башлый.

Шулай ук Хәсән әл-Басри көн исеменнән кешеләргә мөрәҗәгать итеп: «Ий адәм балалары, мин сезгә барлыкка китерелгән яңа мәхлук – көн. Һәм мин синең гамәлләреңә шаһитмын: синең изгелегеңне вә кимчелегеңне күреп торам. Чынлыкта, мине (һәрбер яңа көнне) файдаланып кал. Әгәр дә мин синең каршыңнан чыгып китсәм, син мине Кыямәт көненә кадәр кайтара алмассың (көн үткәч, аны кайтарып булмый)», – дип әйтә.

Дөрестән дә, Аллаһы Тәгалә һәр көн саен безгә Кыямәт көненә, мәңгелек тормышыбызга әзерләнер өчен мөмкинлекләрен биреп тора. Бу мөмкинлекне ничек кулланасын Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм өйрәтеп калдырды, ә сәхабәләр аның Сөннәте буенча үзләренең үрнәкләрендә яшәп күрсәттеләр. Алар Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янәшәсендә яшәгәннәр һәм алар аның гамәлләрен түкми-чәчми җыеп барганнар. Онытмыйк, безнең кулыбызда Коръәни Кәрим бар, Сөннәт бар, үрнәк затларның тормыш тарихы бар.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер сәхабәдән: «Ий Мөгаз, син бүген ничек уяндың, ничек итеп бу иртәне каршы алдың?» – дип сорый. Хәзрәти Мөгаз бине Җәбәл радыяллаһу ганһе: «Чынлыкта, мин бу иртәне хак мөэмин буларак каршы алдым», – дип җавап кайтара. Җавабына игътибар итсәк, аның иртәсе иманына бәйләнгән икәнен күрәбез. «Хак мөэмин буларак», – дип әйтә ул. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хикмәт иясе иде, ул янә: «Һәрбер әйбернең хакы бар. Иманның да хакы бар. Ул мәсьәләдә нәрсә әйтерсең?» – дип сорый. Мөгаз радыяллаһу ганһе: «Мин үз вакытыма болай карыйм: иртән торсам, кичкә кадәр яшәрмен, дип уйламыйм. Кичкә кадәр яшәп, йокларга ятсам, иртәгә кадәр яшәрмен, дип уйламыйм», – дип җавап кайтара.

Бу, җәмәгать, күңел төшенкелеге түгел. Бу – вакытның кадерен белү, бүген эшләргә планлаштырылган эшләрне кичкә, иртәгәгә калдырмау, үзеңнең гомереңнең кыска икәнен аңлау. Хәзрәти Мөгаз радыяллаһу ганһенең бу сүзләре белән: «Намазымны укып калыйм, уразамны тотып

калыйм, Коръәнне укып, изге гамәлләр кылып, Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән хәерле гыйлем алып калыйм, кәсебемне кылыйм, гаиләм белән булыйм», – дип әйтүе иде. Алга таба, сүзен дәвам итеп, Мөгаз радыяллаһу ганһе болай дип әйтә: «Чынлыкта, мин бер адымымны ясаганда, икенчесен ясый алачагым хакында белмим. Минем өчен кешелек дөньясы бүгенге көндә үк Кыяматтә кебек. Менә алар, китапларын тотып, җавап бирергә әзерләнеп торалар. Минем күз каршымда җәннәт, анда кешеләр нигъмәтләнәләр. Минем каршымда җәһәннәм, анда кешеләр газапланалар».

Менә бу сүзләр Мөгаз бине Җәбәл радыяллаһу ганһенең күңелен ачып күрсәтә: ул үзен инде Кыяматтә дип хис итә, җавап бирәчәген ачык аңлый, үзен җәннәттә һәм җәһәннәмдә күзаллап, нинди җәзалар һәм нигъмәтләр көтүен яхшы аңлый. Моңа ул ничек ирешә алган? Әлбәттә, үзенең тормышына, вакытына игътибар итү сәбәбендә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәти Мөгазга: «Чынлыкта, син динне аңладың, шунда нык бул!» – дип әйтә.

Мөгаз бине Җәбәл радыяллаһу ганһе иң бөек сәхабәләрнең берсе була. Ул Ислам динен 18 яшендә Мосгаб бине Гомәйрадан кабул итә.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Минем өммәтемдә иң шәфкатьлесе – Әбү Бәкер. Диндә иң нык торучы – Гомәр. Иң тәкъва – Госман. Шәригатьнең бар нечкәлекләрен белүче – Гали. Барыннан да яхшырак харам белән хәләлне аеручы – Мөгаз бине Җәбәл», – дип әйтә.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мөгаз радыяллаһу ганһене Йәмән җирлегенә укытучы итеп, гыйлем таратырга җибәрә. Хәзрәти Мөгаз бине Җәбәл атка атлангач, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам аның атын тотып, күпмедер озата бара. Янәшәдә басып торган сәхабәләр Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Мөгазны җибәрәсе килмәвен, аны ничек итеп хөрмәтләгәнен күрәләр. Шунда Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Йә Мөгаз, киләсе кайтуыңда син мине

күрмәссең, дип сизәм. Намазны минем мәчетемдә вә минем каберем каршында укырсың», – дип әйтә. Бу сүзләрне ишеткән сәхабәләр Пәйгамбәр янына җыелып, елаша башлыйлар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа: «Йә Мөгаз, мин сине Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен яратам. Сиңа бер әйбер васыять итәм, шуны һәр фарыз намаздан соң кабатла:

اللَّهمَّ أعنِّي على ذِكْرِكَ، وشُكْرِكَ، وحُسنِ عبادتِكَ

«Аллаһүммә әгыйннии галәә ҙикрикә вә шүкрикә вә хүсни гыйбаадәтикә».

«Йә Раббым! Миңа Сине искә төшерүдә, Сиңа шөкер кылуда, гыйбадәт кылуда ярдәмче бул», – дип әйтә.

Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сүзе хак була, Мөгаз радыяллаһу ганһе Йәмәннән кайтканда, Пәйгамбәребез вафат була инде.

Мөгаз бине Җәбәл радыяллаһу ганһе калган сәхабәләргә, табигыйннәргә дә бу хәдисне җиткергәндә: «Дөреслектә, мин сезне яратам һәм сезгә шушы васыятьне тапшырам», – дип әйтеп, шушы доганы өйрәтә торган була. Табигыйннәр дә калганнарга бу хәдисне шушы рәвешле тараткannар.

Хәзрәти Мөгаз радыяллаһу ганһе хәлифәләр вакытында да гыйлем таратып йөрүдән туктамаган. Ул Димәшкъ, Фәләстыйн һ. б. җирлекләргә барып, укытып, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм өйрәткәннәрне тараткан. Пәйгамбәребезн аның турында: «Кыямәт көнендә Мөгаз бине Җәбәл галимнәрнең җитәкчесе булачак», – дип әйткән була.

Кадерле җәмәгать, күргәнебезчә, сәхабәләр кайчан дингә килсәләр, шул вакытта үзләренең гыйлемнәрен арттыра, иманнарын ныгыта башлаганнар. Бары тик шушы рәвешле яшәп кенә, үзләренең һәрбер көннәрен мәгънәле итеп үткәрә алганнар. Гыйлемгә омтылып, нәрсәгә булса өйрәнгәч тә, тизрәк аны тарата башлаганнар. Вакытның кадерен белгәннәр, шуңа күрә изге гамәлләрдә ярышканнар, гыйлем туплауда нык торганнар.

Аллаһы Тәгалә һәрбарчабызга да Үзенең рәхмәтен, бәрәкәтен биреп, безгә җәннәтләрендә очрашырга насыйп итсә иде!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Исмәгыйль хәзрәт Биккинин,*
*Казанның Рөстәм мәчете имам-хатыйбы*

*19 сентябрь вәгазе,*

*рабигыль-әүвәл аеның 27 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Экстремизм корбаны булма!

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча дөньяларның Раббысы булган Аллаһы Сөбеханә вә Тәгаләгә чиксез мактаулар булсын. Ул безгә ихлас мөселманнар булырлык иман шәфәгатьләрен бирүче, тәрбия-тормыш ихтыяҗларын тәэмин итүче. Аллаһының яраткан Расүле Мөхәммәд Мостафага һәм аның гаиләсенә, сәхабәләргә хәер-рәхмәтләр насыйп әйләсә иде!

Ислам дине – иң имин дин. Аның атамасы да *сәлам, сәламәт булу, тынычлык* сүзләреннән чыккан. Һәрбер мөселман башка кешеләргә карата гадел, ачык күңелле булырга тиеш. Ул яхшылыкка гына өндәп, начарлыктан тыелып, тыеп яшәргә тиеш.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, һәркемнең экстремизм һәм террорчылык корбаны булу куркынычы бар. Шикле кешеләр белән очрашканда, иясез әйберләргә тап булганда, нәрсә эшләргә? Ничек мондый очракларда югалып калмаска?

Мөгаен, һәрберебезнең үзенә мондый сорауларны биргәне бардыр. Сакланганны Аллаһы Тәгалә дә саклармын дигән түгелме соң? Шулай булгач, дөнья хәлен белеп булмый, сак яшик, кире юнәлешләргә каршы бергәләп көрәшик. Зур фаҗигаләргә юл куймыйк.

Әгәр илдә икътисади тотрыксызлык саклана икән, анда җинаятьчелеккә дә, террорчылыкка да җирлек арта. Әлбәттә, кешеләрдән уяулык сорала.

Исламның традицион булмаган юнәлешләрен пропагандалаучы, даими яшәү урыны булмаган, гомумән, киеме, үз-үзен тотышы, аралашуы белән шик уяткан кешеләрне очратканда, кичекмәстән, район полиция бүлегенә шалтыратырга кирәк.

Җир йөзендәге күп кенә бозыклыкның асылында куркыныч күренеш – террорчылык – ята. Террорчылык гаепсез кешеләрнең үлеменә, балаларның ятим калуларына, җирлекнең куркыныч астында яшәвенә китерә! Террорчылык – көчле кешеләрнең көчсезләргә үзләренең көчләрен күрсәтүләре. Террорчылык мөселманнарны да, башка халыкларны да җәберли. Әмма иң начары – еш кына бүген террорчылар, үзләренең пычрак һәм бозык гамәлләрен «дин байрагы» астында, Аллаһы Тәгалә исемен кулланып эшләп, диннең асылын кешеләргә бозып күрсәтәләр. Ә бит Аллаһы Тәгалә явызлык, начарлык кылучылар турында Коръәни Кәримдә:

وَاللَّهُ لَا يُحِبُّ الظَّالِمِينَ

**«Аллаһы залимнәрне сөйми»,** – дип әйтә.

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:140

Террорчылык – бөек гаделсезлек. Аллаһы Тәгалә андый кешеләрне сөйми, киресенчә, ләгънәт кыла:

وَالَّذِينَ يَنقُضُونَ عَهْدَ اللَّهِ مِن بَعْدِ مِيثَاقِهِ وَيَقْطَعُونَ مَا أَمَرَ اللَّهُ بِهِ أَن يُوصَلَ وَيُفْسِدُونَ فِي الْأَرْضِ ۙ أُولَٰئِكَ لَهُمُ اللَّعْنَةُ وَلَهُمْ سُوءُ الدَّارِ

**«Әмма Аллаһы белән килешүне үтәргә вәгъдә иткәннән соң бозган, Аллаһы ирешергә әмер иткән нәрсәләрне** [җиренә җиткермичә] **өзгән һәм** [инкяр вә золым кылып, фетнә ясап] **җирдә бозыклык чыгарган кешеләргә – ләгънәт. Һәм аларга – бик яман йорт** [булган җәһәннәм әзерләнгән]**».**

«Әр-Рагъд / Күк күкрәү», 13:25

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм алдан белеп әйткәнчә, аңардан соң һәм аның сәхабәләреннән соң, шулай ук хәзрәти Гомәр бине әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе үлеменнән соң, Ислам дөньясында фетнәчеләр барлыкка килде. Һәм алар, торган саен көчәеп, бүгенге көнгә кадәр җәмгыятьне куркыныч астында тоталар. Мондый адашкан фирка-агымнар иң рәхимсез, мәрхәмәтсез каты фетнәләрнең, кирәксезгә чыккан сугышларның сәбәбе булып тора. Искәртеп китик, мөселманнарның зәгыйфьлеге һәм каршылыкларга, авырлыкларга чыдамаулары тышкы дошманнар-фетнәләрдән тормый, ә эчке ризасызлыклар, җәмгыятьтәге эчке фикер каршылыклары аркасында килеп чыгалар.

Бүгенге көндә, кызганыч, дини гыйлеме булмаган «галимнәр» арта бара. Алар, берничә сүрә, хәдис укып кына, шуннан халыкны тәнкыйтьләп, гаеп эзләп, барысын көферлектә гаепләп утыралар. Ә ата-бабаларыбыздан калган дини мирасыбыз, күркәм гореф-гадәтләребез, йолаларыбыз хәзер онытылып бара.

Илебездә XX гасыр азагында гына барлыкка килсә дә, мөселманнарны тулаем гел көферлектә гаепләп, җәмәгатьне «мөшрик», «кяфер» дип төрле төркемнәргә бүлүче бу фирка мөселманнар дөньясының олы проблемасы булып тора. Һәм Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу агымның өммәтебез өчен зур куркынычлык булуы турында безне кисәтеп куйган, үзенең берничә хәдисендә «хариҗиләр» дип аталган төркемнең килүе хакында сөйләгән. Һәм аларның гади мөселманнарны нигезсез рәвештә көферлектә гаепләвен, үзләре белән риза булмаганнарны каты җәберләвен, җәмәгатьне төрле төркемнәргә бүлүе турында әйтеп киткән, аларның куркынычлыгы турында кисәткән.

Әгәр тарих битләренә күз салсак, без бу төркемнең беренче билгеләренең инде Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм вакытында ук барлыкка килүен күрәбез. Бервакыт Расүлуллаһ галәйһиссәлам мөселманнар арасында зәкятне бүлгән вакытта, бер кеше чыгып, Аллаһы

Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә мөрәҗәгать иткән: «Йә Мөхәммәд, Аллаһыдан курык, гадел бул», – дип ризасызлыгын белдергән. Ягъни, бу кеше үзен гаделлек өчен Пәйгамбәргә караганда да күбрәк көрәшүче, тырышлык куючы дип санаган. Ул үзен бик гадел итеп күргән, ә Аллаһының Расүлен, янәсе, гаделсезлектә фаш иткән: «Аллаһыдан курык, йә Мөхәммәд, гаделлек өстә», – дип әйтергә җөрьәт иткән! Димәк, кешеләр арасында иң бөек кешене – Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмне – гаделсезлектә, хаксызлыкта гаепләгән. Шунда Расүлуллаһ галәйһиссәлам: «Сиңа үкенеч булсын! Мин гаделсез булсам, монда миннән дә гаделрәк кем бар соң?!» – дигән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа бу сүзләрен ачуланып әйткән.

Шулай итеп, бу кешенең мин-минлеге, үзен башкалардан өстен күрү гадәте шундый нәтиҗәгә китергән, каршылык туган, ул имамына (ягъни Пәйгамбәребезгә) итагатьсезлек күрсәткән. Хөрмәтле дин кардәшләрем, без, мөселманнар, бер өммәт булып яшибез, өммәттә тәртип булсын өчен, аның җитәкчесе, имамы булырга тиеш. Безнең өчен бүген зур галимнәребез имамнар булып торырга тиеш, ә интернетта яки башка урында, башлангыч гыйлеме дә булмыйча, үзе теләгәнчә динне аңлатучы кешеләрдән без дини гыйлем дә, нәсыйхәт тә алмыйбыз.

Менә шундый затларны тыңлаганнан, укыганнан соң, бүген арада мәчеттәге хәзрәттән, имамнан риза булмаучылар табыла, безнең арада да каршылык туа. Мәсәлән, 30 яшьлек имам җомга вәгазе сөйли. Кайвакыт шунда берәү, түзмичә, сикереп чыга да, имамга каршы: «Син болай әйттең. Юк, алай дөрес түгел ул. Син кем булдың шундый!» – дип, белер-белмәс, үз сүзен такылдый башлый. Гәрчә аның бу гамәле, әйткән сүзе дөрес булмаса да. Көнчелек, мин-минлек һәр адәмнең күңел төбендә ята шул. Шунда хәзрәт: «Каян укыдыгыз мондый фетнәләрне?» – дип сораса, бу кеше: «Яшел китаптан, яшел китаптан», – дип җавап кайтара. Ягъни, ул бу китапның авторын да, нәшерен дә белми. Ул китап безнең вәзгыять өчен язылганмы,

бу галим сүземе, әллә ниндидер фетнәче язган әйбер генәме – ул бу хакта уйламаган.

Ирексездән Хуҗа Нәсретдин мәзәге искә төшә. Берәү аңа: «Әссәламү галәйкүм, мулла абзый!» – дип сәлам биргән. Хуҗа йөгереп кенә өенә кергән дә, «яшел китап» алып чыккан һәм аннан укып: «Вәгаләйкүм әс-сәлам!» – дип җавап биргән, имеш. Бу мәзәк Хуҗаның наданлыгын тасвирласа, теге имамга каршы чыккан абзый үзенең томаналыгын ачып бирә. Шулай итеп, үзеннән 30–35 яшькә яшьрәк мулланың акыл өйрәтеп ятуын күтәрә алмаучы көнче бәндәләр үзләренең генә түгел, тирә-яктагыларның, бигрәк тә имамның сәламәтлегенә дә зыян салалар. Игътибарлы булып, хикмәт белән эш итсәк иде, газиз дин кардәшләрем.

Бүгенге авыллардагы мәхәлләләргә күз салсак – нигездә бу өлкән яшьтәге кардәшләребез. 65–80 яшьлекләр арасында тырышып хезмәт куеп, мәчеткә намазга йөреп, үзләренең туганнарының сәламәтлеген саклау өчен бөтен мөмкинлекләрдән файдаланучы ачык йөзле, киң күңелле картларыбыз бар. Чын күңелдән Аллаһы Тәгаләне мактап, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләрен өйрәнеп, мәчеткә йөрүчеләр артканнан арта бара. 50–60 яшьтәге ханымнарыбыз да, мәчеткә йөреп намаз, Коръән, догалар укырга өйрәнәләр. Аллаһы Раббыз тел ачкычлары насыйп әйләсен! Әмма арадабызда олы яшькә җитеп тә, мәчет юлын белмәүче, харам сулар кулланып өйдә генә ятучылар да юк түгел. Алар: «Без инде картайган, өйрәнергә соң инде», – дип үзләрен аклап куялар. Әмма, адәм баласы дин юлын, тәүбә, гыйлем алу юлын сайласа, Аллаһы Тәгалә җиңеләйтә һәм әҗерен күпкә арттырып кайтара. Әгәр без бердәм өммәт булып, ярдәмләшеп, адашканнарны динебезгә чакырып, гыйлеме булган кешегә итагать итеп яшәсәк, арабыздагы ямьсез күренешләр, гадәтләр юкка чыгар, тормышыбызның бәрәкәте артыр иде.

Газиз дин кардәшләрем, бүген ялган фиркалар яисә, гомумән диннән бик-бик ерак булып та, шул динне аклану итеп алган төркемнәр шактый.

Террорчылар үзләренә нинди генә акланулар табып, нинди генә максатларны күздә тотып гамәл кылмасын – ул кабул ителми. Динебез белән дә, аек акыл белән дә ул кире кагыла. Аллаһы Тәгалә залимнәре сөйми. Шуңа күрә, иң беренче чиратта, үзебез дә кечкенә генә золым кылудан да сакланыйк. Аллаһыдан үзебезгә тыныч күк йөзе, имин көннәр, бердәмлек телик. Раббыбыз безгә файдалы гыйлемнәр, дөрес гамәлләр бирсен. Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Фәнис хәзрәт Низамов,*

*Аксубай шәһәренең «Әниләр» мәчете имам-хатыйбы*

*26 сентябрь вәгазе,*

*рабигыль-ахыр аеның 4 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Өлкәннәр белән яхшы мөгамәлә

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмнәрне, безне бар кылган, калебләребезне иман нуры белән нурландырып, безне мөселман өммәтеннән яраткан Рәхмәтле һәм Рәхимле Раббыбыз Аллаһы Тәгаләгә барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булсын! Галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән соңгы пәйгамбәр, Аллаһының хак Илчесе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салаватларыбыз ирешсә иде!

Исламда өлкәннәр белән мөнәсәбәтләр хөрмәт, кайгырту һәм ихтирам белән сугарылган. Динебез барлык өлкәннәргә, аларның яшенә, җәмгыятьтәге дәрәҗәсенә яки диненә карамастан, тиешле күркәм мөгамәлә күрсәтергә куша. Өлкән яшьтәге кешеләргә карата мөнәсәбәткә аерым игътибар бирелә. Коръән һәм Сөннәт олыларга хөрмәт күрсәтү, аларга карата кызгану һәм кирәкле ярдәм күрсәтү кирәклеген ассызыклый. Ата-аналарны кайгырту, бигрәк тә картлык көннәрендә, мөселманның иң мөһим бурычларының берсе булып санала. Ата-аналарга карата хөрмәт Аллаһыга гыйбадәт кылудан соң киләсе иң изге бурыч булып тора. Изге Коръәнебездә һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләрендә ата-ана хакында, аларның олы дәрәҗәсе турында бик күп искә алына. Мәсәлән, Коръәни Кәримдә әйтелә:

وَوَصَّيْنَا الْإِنسَانَ بِوَالِدَيْهِ حَمَلَتْهُ أُمُّهُ وَهْنًا عَلَىٰ وَهْنٍ وَفِصَالُهُ فِي عَامَيْنِ
أَنِ اشْكُرْ لِي وَلِوَالِدَيْكَ إِلَيَّ الْمَصِيرُ

**«Без кешегә ата-анасына игелек кылырга васыять иттек. Анасы аны зәгыйфьлек өстенә зәгыйфьлек белән йөрткән. Аны имүдән аеруы исә ике ел эчендә.** [Боларның барысы өчен дә, иң элек, Яратучың буларак] **Миңа һәм** [шуннан соң барлыклар арасыннан яратылыш сәбәбең булган] **ата-анаңа шөкер кыл, чөнки кайту – Миңа** [булачак]**».**

«Локман», 31:14

Изге Коръән һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләре ата-аналарга хөрмәт һәм тыңлаучанлык тиешлеген ассызыклый. Бу аларның физик һәм рухи иминлеге турында кайгыртуны, аларга карата игелек, хөрмәт һәм игътибар күрсәтүне үз эченә ала.

Өлкән яшьтәге ялгыз кешеләргә ярдәм итү дә Ислам тәгълиматының мөһим өлеше булып тора. Мөселманнар мохтаҗларга, бигрәк тә ялгыз һәм ярдәмсез калучыларга карата мәрхәмәтле һәм шәфкатьле булырга тиеш. Бу матди яки рухи ярдәм күрсәтүне, көнкүреш мәсьәләләрдә булышуны һәм аралашуны үз эченә алырга мөмкин. Өлкәннәр белән аралашу Исламда аралашучыга да, өлкән кешегә дә файда китерә торган изге эш буларак карала. Чөнки өлкән яшьтәге кешеләр бай тормыш тәҗрибәсенә һәм яшь буыннар белән уртаклаша алырлык белемнәргә ия. Шуңа да өлкән буын кешеләре белән аралашу аларның зирәклеген үзләштерергә, кыйммәтле киңәшләрен алырга һәм буыннар арасындагы элемтәне ныгытырга мөмкинлек бирә. Шулай ук өлкәннәргә хөрмәт һәм ихтирам белән карау, аларга карата сабырлык һәм аңлау күрсәтү бик мөһим.

Ата-аналары һәм өлкән яшьтәге кешеләр турында кайгырту – ул яхшы гамәл генә түгел, ә бәлки һәр мөселманның бурычы да. Ата-ананы хөрмәт

итмәү, санга сукмау, кысрыклау яки кимсетү, күңелләрен рәнҗетү – иң олы гөнаһлардандыр. Кыямәт көнендә андый кешеләр җәннәтнең хәтта исен дә сизмәсләр, Аллаһы Тәгалә аларга Үзенең рәхим-шәфкатен күрсәтмәс, хәтта кылган бүтән изге гамәлләре күп булса да. Ата-анасын рәнҗетүче фани дөньяда ук сынауларга дучар була, ә әҗәле җиткәч, шәһадәт кәлимәсен әйтә алмас, диелә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләрендә.

Ислам дине өлкән буынны кайгыртучанлык һәм игътибар белән әйләндереп алган. Өлкән яшьтәге кешеләргә матди ярдәм күрсәтү белән генә чикләнеп калмыйча, вакыт табып, аларны тыңлау, үткән тормышлары белән кызыксыну һәм аларга эмоциональ ярдәм күрсәтү мөһим. Янәшәдә булу гына да аларның кәефенә зур йогынты ясый һәм ялгызлык тойгысыннан котылырга ярдәм итә. Өлкән яшьтәге кешеләр белән аралашу, хәер-фатихаларын алу Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешү мөмкинлеге дә булып тора. Чөнки аларның догалары аерым бер көчкә ия, ә аларның үгет-нәсыйхәтләре безгә тормышта дөрес юл табарга ярдәм итә ала. Шуңа күрә, даими рәвештә өлкән яшьтәге кешеләр янына барып, аларга игътибарыбызны күрсәтеп, киңәшләшеп торырга кирәк.

Янә Коръәни Кәримгә мөрәҗәгать итсәк, анда мондый аять бар:

وَقَضَىٰ رَبُّكَ أَلَّا تَعْبُدُوا إِلَّا إِيَّاهُ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا ۚ إِمَّا يَبْلُغَنَّ عِندَكَ الْكِبَرَ أَحَدُهُمَا أَوْ كِلَاهُمَا فَلَا تَقُل لَّهُمَا أُفٍّ وَلَا تَنْهَرْهُمَا وَقُل لَّهُمَا قَوْلًا كَرِيمًا ﴿٢٣﴾ وَاخْفِضْ لَهُمَا جَنَاحَ الذُّلِّ مِنَ الرَّحْمَةِ وَقُل رَّبِّ ارْحَمْهُمَا كَمَا رَبَّيَانِي صَغِيرًا ﴿٢٤﴾

«**Раббың сезгә Үзеннән башкаларга табынмаска, ата-анага игелек** [кылырга] **әмер итте.** [Ий кеше!] **Аларның икесеннән берсе яки икесе дә синең янында картлыкка ирешсә, аларга** [канәгатьсезлек белдереп]**: «Уф!» – дип тә әйтмә.** [Сүз-гамәлләре сиңа ошамаса да]

**Аларга кычкырма, күркәм сүз әйт. Мәрхәмәтлектән алар алдында тыйнаклык канатын җәй һәм** [кяфер булсалар да, һидаятькә ирешүләрен Аллаһыдан сорап]**: «Ий Раббым! Алар кечкенә чагымда мине** [зур бер шәфкать белән] **үстергәннәре кебек, Син дә аларга** [бакый рәхмәтең белән] **мәрхәмәт ит», – дип әйт».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:23–24

Күрәбез, ата-анага авыр сүз әйтү түгел, хәтта «уф» сүзен әйтү дә шелтәләнә. Ә бүген нәрсә? Хәзер еш кына балаларының карт ата-анасы хакында: «Ул мине аңламый, юләр булып, бар нәрсәне дә оныткан булып кылана!» – кебек һәм башка шундый ямьсез сүзләр ишетергә туры килә. Киләр шундый көн, без дә картаербыз. Бездән ишеткән сүзләрне балаларыбыз үзебезгә әйтә башламасмы?

Картлык зәгыйфьлеге берәүгә дә сорап килми бит. Шуңа күрә өлкән яшьтәге ата-аналар белән мөнәсәбәтләрдә түземлелек, сабырлык һәм гафу итүнең мөһимлеген аңлыйк. Яшь арткан саен, аларның сәламәтлек, хәтер һәм холык белән бәйле төрле кыенлыклар туарга мөмкин. Мондый очракта сабырлык, аңлау, хата-кимчелекләрне кичерергә әзер булу тирән хөрмәт һәм мәхәббәт чагылышы булып тора. Шәфкать күрсәтү һәм картларның хаталарын кичерү – диндарлык һәм рухи җитлеккәнлек билгесе ул.

Үзләренең әби-бабаларын хөрмәтләү, кайгыртуны күреп үскән балалар өлкәннәргә хөрмәт белән карарга өйрәнә һәм шәфкатьлелек, миһербанлык хисләрен үзләштерә. Шул рәвешле, бу безнең үзебезнең киләчәгебез өчен дә бер хәерлелек булып тора. Балаларыбызны үз мисалыбызда тәрбиялик.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, өлкән яшьтәге ата-аналар турында кайгырту аларның авыру яки зәгыйфьлек чоры белән генә чикләнми. Динебез аларга гомер буе хөрмәт һәм игътибар күрсәтүне хуплый. Җылы мөнәсәбәтләрне саклау, теләсә кайсы очракларда ярдәм күрсәтү – бу аларның яратуы һәм элек безне кайгыртуы өчен рәхмәт белдерү.

Аллаһыга иман китергән, Исламны бөтен барлыгы белән кабул иткән кеше ата-анасын рәнҗетми, аларга карата сак була, бу мәсьәләгә җитди карый. Кызганыч, әмма нәкъ менә диндә булган яшьләр арасында ата-анага кырын карау очраклары еш күзәтелә. Үзләре намазга басып, мәчеткә йөри башлаган яшьләребез диннән ерак булган ата-аналарын санламый башлый. Ата-аналар балаларының диндә булганын хупласа да, балалар аларны белемсезлектә гаепли. Аллаһыга шөкер, бүген кеше өчен дини белем алуга бернинди дә каршылык юк, дин тотудан тыймыйлар. Әмма алдагы буын вәкилләре әлеге мөмкинлектән мәхрүм иде. Күпләр, диндә булуның мөһимлеген аңлап, Исламга кайта, намазга баса. Әмма кайберәүләр әле моннан ерак. Һәм моның өчен аларны түбәнсетергә, кимсетергә, бигрәк тә алар белән араны өзәргә ярамый. Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм диндә булмаганнар белән аралашуның күркәм мисалы булып тора. Ул беркайчан да кешеләрне аермаган, бигрәк тә югарыдан карап, син гөнаһлы инде, сине Аллаһы кичермәс инде, дип фикер йөртмәгән. Аллаһы Тәгалә болай ди:

فَبِمَا رَحْمَةٍ مِّنَ اللَّهِ لِنتَ لَهُمْ ۖ وَلَوْ كُنتَ فَظًّا غَلِيظَ الْقَلْبِ لَانفَضُّوا مِنْ حَوْلِكَ

«[Расүлем! Өммәтеңә карата сиңа] **Аллаһыдан** [бирелгән кызгану һәм] **шәфкать белән син аларга** [Өхед сугышында әмереңнән чыкканнарга] **йомшак булдың. Әгәр дә дорфа, каты күңелле булсаң, алар синең яннан таралып киткән булырлар иде…»**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:159

Бу аятьтә ачыктан-ачык рәвештә диндә булган кешенең янәшәдәгеләргә аеруча да игътибарлы булуы турында сүз бара. Ә безгә тормыш биргән, тәрбияләп үстергән ата-аналарыбыз турында сүз дә юк. Берәү, көне-төне гыйбадәттә булып, әти-әнисенә йомшаклык күрсәтмәсә, гыйбадәт кылуының файдасын күрерме?

Беләбез, Ибраһим пәйгамбәр галәйһиссәламнең әтисе потлар ясаучы һәм аларга табынучы кеше булган. Әмма, моңа карамастан, Ибраһим галәйһиссәлам аңа катылык күрсәтмәгән, ата хакын олылаган. Әтисенә нәсыйхәтләр бирүдән туктамыйча, йомшак мөгамәлә күрсәткән. Бу хакта Коръәндә тасвирлана. Пәйгамбәр булып җибәрелгән бөек кешенең потка табунычы әтисенә күркәм мөнәсәбәттә булуы ассызыклана. Шуңа күрә, кичә генә намазга өйрәнеп, бүген әти-әниләрен дин тотмауда гаепләүче яшьләр ялгышуларын аңласыннар иде! Бәлки ата-аналарының диндә булмавы алар өчен бер сынау буларак бирелгәндер.

Ислам дине шулай ук өлкән яшьтәге ата-аналарны лаеклы тормыш өчен кирәкле барлык нәрсәләр белән тәэмин итүгә дә игътибарны юнәлтә. Бу торак, туклану һәм медицина ярдәме күрсәтү кебек матди ярдәмне генә түгел, ә мәхәббәт, игътибар һәм хөрмәт күрсәтүдә чагыла торган рухи ярдәмне дә үз эченә ала. Уңайлы һәм куркынычсыз шартлар тудырып, аларның ихтыяҗларын исәпкә алу мөһим. Ислам хокукында балаларның үз ата-аналарына карата хокуклары һәм бурычлары турында төгәл күрсәтмәләр бар. Аерым алганда, мөһим тормыш мәсьәләләрендә ата-аналар белән киңәшләшергә, аларның фикеренә колак салырга һәм аларга авырту яки газаплар китерергә мөмкин булган гамәлләрдән качарга кирәклеге ассызыклана.

Моннан тыш, ата-аналарыбыз өчен дога кылып торыйк, бу дөньяда да, киләчәктә дә аларга Аллаһыдан рәхмәт, гафу һәм иминлек сорыйк. Дога – мәхәббәт һәм рәхмәт белдерүнең куәтле чарасы, ул юаныч китерә һәм буыннар арасындагы бәйләнешне ныгыта.

Ислам әхлагында шулай ук ата-аналарыбызның абыйлары һәм апалары кебек туганнары белән дә яхшы мөнәсәбәтләрне саклауның мөһимлеге ассызыклана. Аларны хөрмәт итү һәм кайгырту ата-аналарның үзләренә карата булган ихтирамны чагылдыра һәм туганлык мөнәсәбәтләрен ныгыта. Коръәни Кәримдә болай диелә:

وَاعْبُدُوا اللَّهَ وَلَا تُشْرِكُوا بِهِ شَيْئًا ۖ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا وَبِذِي الْقُرْبَىٰ وَالْيَتَامَىٰ وَالْمَسَاكِينِ وَالْجَارِ ذِي الْقُرْبَىٰ وَالْجَارِ الْجُنُبِ وَالصَّاحِبِ بِالْجَنبِ وَابْنِ السَّبِيلِ وَمَا مَلَكَتْ أَيْمَانُكُمْ ۗ إِنَّ اللَّهَ لَا يُحِبُّ مَن كَانَ مُخْتَالًا فَخُورًا

«[Ий коллар!] **Аллаһыга гыйбадәт кылыгыз. Аңа бернәрсәне дә ширек кушмагыз. Ата белән анага,** [бертуганнар һәм агалар кебек] **якыннарга, ятимнәргә, мескеннәргә,** [нәселдәшлек яки яшәгән урыны җәһәтеннән] **якын күршегә,** [нәселдәшлеге яки өе] **ерак күршегә,** [ир-хатын, юлдаш һәм сабакташ кебек] **янәшәдәге иптәшләргә, юлда калучыга һәм уң кулыгыз ия булган нәрсәләргә** [коллар, җарияләр һәм хезмәтчеләргә] **игелек кылыгыз. Һичшиксез, Аллаһы тәкәббер** [булганы өчен туган-кардәш һәм күршеләренә карата яхшы мөнәсәбәттә тормаган] **һәм** [өстенлекләрен санаган] **мактанчык кешеләрне сөйми».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:36

Аллаһы Тәгалә барыбызга да динебезне дөрес аңлап, якыннарыбызны нәсыйхәтләп, аларның дингә килүенә сәбәпче булырга насыйп итсә иде, кылган гамәлләребез ихластан һәм дөрес булып, ата-аналарыбыз каршындагы бурычларыбызны үти, ризалыкларына ирешә алсак иде.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул

тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Зөфәр хәзрәт Галиев,*

*Әтнә районының Таш-Чишмә авылы мәчете имам-хатыйбы*

*3 октябрь вәгазе,*

*рабигыль-ахыр аеның 11 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Ата-ананың баласы каршындагы бурычлары

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Газиз дин кардәшләрем, Аллаһы Тәгалә әйтә:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ إِنَّا خَلَقْنَاكُم مِّن ذَكَرٍ وَأُنثَىٰ

**«Ий кешеләр! Һичшиксез, Без сезне бер ирдән һәм бер хатыннан яраттык».**

«Әл-Хуҗүрат / Бүлмәләр», 49:13

Гаилә кору, зур гаилә булдыру – ул Аллаһы Тәгаләнең бер нигъмәте һәм динебездә бик хуплана торган гамәл. Хәдистә: «Дүрт төрле әйбер пәйгамбәрләр сөннәте булып тора: ислемайлар куллану, никахлашу, мисвәк һәм кына куллану»[1], – диелгән.

Һәм телибезме без моны, теләмибезме, безнең киләчәгебез турыдан-туры безнең гаиләбез, балаларыбыз белән бәйле. Галимнәребез әйтүенчә, ата-ананың баласы каршында төп өч бурычы бар, аларны балаларның хаклары дип тә атыйлар. Болар:

1. Бала туганнан соң, аңа күркәм исем бирү.
2. Күркәм тәрбия бирү.

[1] Имам Әхмәд.

3. Яше җиткәч, иманлы (мөселман) кешегә өйләндерү яки кияүгә бирү.

Сөннәтебез буенча, бала тугач та, аның уң колагына – азан, сул колагына камәт әйтелергә, шуннан соң исем кушылырга тиеш. Әлбәттә, бу мөмкинлек булган очракта, андый мөмкинлек булмаса, соңрак әйтергә дә мөмкин. Балага исем сайлауга килгәндә, моның бик җаваплы һәм мөһим гамәл булуын истә тотарга кирәк. Исемнең әйтелеше генә түгел, мәгънәсе дә матур, яхшы булырга тиеш.

Исем сайлауда галимнәребез, имамнарыбыз безгә мондый киңәшләр бирә:

1. Беренчедән, исем динебез кануннарына туры килергә тиеш.

2. Икенчедән, баланың нәсәбе әтисе ягына карый, ягъни бала әтисенең нәселеннән санала һәм аны дәвам иттерә. Кыямәт көнендә һәр кеше исеме һәм нәсәбе (ягъни әтисенең исеме) белән чакырылачак.

3. Өченчедән, исем кушу өчен иң яхшы вакыт – бала туганнан соң ук, яки өченче, яки җиденче көнендә.

4. Дүртенче мөһим кагыйдә – малайларга «Габд» (кол) сүзе белән башланган исем яки пәйгамбәрләр, әүлияләр исемнәрен кушу күркәм санала. Хәдистә: «Чынлыкта, Аллаһы Тәгалә өчен иң яраткан исемнәр булып Габдуллаһ һәм Габдрахман исемнәре тора», – диелгән. Бу исемнәр «Аллаһының колы» һәм «Әр-Рахмәннең колы» дигәнне аңлата.

5. Бишенче кагыйдә – яңа, «модный» (төрле кино, сериаллардан ишетеп алган) исемнәрне куймаска тырышу, чөнки исем кешенең тормышына зур йогынты ясый. Динебез, милләтебезгә ят булмаган, туры килгән исем сайлагыз.

6. Киләсе кагыйдә, газиз дин кардәшләрем, – төрле потлар атамалары, секталар яки мәҗүсиләр табынган әйберләрнең атамалары кергән исемнәр кушу катгый тыелган! Шулай ук үзенең гөнаһлары белән танылган кеше исемен кую да киңәш ителми.

7. Һәм без атаячак соңгы кагыйдә – балага Аллаһы Тәгаләнең күркәм исемнәреннән булган исемне кушу да тыела. Бу исемнәрне, алда әйткәнчә, «Габд» сүзе белән бергә кушарга кирәк.

Димәк, дин кардәшләрем, динебездә исем кушуга зур урын бирелә. Балаларыбызга күркәм, динебез һәм милләтебезгә туры килгән матур исемнәр сайлыйк.

Баланың киләсе хаклары яки ата-ананың бурычы – ул гаиләдә күркәм тәрбия бирү һәм үз гаиләсен булдыруда иманлы кешене сайларга ярдәм итү. Бу ике бурычны минем бергә карап китәсем килә, чөнки алар үзара бәйләнгән. Баланың беренче мәдрәсәсе – ул гаилә, ул әни. Шуңа күрә бала тәрбиясе иманлы, әхлаклы, тәрбияле хәләл җефет сайлаудан ук башлана. Яшьләребез шуны истә тотсын иде: без гомерлек яр гына түгел, без беренче чиратта булачак балабызның әнисен яки әтисен сайлыйбыз.

Динебездә хәләл җефетне сайлау мөһим мәсьәлә булып тора. Әйе, күп ата-аналар балалар кечкенә әле, аларга әле 10 яки 20 яшь кенә, аларның әле үсәсе, укыйсы, мәктәп һәм университет тәмамлыйсы, һөнәр аласы, карьера төзисе бар, дип уйларга мөмкин. Яшьләр арасында күпләр, үз гаиләсен булдырырга ашыкмыйча, тормышларының башка өлкәләрендә уңышка ирешкәч кенә гаилә турында уйлана башларга кирәк, дип фикер йөртә.

Әмма Ислам динендә барысы да башкача! Хөрмәтле дин кардәшләрем, балаларыбыз кечкенә булганда ук, безгә аларның киләчәктә гаилә корулары турында уйлый башларга кирәк. Бу без кечкенәдән балаларыбызга өйләнү, кияүгә чыгу турында гына сөйләп торырга тиеш дигән сүз түгел, юк. Әмма хикмәтле, алдан уйлап эш итүче әти-әни буларак, без балаларыбызның кечкенә чагыннан ук бу мәсьәләне кайгырта башларга тиеш. Мәсәлән, Ислам күзлегеннән кайсы гаиләләрне без үрнәк гаилә дип атый алабыз? Тирәягыбыздагы гаиләләрдән кайсысында тәкъва һәм иманлы мөселман вә мөслимәләр үсеп килә? Алар нинди тәрбия ала? Үз әти-әниләрен тыңлыймы, аларга карата ихтирамлымы алар? Без балаларыбызның киләчәген

кайгыртырга тиешбез, Аллаһы Тәгалә аларны безгә әманәт итеп ышанып тапшырды, һәм Кыямәт көнендә без Аллаһы каршында җавап тотачакбыз.

Шулай ук бүген бик тә әһәмиятле, бик күпләрне борчып торган мәсьәлә бар. Кардәшләрем, без балаларыбызга аңлатырга тиешле бик мөһим мәсьәлә – ул ир-ат белән хатын-кыз арасында рөхсәт ителгән, гөнаһлы булмаган бердәнбер мөнәсәбәтләрнең *никах* булуын җиткерү. Башка төрле мөнәсәбәт һәм аралашулар булырга тиеш түгел. Кызганыч, бүген без көннән-көн ешрак: «Без әлегә бергә яшәп кенә карыйбыз, тора алырбызмы-юкмы, аннан соң карарбыз», – кебек куркыныч сүзләрне ишетәбез. Бу сүзләрдән иманлы кешенең коты очып торырга тиеш! Бу – зина. Зина – куркыныч гөнаһ. Ислам динендә гаилә принциплары ачык һәм төгәл билгеләнгән. «Ярый, бераз бергә яшәп карасыннар, бәлки холыклары туры килмәс», – дип никах, гаилә мәсьәләсенә җиңел караган кешеләрне, әти-әниләрне Аллаһы Тәгалә Коръәндә бик каты кисәтә. Мондый гөнаһ өчен ике дөньяда да җәза каралганы аңлашыла. Гаилә мәсьәләсенә җиңел карарга, «просто яшәп карарга» ярамый!

Балаларыбыз куркыныч гөнаһлардан ерак торып, хәләл җефет сайлаганда безгә ышанып, безнең фикергә колак салырга тиеш. Нарасыйларыбызны шул рәвешле тәрбияли алу – ата-ана буларак безнең бурычыбыз. Шул ук вакытта без гаилә коруда ниятнең дөрес булуын да җиткерә белергә тиешбез.

Әгәр без никах алдыннан кияү белән кәләштән: «Ни өчен өйләнәсең / кияүгә чыгасың?» – дип сорасак, күпләрдән: «Яратам», «Бәхетле булыр өчен», «Гомер буе бергә яшәр өчен», «Гаиләм, балаларым булсын өчен», «Шулай тиеш инде, гадәт шундый», – кебек җаваплар ишетергә мөмкин. Ягъни җаваплар бик төрле була. Әмма дөрес җавап Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сүзләрендә: «Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен».

Безнең иң төп ниятебез – ул Аллаһы Раббыбызның ризалыгы. Аның ризалыгыннан башка берни булмаячак. Ул кушканнарны үтәмибез икән, димәк, без Аның рәхмәтеннән мәхрүм калабыз. Әгәр кеше университетта яки

эшендә үз вазифаларын үтәми икән, ул кисәтү яки җәза ала. Диндә дә нәкъ шулай: Аллаһы Тәгаләнең кануннарын бозабыз икән, Ул да безгә без сораганны бирмәячәк. Шуңа күрә гаилә корганда беренче урында Раббыбызның ризалыгы булырга тиеш. Ә Аллаһының ризалыгына ирешү өчен, Ул кушканнарны үтәргә кирәк. Ул безгә нәрсәләр әмер итә? Һәрберебезнең көче җитәрдәй, һәркайсыбыз үти алырдай әйберләр генә. Димәк, әгәр гаилә корырга ниятләгәнбез икән яки әти-әни баласына туры килердәй пар тапкан икән, без Аллаһы Тәгалә кушканнарның иң азын булса да эшләргә тиешбез. Моннан башка Аллаһының ризалыгына да, бәхеткә дә, бәрәкәткә дә, иминлеккә дә ирешеп булмас. Әмерләрне бозудан башлыйбыз икән, димәк, бу гөнаһыбыз өчен бу дөньяда да, ахирәттә дә җавап тотачакбыз. Шул рәвешле, гаилә корганда иң күркәм ният Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен булыр.

Димәк, дин кардәшләрем, әгәр мөселман диндар һәм әхлаклы пар белән кавышкан икән, ул булачак балаларының тәрбиясенә инде зур өлеш керткән. Әгәр баласына шундый пар белән кавышырга ярдәм иткән икән, ул үз бурычын да үтәп, киләсе буыннары тәрбиясенә дә зур өлеш керткән. Алга таба без баланың нәкъ гаиләдә Раббысы хакында беренче мәгълүмат алуын истә тотабыз. Бала кечкенә булганда, ул әти-әнисен дөньядагы иң көчле затлар буларак кабул итә. Әмма без шушы вакытта ук балага барыбызның да Аллаһы Тәгаләгә мохтаҗ булуыбызны, Аннан гына ярдәм соравыбызны аңлата башларга тиешбез. Мәсәлән, балабыз бездән нидер сораганда, аңа Аллаһы Тәгалә хакында искә төшерергә, Аның безне күрүен, ишетүен сөйләргә кирәк.

Нәкъ гаиләдә баланың гыйбадәткә мәхәббәте барлыкка килергә тиеш. Һәм күңелдә башта Аллаһы Тәгаләгә мәхәббәт тәрбияләнмәсә, гыйбадәтне ярату мөмкин түгел. Гыйбадәт мәсьәләсендә балалар еш кына әти-әниләрен кабатлый. Шуңа күрә, әгәр без үзебез гыйбадәтләребезгә җиңел карыйбыз икән, Коръәни Кәримне өйрәнүгә, намазларга җиңел карыйбыз икән, балабыздан нәрсә көтәбез? Әүвәл үзебез динебезне өйрәнүгә, Коръәнгә игътибарлы булыйк, балаларыбыз да безгә иярер, иншәАллаһ.

Гаилә бер-береңне ярату, миһербанлы булу, бердәмлек һәм килешүгә нигезләнә. Ике дөнья бәхетенә ирешергә телибез икән, Аллаһы Раббыбыз әмер иткәнчә, Коръән һәм Сөннәткә нык тотынырга кирәк. Шушы кагыйдәне балаларыбызга җиткерә алсак, һәрберебез шуны аңлап, калебенә кертсә, кануннар буенча яшәсә, барыбыз да ике дөнья бәхетенә ирешә алачак.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рөстәм хәзрәт Хәйруллин,*

*Казанның «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы*

# Нәрсә?
# Кайда?
# Кайчан?

# МАРТ-МАЙ

## Кама Тамагы мөхтәсибәте күпбалалы һәм үрнәк гаиләләр белән очрашу үткәрде

Кама Тамагы бистәсенең Мәгърифәт үзәгендә районның күпбалалы һәм үрнәк гаиләләре белән очрашу узды: анда гаиләдәге мөнәсәбәтләрне ныгыту, бала тәрбияләү, әдәп-әхлак мәсьәләләре буенча тәҗрибә уртаклаштылар.

## Татарстан Мөфтие Сбербанкның ислам офисы белән танышты

Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Сбербанкның ислам офисында булды. Биредә клиентларга Диния нәзарәте фәтвасы булган «Амана» исәп-хисап счеты, «Адафа» дебет картасы, ислам исәп-хисап касса хезмәте, «Мурабаха» ипотекасы һәм «Мурабаха» факторингы тәкъдим ителә.

## Мөфти халык белән очрашулар үткәрде

Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Рамазан аенда Республиканың төрле районнарында халык белән очрашты. Камил хәзрәт Лаеш, Теләче, Лениногорск, Мөслим, Арча, Яр Чаллы, Алабуга мөхтәсибәтләренә эшлекле сәфәр кылып, мөселманнар белән очрашты. Очрашулар вакытында Мөфти хәзрәтләре Рамазан аеның һәм ураза тотуның фазыйләтләре, нәфесне тәрбияләү, Коръән уку өчен бирелә торган саваплар, хатем кылуның мөһимлеге турында вәгазьләр сөйләде. Ул Диния нәзарәтенең төп эш юнәлешләре һәм соңгы еллардагы казанышлары турында сөйләде, мөфтият һәм аның структур оешмалары алдындагы өстенлекле юнәлешләрне билгеләде. Алар: кадрлар әзерләү, мәгърифәтчелек һәм дәгъват, вакф институтын үстерү, махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү кебек юнәлешләр. Төбәк җитәкчеләре белән очрашуларда исә урыннардагы дини вәзгыять турында фикер алыштылар.

Шулай ук махсус хәрби операциядә һәлак булганнарның якыннары белән дә очрашулар узды.

## «Рамазан – изге гамәлләр ае» марафоны тәмам: Татарстанда 2200 дән артык кешегә ярдәм күрсәтелде

Татарстанда ел саен үткәрелә торган «Рамазан – изге гамәлләр ае» хәйрия марафоны узды. Әлеге акция Диния нәзарәте тарафыннан Рамазан аеның беренче көненнән үк игълан ителгән иде. Нәтиҗәдә «Зәкят» хәйрия фонды аның кысаларында 2288 кешегә ярдәм күрсәтте.

Марафонның төп нәтиҗәләренең берсе авыру сабыйларны һәм өлкәннәрне дәвалау өчен акча җыю белән бәйле. Аерым алганда, акция 49 балага тернәкләнү һәм дәвалау курсларын узарга мөмкинлек бирде. Бу балаларда – церебраль паралич, җитлекми туу белән бәйле булган катлаулы диагнозлар (перинатальная патология ЦНС и ретинопатия недоношенных); миопия, астигматизм. Шулай ук физик мөмкинлекләре чикле 31 өлкән кешегә дәвалану һәм тернәкләнү курслары узу өчен акчалата ярдәм күрсәтелде.

Моннан тыш, авыр тормыш хәлендә калган 20 өлкән кеше, бурычларын түләү һәм көнкүреш шартларын яхшырту өчен, финанс ярдәм алды.

Шулай итеп, марафон нәтиҗәләре буенча, «Зәкят» фондыннан адреслы җыемнар, шулай ук фитр садакасы һәм фидия хисабына барлыгы 100 кеше 8 млн 838 мең сумлык матди ярдәм алды. Мөселманнарга уңайлы булсын өчен, «Зәкят» хәйрия фонды әлеге төр садакаларны электрон рәвештә үзәкләштереп җыюны оештырды. Нәтиҗәдә 1 892 737,46 сум фитр садакасы һәм 816 544,63 сум күләмендә фидия җыелды, һәм 100 мохтаҗның 37 сенә җибәрелде.

Хәйрия марафонының тагын бер юнәлеше Татарстанның аз керемле гаиләләренә азык-төлекләтә ярдәм күрсәтү белән бәйле иде. Ай дәвамында «Зәкят» хәйрия фонды 600 дән артык кешене (Бөек Ватан сугышы ветераннарын һәм башка мохтаҗларны) 5,6 тонна азык-төлек белән тәэмин итте. Бер җыелманың авырлыгы 9 килограммнан артып китте.

Моннан тыш, «Зәкят» хәйрия фонды үз акчаларына һәм иганә хисабына 375 мохтаҗ һәм авыру кешеләр өчен 8 хәйрия ифтары уздырды.

## Көньяк Африка Республикасы, Оман һәм Катар Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты буенча комитеты сертификатын таныды

Көньяк Африка Республикасы, Оман һәм Катар Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты буенча комитеты сертификатын таныды. Шулай итеп, Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты буенча комитеты Татарстанның хәләл товарлар җитештерүчеләренә тагын берничә чит илгә экспортка чыгу өчен мөмкинлек тудырды: Хәзер Диния нәзарәте сертификаты булган товарлар Көньяк Африка Республикасына, Оман һәм Катарга чыгарыла ала.

Бу Диния нәзарәте Комитетының стандартларын чит илләрдә тануның беренче тәҗрибәсе түгел. Элегрәк Комитет Фарсы култыгы илләрендә сертификацияләү органы булган Gulf Accreditation Centre (GAC)да аккредитация узган иде.

## Татарстан мөфтияте һәм Болгар ислам академиясе җитәкчеләре уку йортының үсеше мәсьәләләре хакында фикер алышты

Мөфти Камил хәзрәт, аның урынбасары, Россиянең ислам мәгарифе советы директоры Рәфикъ хәзрәт Мөхәммәтшин һәм БИА ректоры Фәрхәт Хөснетдинов ислам дин белгечләрен әзерләү һәм фәнни тикшеренүләр, мөгаллимнәрне җәлеп итү проблемалары һәм Россия имамнарын белем дәрәҗәсен күтәрүгә җәлеп итү чаралары хакында сөйләште.

Камил хәзрәт Болгар ислам академиясендә профессор, фән докторы, ислам хокукы һәм ислам хокукы методологиясе мөгаллиме шәех Мөхәммәд Айман әз-Заһрави һәм кайбер шәкертләр белән дә аралашты.

## Рамазан-шәриф аенда «Ислам. Беренче адымнар» мәктәбендә 200 дән артык кеше намазга басты

Рамазан аеның 15 нче көнендә (15 мартта) Казанда «Ислам. Беренче адымнар» мәктәбенең 15 нче сезоны тәгәлләнде: 200 дән артык кеше намазга басты. Курслар, Исламда беренче адымнарын ясаучы кардәшләребез изге ай тәгәлләнгәнче намаз укырга өйрәнә алсын өчен, Рамазан ае алдыннан махсус оештырылды. «Ислам. Беренче адымнар» проекты Татарстан мөфтияте тарафыннан 2018 елда тормышка ашырыла башлады. Унбиш сезон дәвамында әлеге курсларда 1700 дән артык кеше белем алды һәм намазга басты.

## Казанда Диния нәзарәтенең IX Корылтае узды. Камил хәзрәт Сәмигуллин – Татарстан Мөфтие, Җәлил хәзрәт Фазлыев Баш казый итеп сайланды

Рамазан аеның 19 нчы көнендә (19 мартта) Казанда Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең чираттагы IX Корылтае узды. Аның эшендә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Республиканың 1520 имамы, ТР Дәүләт Советы, ТР Министрлар кабинеты, ТР Рәисе Аппараты вәкилләре, зур оешма җитәкчеләре, район һәм шәһәрләр башлыклары, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашты. Корылтайның көн тәртибендәге мәсьәләләр булып Татарстан Мөфтиен һәм Баш казыен, Нәзарәтнең үткән 4 елда башкарылган эшчәнлегенә йомгак ясау һ. б. торды. Шулай ук делегатлар игътибарына Нәзарәтнең Казыйлар шурасы һәм Үзәк ревизия комиссиясе хисабы да тәкъдим ителде.

## Казанда 13 нче Республикакүләм ифтар узды

19 мартта Казанда «Казан Экспо» Халыкара күргәзмәләр үзәгендә Россиядәге иң зур ифтарларның берсе – 13 нче Республикакүләм ифтар – узды. Чара Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте, «Ак Барс Арена» стадионы дирекциясе, «Туган авылым» милли-туристлык комплексы һәм «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәге көче белән оештырылды. Республикакүләм ифтарның мул табыннары артында

13 меңнән артык кеше җыелды. Алар арасында Татарстанның төрле почмакларыннан килгән дин кардәшләребез, җитәкчеләр, махсус хәрби операциядә катнашучылар, танылган дин, җәмәгать, мәдәният, дәүләт эшлеклəре һ. б. бар.

Республикакүләм ифтарның концептуаль эчтәлеге әһәмиятле: ул Россиядә һәм Татарстанда игълан ителгән Ватанны саклаучылар елы кысаларында, шулай ук Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгы билгесе астында узды. Шулай итеп, бөтен программа Ватанга мәхәббәт һәм махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм итүгә багышланды һәм Бөек Җиңү каһарманнары истәлегенә хөрмәт белдерүне күздә тотты.

## Диния Нәзарәте «Батыр» һәм «Алга» батальоннары имамнарына «тәгәрмәчле мәчетләр» тапшырды

Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды махсус хәрби операциядә катнашучы мөселман хәрбиләре өчен «тәгәрмәчле мәчетләрне» җиһазландыруга акча җыюны уңышлы тәмамлады. «Каһарман» акциясе кысаларында барлыгы 3,5 миллион сум акча җыелды, шуларга ике УАЗ СГР автомобиле сатып алынды һәм җиһазландырылды.

«Тәгәрмәчле мәчетләрнең» салоннары эчендә намаз уку һәм рухи әңгәмәләр алып бару өчен уңайлыклар тудырылды: идән, стеналар һәм түшәм су үтмәслек, тавыш кермәслек һәм җылылык сакларлык итеп эшләнде, идәннәре тигезләнде һәм келәм җәелде. Салоннар, юу җиңел булсын өчен, ясалма күн белән тышланды, михраб һәм шамаилләр белән бизәлде, утырып тору һәм әйберләрне саклау өчен, тартмалар куелды, шулай ук китап киштәләре урын алды. Полк имамнарының үтенечен истә тотып, мобиль мәчетләргә кондиционерлар, РЭБ чаралары һәм кыйбланы билгеләү өчен компас куелды, кечкенә китапханә эшләнде. Дини бурычлардан тыш, автомобильләр хәрби частьләр арасында йөрү һәм яралыларны йөртү, даруларны һәм азык-төлек әйберләрен ташу өчен файдаланылачак.

## Нәзарәттә Малайзиянең Ислам үсеше департаменты (JAKIM) экспертлары булып китте

Рамазан аеның 21 нче көнендә (21 март) Нәзарәттә Малайзия Ислам үсеше департаментының хәләл идарә буенча халыкара советы башлыгы Мөхәммәд Замри бине Мөхәммәд Шапик һәм аның ярдәмчесе доктор Җөһәри бине Габдүл-Латыйп булып китте. Алар белән Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин очрашты. Очрашуда мөфтиятнең «Хәләл» стандарты буенча комитет җитәкчесе Аббяс хәзрәт Шляпошников та катнашты. Экспертлар Казанга Комитет эшчәнлегенең Малайзиядәге дәүләт стандартына туры килү-килмәвен тикшерү һәм, алга таба аккредитацияләү өчен, танышырга дип килде. Сәфәр вакытында алар шулай ук республика районнарында хәләл продукция җитештерүчеләр белән дә танышты.

## Татарстанлылар Россиякүләм Коръән бәйгесендә призлы урыннар алды

19–20 нче мартта Грозный шәһәрендә Хутмат Кадыйрова башлангычы белән Чечен Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте белән берлектә «Woman in Islam» проекты тарафыннан оештырылган хатын-кызлар арасында Беренче Россиякүләм Коръән хафизлар бәйгесенең финал этабы узды. Анда катнашучылар Коръәннең 10 җүзен яттан белергә тиеш иде. Татарстан вәкилләре уңышлы чыгыш ясады: Ашурова Шоира – I урын, Маликова Хәдичә II урын яулады.

## Татарстанда махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләре өчен ифтарлар узды

Татарстанда махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләре өчен ифтарлар узды. Яр Чаллы мөхтәсибәте махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләрен һәм якыннарын югалтучыларны чакырып, «Чаллы Яр» мәчете янындагы кафеда ифтар оештырды. Әлеге чарада 60 лап кеше – тол хатыннар, солдатларның әти-әниләре катнашты. Ә Түбән Кама мөхтәсибәте махсус хәрби операциядә хезмәт иткән мөселман солдатларына ифтарлар үткәрде.

## Казанда Беренче Хатын-кызлар ифтары узды

Казанда Беренче Хатын-кызлар ифтары оештырылды. Төрле яшьтәге ханымнар һәм төрле һөнәр ияләре, абыстайлар һәм Татарстанның төрле почмакларыннан мәшһүр ханымнар, күпбалалы әниләр, махсус хәрби операциядә хезмәт итүчеләрнең әниләре һәм хәләл җефетләре, Рамазан шатлыгын уртаклашу өчен, бергә җыелды. 600 мөслимә танылган дин әһеле, Мөфтинең беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәновның вәгазен тыңлады. Хатын-кызлар ифтарында әниләр һәм хәләл җефетләрнең күз яшьләре аша балалары һәм ирләре өчен дога кылуы күңел кылларын тибрәткән мизгел булды. Беренче Хатын-кызлар ифтарында күпбалалы әниләрне дә хөрмәтләделәр.

## Тукай районы мөхтәсибәте балалар арасында намаз бәйгесе оештырды

Тукай районы мөхтәсибәте балалар арасында намаз бәйгесе оештырды. Әлеге чара Күзкәй авылы мәчетендә узды һәм намаз уку дәресләренә йомгак ясау буларак үткәрелде. Ярыш өч раундтан торды. Биредә иман, намаз, тәһарәт, кыйбла, тарих кебек 15 теманың һәрберсе буенча 5 әр сорау бирелде. Барлык катнашучыларга һәм җиңүчеләргә сертификатлар һәм бүләкләр тапшырылды. Бәйге тәмамланганнан соң, ифтар мәҗлесе үткәрелде.

## Сабада 650 гә якын бала өчен ифтар үткәрелде

Рамазан аеның 24 нче көнендә Байлар Сабасы бистәсендә мәктәп бинасында 650 гә якын ураза тотучы бала өчен ифтар мәҗлесе үткәрелде. Мәҗлес елдагыча район җитәкчелеге, Саба мөхтәсибәте тарафыннан иганәчеләр, шәхси эшмәкәрләр, аерым затларның садака акчасына оештырылды. Рамазан аенда ураза тотучы яшүсмерләргә һәм яшьләргә вәгазь-нәсыйхәт сүзләрен Татарстанның Баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев җиткерде. Балалар вәгазь тыңлады, викторинада катнашты, намаз укыды, бергәләп авыз ачты.

## Камил хәзрәт Казахстанның Казандагы Генераль консулы Ерлан Искаков белән очрашты

Рамазан аеның 28 нче көнендә (28 мартта) Нәзарәттә Казахстанның Казандагы Генераль консулы Ерлан Искаков булып китте. Мөфтияттә аны Татарстан мөселманнары башлыгы, Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин каршы алды. Мөхтәрәм кунак һәм Мөфти Татарстан һәм Казахстан халыклары арасында дин, тел һәм тарихи яктан элемтәләрне ныгытуның мөһимлеген билгеләп үтте, мондый хезмәттәшлекнең мәдәни аңлашуны тирәнәйтергә һәм дустанә мөнәсәбәтләрне ныгытырга ярдәм итәчәген белдерде.

## Казанның Мәрҗани мәчетендә Татарстан Рәисе катнашында Ураза гаете билгеләп үтелде

Шәүвәл аеның 1 нче көнендә (30 мартта) бөтен дөнья мөселманнары бөек бәйрәм – Ураза гаетен – билгеләп үтте. Бу уңайдан Татарстан Республикасының барлык мәчетләрендә иртәдән үк бәйрәм чаралары башланды. Татарстанның төп бәйрәм тантанасы, берникадәр вакыт тукталып торганнан соң, тәүге тапкыр яңартылган Мәрҗани мәчетендә узды. Бу уңайдан ТР Милли музее мәчет халкына кыйммәтле бүләк ясады: Мөфти Камил хәзрәткә, Гает вәгазен укыр өчен генә, фондның иң кыйммәтле ядкаре – Мәрҗанинең чын вәгазь таягы – тапшырылды. Бәйрәм вәгазен тыңлаганнан соң, мөселманнар Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә намаз укыды. Мәртәбәле кунаклар арасында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов бар иде. Мәрҗани мәчетендәге бәйрәм чараларын «ТНВ Татарстан» һәм «ТНВ Планета» телеканалы аша турыдан-туры карарга мөмкин булды.

## Мәрҗани мәчетендә Халыкара Әл-Кудс көнен билгеләп үттеләр һәм Газзәдәге дин кардәшләр өчен дога кылдылар

Рамазан-шәриф аеның соңгы җомгасында, 28 мартта, бөтен дөньяда Халыкара Әл-Кудс көне билгеләп үтелде, мөселман өммәте Фәләстыйн халкына теләктәшлек белдерде һәм киң җәмәгатьчелекнең игътибарын Фәләстыйн

мәсьәләләренә юнәлтте. Казанның Мәрҗани мәчетендә дә җомга намазыннан соң шул уңайдан чара узды. Анда Татарстан Мөфтиенең мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча урынбасары, Мәрҗани мәчете имам-хатыйбы Равил хәзрәт Зөфәров, Иранның Казандагы Генераль консулы Давуд Мирзахани, «ТР Гарәп студентлары берлеге» иҗтимагый оешмасы рәисе Алхамсс Ясер Шәфикъ һәм башкалар катнашты. Алар ТР Рәисе Рөстәм Миңнехановка һәм Татарстан мөфтиятенең «Зәкят» хәйрия фондына Газзә секторында яшәүчеләргә күрсәткән гуманитар ярдәме өчен ихлас рәхмәтләрен белдерде. Ахырдан алар: «Йә Бөек Раббыбыз, мөселманнарны явызлыктан һәм җәберләүләрдән сакла, аларга дошманны җиңәргә мөмкинлек бир һәм Фәләстыйнда гаделсезлекне туктат», – дип дога кылды.

## РФ Саклану министрлыгының Казан шәһәрендәге Хәрби госпиталендә беренче тапкыр Гает намазы үтте

РФ Саклану министрлыгының Казан шәһәрендәге Хәрби госпиталендә беренче тапкыр Гает намазы үтте. Аны «Ал таң» мәчете имамы Ирек хәзрәт Җиһаншин алып барды. Намазда 35 кеше – махсус хәрби операция вакытында яраланып, хәзер госпитальдә дәваланучылар – катнашты. Ирек хәзрәт ил һәм Республика җитәкчеләренең, Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның Ураза гаете белән котлауларын җиткерде.

## Татарстан шәһәрләрендә һәм районнарда Ураза гаете уңаеннан бәйрәм чаралары узды

30 мартта Татарстан шәһәрләрендә һәм районнарда Ураза гаете уңаеннан гомумшәһәр балалар һәм гаилә бәйрәмнәре узды. Мөхтәсибәтләр, гадәттәгечә, паркларда һәм мәчетләр янында бәйрәмнәр оештырды. Алар сый-нигъмәт, төрле бәйгеләр, викториналар, эстафеталар, милли уеннар, спорт ярышлары һәм мәдәни программа, тәмле сыйлар, пылау тәкъдим итте.

Казанда Әхмәдзәки һәм «Гаилә» мәчетләрендә узган бәйрәмдә хәзрәтләр вәгазьләр сөйләде, балалар Коръән укыды, саф һавада уеннарда, остаханәләрдә,

викторинада, аттракционнарда катнашты. Ураза бәйрәме Апанай мәчете янәшәсендә дә узды. «Иман нуры» мәчетендә дәресләргә, тәравих намазларына йөргән балалар өчен «Коръән бәйрәме» оештырылды. Казанда шулай ук «Рамазан Фест» шәһәркүләм гаилә фестивале дә оештырылды.

## Казанда кызлар һәм егетләр өчен «Яшь килен» һәм «Яшь кияү» Ислам курслары узды

Апрель-май айларында Казанда яшьләр өчен берьюлы ике Ислам курсы: яшь кызлар өчен – «Яшь килен» һәм егетләр өчен – «Яшь кияү» курслары эшләде. «Яшь килен» курслары инде 12 нче тапкыр оештырылып, онлайн форматта узса, «Яшь кияү» Ислам курслары тәүге тапкыр үткәрелде һәм офлайн форматта Казан мөселманнарын гына җыйды.

«Яшь килен» һәм «Яшь кияү» курслары, гаилә хәленә һәм социаль статусына карамастан, барлык яшьтәгеләр өчен дә һәм гаилә корырга ниятләүчеләргә дә, никахта торучыларга да, якын киләчәктә улын өйләндерергә яки кызын кияүгә бирергә ниятләүчеләргә дә бертигез дәрәҗәдә файдалы булды. Әлеге проектлар мөселман яшьләре арасында гаилә кыйммәтләрен ныгыту максатыннан тормышка ашырылды, шәригать һәм татар халкы гореф-гадәтләренә нигезләнеп, никахка кагылышлы төрле мәсьәләләргә багышланды. Белем бирү курсы Коръәнгә, Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам Сөннәтенә, дин галимнәре дәресләренә нигезләнгән күп төрле белемнәрне үз эченә алды.

## Татарстанда җәмәгать урыннарын иң матур тышкы бизәү буенча «Нурлы Рамазан» бәйгесе узды

Шәүвәл аеның 5 нче көнендә (3 апрельдә) Нәзарәттә җәмәгать урыннары арасында иң матур бизәлештә ярышу буенча «Нурлы Рамазан» бәйгесендә җиңүчене һәм финалга чыгучыларны бүләкләү тантанасы булды.

Бәйгедә җиңүче булып Мөслим районы Баланлы авылында үзләре яшәгән йортны бизәгән Гүзәл һәм Җәмил Газыймовлар гаиләсе танылды.

Аларга төп бүләк – Нәзарәтнең «ДУМ РТ Хадж» рәсми операторыннан хаҗга юллама – тапшырылды.

Җиңүчеләр үз капка һәм йортны бизәү белән генә чикләнмәгән, ә бөтен әйләнә-тирәне – каралты-кураларны, койманы, хәтта урам-тыкрык өлешен дә – бизәгән. Ул, ерактан ук балкып, зур хәрефләр белән язылган «Рамазан» һәм «СөбханАллаһ» сүзләре белән игътибарны әллә кайдан җәлеп итеп торды. Шунысы да игътибарга лаек: Газыймовлар, гаять тырышлык һәм үҗәтлек күрсәтеп, «Нурлы Рамазан» бәйгесендә ел саен катнашып килә. Узган ел алар финалга чыкты, ә быел җиңүче булды.

Быел бәйгегә барлыгы 38 эш килеп иреште: Рамазан ае хөрмәтенә шәхси йортлар, мәчетләр һәм җәмәгать урыннары бизәлде. Быел дини оешмалар (мәчетләр, мәдрәсәләр һәм мәгърифәт үзәкләре) аеруча зур активлык күрсәтте – барлыгы 21 гариза килде: күпчелекне Казан шәһәре, Арча, Алабуга, Мамадыш һәм Чистай районнары тәшкил итте.

## Казанда «Сөембикә энеләре һәм сеңелләре» дини-милли бәйгесе узды

«Гаилә» мәчетендә «Сөембикә энеләре һәм сеңелләре» дип аталган XXIV Бөтенроссия дини-милли бәйгесе оештырылды. Ул балалар арасында Коръәнне, Ислам нигезләрен яхшы белүчене ачыклау, яшь буынга рухи-әхлакый тәрбия бирү, Ислам нигезләре белән бәйле белемнәрен арттыру, милли тарихыбызны өйрәнергә чакыруны максат итеп куйды. Билгеле булганча, әлеге бәйгенең башында танылган татар журналисты һәм җәмәгать эшлеклесе Әлмира апа Әдиатуллина тора.

Бәйгедә Казанның «Шамил» мәдрәсәсе, «Бишбалта», «Ал таң», «Казан нуры», «Гаилә», Әхмәтзәки, Зәңгәр, «Тәүфыйк», «Өметлеләр» мәчетләре, «Белем нуры» бакчасы, Лаешның Усад авылының «Ихлас» мәчете, Нагорный бистәсенең «Иман нуры» мәчете, «Госмания» мәктәбе, Осиново мәчете, Биектауның «Бердәмлек» мәчете, Яшел Үзәннең «Гөлбакча» бакчасы һәм «Тынычлык» мәчетләреннән, Самара өлкәсеннән 80 нән артык бала катнашты.

## Балтач мөхтәсибәтендә Коръән укучылар бәйгесе үтте

Шәүвәл аеның 8 нче көнендә (6 апрельдә) Балтач мөхтәсибәтендә балалар һәм яшүсмерләр арасында районкүләм Коръән укучылар бәйгесе узды. Анда районның төрле авылларыннан җыелган 4 яшьтән алып 17 яшькәчә кадәрге 230 дан артык ир бала һәм кызлар катнашты. Алар 8 номинациядә белемнәрен күрсәтте.

Балтач мөхтәсибәтендә Коръән укучылар бәйгесе тәүге мәртәбә 1994 елда оештырылган иде. 2008 елдан башлап ул һәр елны үткәрелә.

## Казанның Тынычлык бистәсендә яңа Камил мәчете ачылды

Шәүвәл аеның 13 нче көнендә (11 апрель) Казанның Тынычлык бистәсендә яңа Камил мәчете үз ишекләрен ачты. Биредә мәхәллә кешеләре тәүге мәртәбә Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә җомга намазын укыды. Тантаналы ачылыш чарасына, халыкның һәм иганәчеләрнең шатлыгын уртаклашырга дип, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм башка мәртәбәле кунаклар килде.

Мәчетнең тышкы күренеше игътибарга лаек: аның манарасы – Болгардагы 14 нче гасырдагы уникаль архитектура һәйкәле булган «Кече манара»ның төгәл күчермәсе. Мәчет тышкы һәм эчке яктан Дагъстаннан кайтартылган таш белән тышланган; эчке бизәлеше Идел буе Болгарстанындагы 10 нчы гасыр интерьерларын хәтерләтә.

## Шәүвәл аеның 13 нче көнендә Казанда Хәтер көне узды

Шәүвәл аеның 13 нче көнендә Казанда традицион Хәтер көне – динебез, Ватаныбыз, милләтебез хакына шәһит киткән татар каһарманнарын искә алу көне – узды. Әлеге чарада Татарстан мөфтиятенең барлык мөхтәсибәтләреннән аксакаллар, имамнар һәм барлык теләгән дин кардәшләребез катнашты. Нәзарәттә Аксакаллар шурасы утырышы белән башланып киткән чараның төп өлеше Казанның төзекләндерелгән «Иске таш» мәчетендә узды. Мәчет Хәтер көнен үткәрү өчен юкка гына сайланмаган: ул Казан алынганда шәһит булып киткән кардәшләр

каберлегендә төзелгән. Кабер зур иске таш белән билгеләнгән, шуңа күрә мәчеткә «Иске таш» дип исем бирелгән.

Быел Хәтер көне мөһим вакыйга белән истә калды: җомга намазын укыганнан соң, җыелган халык «Иске таш» мәчете янәшәсендә киләчәктә «Татар халкы каһарманнары истәлегенә» мемориаль стела урнаштырылачак урында символик таш куюда катнашты. Бу уңайдан аксакаллар Коръән аятьләре укыды һәм татар халкының шәһит булып киткән уллары рухына дога кылды.

## Тукай мөхтәсибәтендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләре өчен Коръән ашы узды

Тукай мөхтәсибәтенең Калмаш авылында махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләре өчен Коръән ашы узды. Аларны имам-мөхтәсиб Инсаф хәзрәт Сәубанов һәм башка хәзрәтләр, җирле хакимият вәкилләре сәламләде. Хәзрәтләр, сугышчыларның якыннарына теләктәшлек белдереп, аларга үгет-нәсыйхәтләр бирде, һәлак булган һәм МХОда булган сугышчылар өчен дога кылдылар.

## Нәзарәтнең «Хәләл» стандарты комитеты SMIIC стандартлары буенча халыкара аккредитация алды

Нәзарәтнең «Хәләл» стандарты комитеты SMIIC стандартлары буенча халыкара аккредитация алды. SMIIC – Ислам дөньясы илләрендә бердәм хәләл стандартларын формалаштыручы халыкара оешма. Ул Ислам хезмәттәшлеге оешмасы каршында эшли. Аңа Ислам дөньясына караган 57 ил керә. Россия дә – SMIIC әгъзасы (ул бу оешмада күзәтүче буларак эшли).

SMIIC стандартлары буенча халыкара аккредитация алу мөселман җитештерүчеләре өчен чит ил базарларына чыгуны җиңеләйтә. Алар җитештергән продукция Диния нәзарәте тарафыннан бирелгән хәләл таныклык белән мөселман дөньясында көндәшлеккә сәләтле булачак һәм чит ил кулланучыларында ышаныч уятачак.

## Казанда кызлар һәм хатын-кызларның III Бөтенроссия Коръән бәйгесе узды

Шәүвәл аеның 16 нчы көнендә (14 апрельдә) Казанда кызлар һәм хатын-кызлар арасында «Коръәнгә мәхәббәт белән» III Бөтенроссия Коръән бәйгесе тәмамланды. Анда Татарстаннан Шоира Ашурова («Тулы Коръәнне яттан белү») җиңүче булды, ул гомрәгә юллама белән бүләкләнде. Бәйге Коръән өйрәнүгә омтылышны үстерү, Коръән ятлаган мөслимәләрне хуплау һәм рухи-әхлакый кыйммәтләрне ныгыту максатыннан үткәрелде.

## Мөфти Камил хәзрәт ТР Рәисе ярдәмчесе Марат Гатин белән очрашты

Шәүвәл аеның 16 нчы көнендә (14 апрельдә) Нәзарәттә Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин ТР Рәисе ярдәмчесе Марат Гатин белән очрашты. Фикер алышу барышында «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме чаралары кысаларында хезмәттәшлек мәсьәләләре каралды. Җитәкчеләр 2025 елга ниятләнгән чаралар планы хакында фикер алышты. Алар агымдагы елның маенда Казанда «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» XVI Халыкара икътисади форумы кысаларында узачак «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме утырышын оештыру мәсьәләләре буенча фикер алышты.

## Казанда «Татар милли киеме» көне узды

Шәүвәл аеның 19 нчы көнендә (17 апрель) Казанда «Татар милли киеме көне» узды. Ул бүгенге көндә милли кием стилен саклау һәм популярлаштыруны максат итеп куйды. Нәзарәтнең хатын-кызлар белән эшләү бүлеге һәм ТР Мөслимәләр берлеге оештырган чарага бөтен Татарстаннан кул осталары, абыстайлар, татар милли киеме өлкәсендә эшләүче дизайнерлар – барлыгы 140 кеше җыелды.

Кичә Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигулинның Коръән укуыннан башланып китте. Аннан соң ул киемнең Коръән һәм Сөннәттә килгән хөкемнәре белән таныштырды. Мөфти шулай ук хиҗабның хатын-кызлар өчен мәҗбүрилеген һәм

үзенә күрә бер җиһад булуын, ягъни үзеңнең эчке дөньяңны тәрбияләү икәнлеген, искәртте. Милли киемне саклау һәм популярлаштыруга юнәлтелгән чараларның мөһимлеген билгеләп үтте.

## Мөфти җитәкчелегендәге Диния нәзарәте делегациясе Луганскида «Гасырлар аша батырлык: Ватанны саклаучылар истәлегенә» конференциясендә катнашты

Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендәге Диния нәзарәте делегациясе Луганскида Бөек Җиңүнең 80 еллыгына багышланган «Гасырлар аша батырлык: Ватанны саклаучылар истәлегенә» дип аталган конференциядә катнашты. Татарстан делегациясе конференциягә ЛХР мөфтие Мөхәммәд хаҗи Исмаил чакыруы буенча килде: анда шулай ук Татарстан Мөфтиенең беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов, казый Марат хәзрәт Мәрданшин һәм башкалар керде. Шул рәвешле, ЛХР Диния нәзарәте бер мәйданчыкта хәзрәтләрне һәм МХОда катнашучыларны җыйды, анда Бөек Ватан сугышы каһарманнарын искә алдылар һәм махсус хәрби операциядә катнашучы солдатларны хөрмәтләделәр. Татарстан хәзрәтләре шулай ук ЛХР Диния нәзарәте соравы буенча мөфти Мөхәммәд хаҗи Исмаилга рус телендә «Калям Шариф. Перевод смыслов» басмасын тапшырды.

## Мөфти «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме җитәкчелегенең Ислам хезмәттәшлеге оешмасы дәүләтләре илчеләре белән очрашуында катнашты

Шәүвәл аеның 23 нче көнендә (21 апрельдә) Мәскәүдә «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме җитәкчелегенең Ислам хезмәттәшлеге оешмасына кергән дәүләтләрнең илчеләре белән очрашуы булды. Чарада Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин, Россия Тышкы эшләр министры Сергей Лавров, Татарстан Рәисе, «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме рәисе Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Баш мөфти Тәлгать хәзрәт Таҗетдин һәм башкалар катнашты.

Җыелышның төп темасы илчеләргә Төркемнең 2024 елдагы эш нәтиҗәләре һәм агымдагы елдагы эшчәнлек перспективалары турында мәгълүмат бирү белән бәйле иде. Шул исәптән Стратегик караш төркеменең Казанда «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисади форумы көннәрендә 15-16 майда узачак «Россия һәм Ислам дөньясы илләренең яшьләр сәясәте өлкәсендәге тәҗрибәсе: гомуми чакырулар һәм уртак гамәлләр» дигән утырышы хакында сөйләделәр.

## Алабуга мөхтәсибәтендә Коръән укучылар бәйгесендә 90 га якын бала катнашты

Алабуга мөхтәсибәтендә Коръән укучылар конкурсы узды: анда 15 яшькә кадәрге 90 га якын бала катнашты. Чара Җәмигъ мәчетендә узды. Бәйгенең бәяләү кагыйдәләре үзгәрешсез калды: сүрәләрне яттан хатасыз уку, өйрәнелгән сүрәләр саны, Коръәнне оригиналда уку осталыгы исәпкә алынды. Моннан тыш, катнашучының тышкы кыяфәтенә дә игътибар бирелде.

## Диния нәзарәте казые Марат хәзрәт Мәрданшин алгы сызыкта солдатлар янында булды һәм 90 нчы танк дивизиясенең 80 нче полкында блиндажлы мәчет ачуда катнашты

Диния нәзарәте казые, Ютазы районы имам-мөхтәсибе, «Фәнис» мәдрәсәсе директоры Марат хәзрәт Мәрданшин бу көннәрдә махсус хәрби операциядә алгы сызыкта хезмәт итүче солдатлар янына барды. Ул «Батыр» батальонында, 90 нчы танк дивизиясендә һәм башка хәрби частьләрдә булды. Полк имамы Мөхәммәд хәзрәт Хәйруллаев белән бергә алар сугышчыларга кече Ватаннан җылы сәлам тапшырды, үгет-нәсыйхәтләр бирде, җәмәгать белән намазлар укыды һәм дога кылды.

90 нчы танк дивизиясенең 80 нче полкы хәрбиләре янына бару истәлекле булды: монда Диния нәзарәтенең полк имамы Мөхәммәд хәзрәт тырышлыгы һәм командование ярдәме белән блиндажлы мосаллә ачылды. 15 кв.м мәйданлы «мәчет» 90 нчы танк дивизиясенең 80 нче полкының даими җыелу урынында корылган. Мәчетнең стеналары һәм идәннәре ак материал белән тышланган. Идәнгә

келәмнәр җәелгән. Диния нәзарәте вәкилләре мәчеткә бүләкләр: намазлыклар, шамаил, дивар сәгате, китаплар бүләк иттеләр. Биредә намазлар укылачак һәм солдатлар белән рухи әңгәмәләр үткәреләчәк.

## Балтач мөхтәсибәтендә рухи-әхлакый тәрбия буенча «Күркәм холык – бәхет ачкычы» республикакүләм семинары узды

Шәүвәл аеның 25 нче көнендә (23 апрельдә) Балтач районының Сосна төп гомумбелем бирү мәктәбендә рухи-әхлакый тәрбия буенча «Күркәм холык – бәхет ачкычы» дип аталган республикакүләм семинар узды. Мөгаллимнәрнең ачык әхлак дәресе һәм «Иман берлә Коръән тулган садремә...» дип аталган сыйныфтан тыш чара шагыйрь Г. Тукай иҗатына багышланган иде.

Алга таба Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан мөселман мәдрәсәсенең Балтач филиалын тәмамлаучыларның чыгарылыш кичәсе узды. Мәдрәсәнең кичке бүлеген тәмамлаган 30 белгеч урта һөнәри белем турында диплом алды.

## РИИда татар һәм гарәп телләре һәм Ислам фәннәре буенча олимпиадалар узды

Шәүвәл аеның 26 нчы көнендә (24 апрель) Россия Ислам институтында урта һөнәри Ислам уку йортлары шәкертләре арасында Ислам фәннәре һәм гарәп теле буенча Бөтенроссия олимпиадасы; шулай ук мәдрәсәләр һәм Ислам югары уку йортлары шәкертләре арасында татар теле, татар әдәбияты һәм татар халкы тарихы буенча V республика олимпиадасы узды.

Олимпиадалар Россия Ислам институты һәм РФ Ислам мәгарифе советы тарафыннан Ислам мәдәниятенә, фәненә һәм мәгарифенә ярдәм фонды, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте, шулай ук РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе теләктәшлегендә үткәрелде. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: бу – Ислам мәгарифе тарихында Ислам мәдрәсәләре укучылары арасында уздырылган

беренче Бөтенроссия олимпиадасы. Элек мондый чаралар төбәк дәрәҗәсендә генә оештырыла иде.

## Казанның «Госмания» мөселман мәктәбе 30 еллык юбилеен билгеләп үтте

Шәүвәл аеның 27 нче көнендә (25 апрель) башкаланың борынгы Мәрҗани мәчетендә Казан шәһәренең «Госмания» урта гомуми белем бирү мәктәбенең 30 еллыгы уңаеннан тантана узды. Юбилейга багышланган чарада мәктәп тарихы турында сөйләделәр һәм 30 еллык эшчәнлеккә йомгак ясадылар, мәктәпнең беренче директоры Камил Вәлиуллинның «Госмания – иман һәм белем чишмәсе» китабын тәкъдим иттеләр.

## Апанай мәчетенең Коръән укырга өйрәнү буенча онлайн курсларын уңышлы тәмамлаган 500 укучыга сертификатлар тапшырылды

Шәүвәл аеның 28 нче көнендә (26 апрельдә) Казанда Апанай мәчетенең Коръән укырга өйрәнү буенча онлайн курсларын тәмамлаучыларга сертификатлар тапшырдылар. Сертификатларны Россиянең төрле төбәкләреннән, шул исәптән Татарстан Республикасыннан, Башкортстан Республикасыннан, Ульяновск һәм Самара өлкәләреннән, шулай ук Урал һәм Себер төбәкләреннән килгән 500 мөселман алды. Укуларны барлыгы 950 кеше тәмамлады.

## Лениногорскида XII «Гыйлем нуры» бәйгесе узды

Шәүвәл аеның 28 нче көнендә (26 апрель) Лениногорск шәһәренең «Ихлас» мәчетендә Лениногорск мөхтәсибәте оештырган XII «Гыйлем нуры» конкурсы узды. Бәйгедә Азнакай, Баулы, Бөгелмә, Әлмәт, Мөслим, Сарман, Кукмара, Ютазы, Чирмешән, Нурлат, Балтач, Яңа Чишмә, Арча, Алабуга, Лениногорск һәм Тукай районнары мөселманнары – барлыгы 16 команда көч сынашты. Шунысы үзенчәлекле: әлеге командаларга октябрьдән алып майга кадәр мәчет каршындагы курсларда

белем алган абыстайлар кергән. Алар Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшриятында басылган «Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә», Әхмәтһади Максудиның «Мөгаллим сәни», «Ислам дине нигезләре», шулай ук пәйгамбәрләрнең тормыш юлы турындагы хезмәтләргә нигезләнгән биремнәрне үтәде. Бәйге нәтиҗәләре буенча Алабуга мөхтәсибәте командасы иң күп балл җыйды һәм җиңүче булып танылды.

## Нәзарәт һәм Казан мәдрәсәләре коллективлары Казанның Яңа татар зиратында өмә үткәрде

Зөлкагъдә аеның 1 нче көнендә (29 апрельдә) Татарстан мөфтияте, «Мөхәммәдия» һәм Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә мөгаллимнәре һәм хезмәткәрләре, Казан шәһәренең Яңа татар зиратында өмә оештырып, аның шактый зур өлешен тәртипкә китерде. Быелгы чара Ватанны саклаучылар елы кысаларында оештырылды һәм Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгына багышланды. Катнашучылар ветераннарның һәм дин әһелләренең каберләрен чүп-чардан, кипкән үләннәрдән һәм корыган агачлардан аралады, аллеяларны себереп җыештырды, кабер ташларын чистартты. Биредә җирләнгән дин әһелләренең, күренекле мәгърифәтчеләрнең, остазларның рухларына җәмәгать белән дога кылынды.

## Казанның Яңа бистә зиратында остазларны искә алу көне узды

Зөлкагъдә аеның 4 нче көнендә (2 майда) мөселман дин эшлеклеләре, мөгаллимнәр, шәкертләр, татар зыялылары Казанның Яңа бистә зиратына җыелды – биредә остазларны искә алу көне үтте. Быелгы чара Ватанны саклаучылар елы кысаларында Бөек Җиңүнең 80 еллыгына багышлап үткәрелде.

Алар тарихта тирән эз калдырган күренекле дин әһелләре һәм галимнәр – Шиһабетдин Мәрҗани, Галимҗан Баруди, Әхмәтһади Максуди, Әхмәдзәки хәзрәт Сафиуллин, Габделхак хәзрәт Саматов, Зәкәрия хәзрәт Минвәлиев, шулай ук Казанның соңгы ишаны, Бөек Ватан сугышында катнашкан Гарифулла ишан Гайнуллин – кабере янында Коръән укып дога кылды. Яңа бистә зиратында 100 гә якын мөселман дин әһеле, мәгърифәтче һәм галим җирләнгән дип санала.

Соңыннан Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәдә Коръән ашы узды. Биредә Коръән хатем кылынды һәм аның савабы мәрхүмнәр рухына багышланды.

## Диния Нәзарәте Татарстанда Корбан бәйрәмен уздыру тәртипләрен билгеләде

Татарстан мөфтияте 2025 елда Корбан бәйрәмен һәм гает намазын үткәрү тәртипләрен раслады.

Гарәфә көне – 5 июньгә, Корбан гаете 6 июньгә туры килә. Бу көнне Татарстан мәчетләрендә җәмәгать белән бәйрәм намазлары үтә. Гает намазы укылганнан соң, махсус билгеләнгән урыннарда корбан чалу башлана һәм 8 нче июньдә кояш баеганчы дәвам итә. Корбан нисабы күләме – 53 мең сум. 5, 6, 7, 8 һәм 9 нчы июнь көннәрендә тәкбир әт-тәшрикъ көннәре билгеләп үтелә.

## Нәзарәт Җиңү көне уңаеннан махсус хәрби операциядә катнашучыларга гуманитар йөк тапшырды

Татарстан мөфтияте, Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын каршы алып, махсус хәрби операция зонасында хезмәт итүче солдатларга чираттагы гуманитар ярдәмне илтеп кайтты. Диния нәзарәте делегациясе янәдән Луганск юнәлешендәге алгы сызыкка барды: биредә 621 нче артиллерия дивизионы һәм «Батыр» батальоны сугышчылары белән очрашты.

Гуманитар йөк сугышчыларның теләкләрен искә алып әзерләнде: кыр шартларында туклану өчен хәләл коры ризык һәм киптерелгән җиләк-җимешләр, медицина препаратлары, авыртуны баса торган дарулар кергән аптечкалар, компьютер техникасы, портатив заряд станциясе, элемтә өчен Starlink, «Терминатор» сигналны басу җайланмасы, урын-җир кирәк-яраклары һәм маскировка челтәрләре, машина көпчәкләре (16 данә) һәм «КамАЗ» аккумуляторлары тапшырылды.

## Мөфти Менделеевск шәһәрендә урнашкан 10 нчы төзәтү колониясендә булды

Зөлкагъдә аеның 9 нчы көнендә (7 майда) Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Менделеевск районына эшлекле сәфәр кылды. Биредә ул 10 нчы төзәтү колониясендә булды һәм колония җитәкчесе Илдар Минәхмәтов белән очрашу үткәрде. Җитәкчеләр төзәтү колониясендә Корбан бәйрәмен үткәрүгә кагылышлы оештыру мәсьәләләре турында фикер алышты.

Аннары Камил хәзрәт 10 нчы төзәтү колониясенең «Тәүбә» мәчетендә тоткыннар белән аралашты: үгет-нәсыйхәтләрен ирештерде һәм дини мәсьәләләргә кагылышлы сорауларга җавап бирде. Иректән мәхрүм ителүчеләрне аеруча гыйбадәт тәртипләре һәм тәүбә кылу белән бәйле мәсьәләләр кызыксындырды.

## Урыссуда «Халисә» VI Россиякүләм Коръән укучылар бәйгесе узды

Зөлкагъдә аеның 12 нче көнендә (10 майда) Ютазы районы Урыссу бистәсендә хатын-кызлар арасында «Халисә» VI Россиякүләм Коръән укучылар бәйгесе үтте. Әлеге бәйге Мәрданшиннар гаиләсе башлангычы белән Татарстан мөфтияте, Ютазы мөхтәсибәте һәм Ютазы муниципаль районы ярдәме белән оештырылды. Бәйгедә Мордовия, Удмуртия һәм Башкортстан Республикаларыннан, Казан, Мәскәү, Уфа, Ижевскидан, Татарстан районнарыннан 75 кеше катнашты.

Бәйге нәтиҗәләре буенча «Коръәнне тулысынча яттан белү» номинациясендә җиңүче Шоира Ашурова гомрәгә юллама белән бүләкләнде.

## Казанда «Kazan Halal Market» хәләл ярминкәсе эшләде

«Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2025» XVI халыкара икътисади форумы кысаларында «Казан» Агросәнәгать паркында «Kazan Halal Market» Халыкара хәләл продукция ярминкәсе эшләде. Ярминкәне Мөфти Камил хәзрәт Коръән аятьләре укып ачты.

Хәләл маркетта сатыла торган барлык товарлар төрле оешмаларда сертификацияләр алган иде һәм өстәмә рәвештә Диния Нәзарәтенең «Хәләл» стандарты буенча Комитеты тарафыннан тикшерелде. Аерым алганда, Комитет белгечләре ярминкәдә эшләүче сатучыларның һәм җитештерүчеләрнең чималларын, продукциясен, шулай ук сату-алу шартларын «хәләл» стандартларына туры килү-килмәвен тикшерде.

Ярминкәдә Россия Федерациясенең 15 төбәгеннән, Әфганстан, Пакъстан, Казахстан, Азербайҗан, Кыргызстан, Төркия, Иран, Һиндстан һәм Сенегал кебек илләрдән барлыгы 150 дән артык оешма катнашты.

## KazanForumда Татарстан Диния нәзарәтенең мәйданчыклары эшләде

13–18 майда Казанда «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2025» XVI Халыкара икътисади форумы узды. Форумның максаты: Россия Федерациясе төбәкләренең һәм Ислам Хезмәттәшлеге оешмасы илләренең сәүдә-икътисади, фәнни-техник, социаль һәм мәдәни элемтәләрен ныгыту, шулай ук Россия Федерациясендә ислам финанс системасы институтларын үстерүгә ярдәм итү. KazanForum кысаларында Диния нәзарәте берьюлы берничә тематик мәйданчык оештырды. Казанның Агросәнәгать паркында эшләгән Халыкара «Kazan Halal Market» хәләл продукция ярминкәсен оештыруда Нәзарәтнең «Хәләл» стандарты буенча комитеты зур өлеш кертте. Әлеге комитет «2030: хәләл индустрия стратегиясе» дип аталган сессия үткәрде.

## Татарстан Мөфтие Коръән укып «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» XVI Халыкара икътисади форумын һәм «Russia Halal Expo 2025» халыкара күргәзмәсен ачып җибәрде

Зөлкагъдә аеның 17 нче көнендә (15 майда) «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәгендә «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» XVI Халыкара

икътисади форумы һәм «Russia Halal Expo 2025» халыкара күргәзмәсе тантаналы рәвештә ачылды. Әлеге чарада беренче булып Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин чыгыш ясады – ул экспозицияне Коръән аятьләре укып ачып җибәрде.

«Russian Halal Expo» күргәзмәсе Россиядә инвестиция һәм инфраструктура проектлары буенча зур күргәзмәләрдән санала, ул бизнес-проектларны үстерү өчен яхшы мөмкинлек булып тора һәм катнашучылар арасында эшлекле элемтәләр булдыру мәйданчыгын тәшкил итә.

## Нәзарәт һәм Фарсы култыгы дәүләтләре һәм Йәмән Республикасы хезмәттәшлеге советының аккредитация үзәге арасында Меморандум имзаланды

Зөлкагъдә аеның 17 нче көнендә (15 май) «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2025» XVI Халыкара икътисади форумы мәйданчыгында Диния нәзарәте һәм Фарсы култыгына кергән гарәп дәүләтләре һәм Йәмән Республикасы хезмәттәшлек советының аккредитация үзәге арасында Меморандум имзаланды. Меморандумга Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Фарсы култыгына кергән гарәп дәүләтләре һәм Йәмән Республикасы хезмәттәшлек советының аккредитация үзәге генераль директоры Мотеб әл-Мезани кул куйды.

## Нәзарәтнең «Хәләл» стандарты комитеты Кыргызстан, Казахстан һәм Беларусь белән үзара тану турында Меморандумнар имзалады

«Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2025» XVI халыкара икътисади форумы мәйданчыгында Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты буенча комитеты белән Кыргызстан, Казахстан һәм Беларусь Республикасының хәләл сертификацияләү өчен вәкаләтле органнары арасында үзара тану турындагы Меморандумнар имзаланды. Хәзер Комитетның хәләл өлкәсендәге хезмәттәшлеге Казахстан мөселманнары Диния нәзарәте каршындагы «Халал Даму» стандартлаштыру һәм сертификацияләү үзәге; Кыргызстан Республикасы Икътисад

һәм коммерция министрлыгы каршындагы «Хәләл индустрияне үстерү үзәге» дәүләт учреждениесе һәм Белоруссиянең «БелХәләл» ҖЧҖ «Хәләл» стандартлаштыру һәм сертификацияләү үзәге белән документаль рәвештә беркетелде.

## Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты комитеты Малайзиянең Ислам үсеше департаменты (JAKIM) аккредитациясен алды

«Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2025» XVI халыкара икътисади форумы кырларында Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хәләл» буенча стандарты комитетына хәләл продукцияне сертификацияләү буенча халыкара лидерларның берсе булган Малайзия Ислам үсеше департаментыннан (JAKIM) аккредитация аттестаты тапшырылды. Комитет рәисе Аббяс хәзрәт Шляпошниковка аны «Малайзия Ислам үсеше департаменты» генераль директоры Сиражетдин Сухайми тапшырды. Бу вакыйга Татарстан Республикасы һәм Россия өчен зур әһәмияткә ия. JAKIMнан аккредитация алу комитетның хәләл сертификацияләү системасын халыкара дәрәҗәдә тануны аңлата. Ул сертификацияләнгән җитештерүчеләргә Көньяк-Көнчыгыш Азия һәм Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләренең глобаль базарларына керү мөмкинлеген ача.

## Татарстан Мөфтие «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме утырышын Коръән укып ачты

Зөлкагъдә аеның 18 нче көнендә (16 майда), Казанда «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеменең утырышы узды. Төркем утырышы «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» 2025 Халыкара икътисади форумы кысаларында узды. Чараның темасы «Россия һәм Ислам дөньясы илләренең яшьләр сәясәте өлкәсендәге тәҗрибәсе: уртак чакырулар һәм уртак гамәлләр» дип аталды. Утырышны Мөфти Камил хәзрәт ачып җибәрде – ул Изге Коръән аятьләрен укыды.

## Мөфти Нәзарәтнең Голамәләр шурасының яңа Ислам банк продуктларын хуплау турындагы карарларын тапшырды

Зөлкагъдә аеның 18 нче көнендә (16 майда) «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2025» Халыкара икътисади форумы кысаларында яңа финанс продуктларының шәригать таләпләренә туры килү турындагы сертификатлар тапшырылды. Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин кулыннан сертификатларны Россиянең 4 финанс оешмасы вәкилләре алды.

Нәзарәт «ТР Эшмәкәрлеккә теләктәшлек фонды»ның «Кард хасан – Развитие экспорта» продуктын; «ТБанк» АҖнең «Сервис Халяль Инвестиции» продуктын; «ПСБ банкы»ның «Исламский расчетный счет» һәм «Партнерский факторинг» продуктларын; «Мирас ФК» ҖЧҖнең «Кард хасан» продуктларын хуплады.

Яңа финанс продуктлары Россия Ислам икътисады һәм финанслары үзәге (РЦИЭФ) белән берлектә эшләнде һәм Диния нәзарәтенең Голамәләр шурасы тарафыннан хупланды. Бу финанс оешмаларының һәрберсенә, продуктларны гамәлгә кертүне тикшереп тору өчен, Диния нәзарәтенең Голамәләр шурасыннан шәригать күзәтүчесе беркетелгән.

## KazanForum 2025 тә Казан кулъязма Коръәне феномены турында сөйләделәр

Зөлкагъдә аеның 18 нче көнендә (16 майда) «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2025» XVI Халыкара икътисади форумы мәйданчыгында Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан «Каллиграфия сәнгате һәм аны хәзерге дөньяга интеграцияләү мөмкинлекләре» дип исемләнгән темага сессия үткәрелде. Сессиядә катнашучылар Ислам сәнгати мәдәнияте белән тыгыз бәйләнгән каллиграфия фәненең әһәмияте хакында фикер алышты.

Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин исеменнән сессиядә катнашучыларны аның урынбасары, Нәзарәтнең «Хозур» нәшрият йорты җитәкчесе Ришат хәзрәт Хәмидуллин сәламләде. Казан кулъязма Коръәне проекты хакында тулырак Шәех Мәэмүн Шәгъбән Хәлил әр-Рави сөйләде – ул Коръән хифзы буенча 10 кыйраәт

белгече, Фарсы култыгы илләрендә Коръән буенча бәйгеләрдә баш хөкемдар һәм жюри рәисе, пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнең нәсел дәвамчысы, Изге Коръән Дубай халыкара премиясе (DIHQA) Коръән әзерләү комиссиясе башлыгы, Казанда кулъязма Коръән әзерләү буенча комиссия әгъзасы.

## Татарстан Рәисе Мөфти Камил хәзрәтне Татарстанның «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләде

Казанда Бөтенроссия татар дин әһелләренең «Милли тормыш һәм дин» XV форумы барышында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинны Татарстанның «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләде. Медаль хәзрәткә рухи-әхлакый кыйммәтләрне саклауга һәм үстерүгә, динара тынычлыкны һәм татулыкны ныгытуга керткән зур өлеше өчен бирелде. Бу – Камил хәзрәтнең беренче дәүләт бүләге.

Моннан тыш, Нәзарәтнең хатын-кызлар белән эшләү бүлеге җитәкчесе, ТР Мөслимәләр берлеге рәисе Наилә Җиһаншинага «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» исеме бирелде. Ул бу исемгә татар милли киеме традицияләрен саклауга һәм популярлаштыруга өлеш кертүе өчен лаек булды.

## Мөфти Камил хәзрәт Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге X Укуларда катнашучыларны сәламләде

Зөлкагъдә аеның 19 нчы көнендә (17 майда) Мәрҗани мәчетендә «Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге укулар» X Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясенең пленар утырышы узды. Фәнни җыелыш РФ мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан оештырылды.

Анда Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашып, ТР мөселманнары Диния нәзарәте, РИИ һәм БИА белгечләренең Мәрҗани мирасын өйрәнү өлкәсендәге казанышлары турында җентекләп сөйләде. Билгеле булганча, Мәрҗани мирасын популярлаштыру өчен, Татарстан Диния нәзарәте галимнең 6 томлык җыентыгын чыгарды, ул бүгенге көнгә иң тулы җыентык булып санала. «Хозур»

нәшрият йорты һәм Россия Ислам институты Мәрҗанинең рус теленә тәрҗемә ителгән 4 мөһим фундаменталь хезмәтен бастырып чыгарды. Хәзерге вакытта Россия Ислам институтында Мәрҗанинең барлык төп хезмәтләре тәрҗемә ителеп бетте – бастыру өчен 10 томлык материал җыелды. Шулай ук Болгар Ислам академиясендә татар дин белгече Шиһабетдин Мәрҗани мирасы буенча 12 магистрлык һәм докторлык диссертациясе якланды.

## XV Бөтенроссия татар дин әһелләренең «Милли тормыш һәм дин» форумы узды

Зөлкагъдә аеның 19 нчы көнендә (17 майда) Бөтендөнья татарлар конгрессы Казанда XV «Милли тормыш һәм дин» Бөтенроссия татар дин әһелләре форумының пленар утырышын үткәрде. Форум эшендә илебезнең 74 төбәгеннән мөфтиләр һәм имамнар – барлыгы 1049 кеше катнашты. Форумда Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм Татарстан имамнары да эшләде.

## Шәһре Болгарда Изге Болгар җыены үтте

Зөлкагъдә аеның 20 нче көнендә (18 майда) Шәһре Болгарда, Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул ителү уңаеннан, Татарстан мөселманнары тормышындагы төп вакыйгаларның берсе – Изге Болгар җыены үткәрелде. Җыен «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2025» XVI Халыкара икътисади форумы мәдәни программасын тәмамлады. Болгар җыенында Татарстан Республикасы җитәкчелеге, Россия Федерациясе төбәкләреннән делегатлар, Россия мөфтиятләре, дини оешмалар, якын һәм ерак чит илләрдән мөселман җәмгыятьләре вәкилләре катнашты.

Елдан-ел Татарстан мөфтияте әлеге вакыйганы дини яктан үстерә, һәм быел да программага күбрәк вәгазьләр һәм мөнәҗәтләр кертелде. Кече манара янында җәмәгать белән тәүбә кылу Изге Болгар җыенының үзәк өлешен тәшкил итте. Аны күп еллар дәвамында оештырган Баш Мөфти, Россиянең Үзәк өлеше мөфтияте рәисе Тәлгать хәзрәт Таҗетдин алып барды. Җәмәгать белән Хан мәчетендә өйлә намазын уку Изге Болгар җыенының кульминацион өлеше булды.

## Казанда III Республикакүләм студентлар конференциясе узды

Зөлкагъдә аенның 24 нче көнендә (22 майда) Россия Ислам институтында «Хәзерге Россия мөселман яшьләренең бердәмлекне саклауда һәм ватанпәрвәрлекне ныгытудагы роле» III Республикакүләм студентлар фәнни-гамәли конференциясе узды. Фәнни җыенда уннан артык югары уку йортыннан, көллиятләрдән, мәдрәсәләрдән һәм гуманитар юнәлешләр буенча белем бирүче башка белем бирү учреждениеләреннән 100 дән артык студент катнашты.

Фәнни форумны Ислам мәдәниятенә, фән һәм мәгарифенә теләктәшлек фонды ярдәме белән Татарстан мөфтияте, Россия Ислам институты һәм Казан Ислам университеты оештырды.

Конференциядә катнашучылар Россиядә ислам дин гыйлеме һәм теология: тарихы һәм хәзерге торышы; яшь галимнәр күзлегеннән теологик белем; туган тел һәм әдәбият; күптөрле дини киңлектә чит телләр һәм мәдәниятләр; хәзерге җәмгыятьтә медиа һәм реклама: өйрәнелүе, үсеш баскычлары һәм киләчәге мәсьәләләренә багышланган секция утырышларында эшләде.

## РФ Президентының Төньяк Кавказ федераль округындагы Тулы вәкаләтле вәкиле Татарстан Мөфтиенә рәхмәт юллады

Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның Карачай-Черкессия Республикасына эш сәфәре вакытында аңа Россия Президентының Төньяк Кавказ федераль округындагы Тулы вәкаләтле вәкиле Юрий Чайканың Рәхмәт хатын тапшырдылар. Анда Камил хәзрәтнең Төньяк Кавказ федераль округы территориясендә динара һәм милләтара мөнәсәбәтләрне ныгытуга зур өлеш кертүе билгеләп үтелә. Татарстан Мөфтие даими рәвештә эксперт сыйфатында җәмгыятьтә динара тынычлыкны һәм татулыкны саклау һәм низагларны җайга салу мәсьәләләре буенча мәйданчыкларга җәлеп ителә.

## Питрәч районы Көек авылында төзелүче Фатыйма мәчетенә ай куелды

Питрәч мөхтәсибәте Көек авылында төзелүче Фатыйма мәчетенә тантаналы рәвештә ай куелды. 500 кешегә исәпләнгән ике катлы мәчет төзелеше 2023 елда башланып китә. Ул мәчет төзелешен башлап йөрүчеләрнең берсе төзелеш өчен үз җирен биргән Рафис Вәлиәхмәтовның әнисе хөрмәтенә «Фатыйма» дип аталган.

## Нәзарәт делегациясе МХО зонасына гуманитар ярдәм илтте

Татарстан мөфтияте делегациясе, Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин боерыгы буенча, чираттагы гуманитар йөк белән махсус хәрби операция зонасына барып кайтты. Татарстан мөселманнарыннан күчтәнәчләрне «Алга» һәм «Тимер» батальоннары, 430 нчы полк солдатларына, Донецк һәм Луганск Халык Республикалары госпитальләренә тапшырдылар. Делегацияне махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү буенча Татарстан Мөфтие урынбасары Мансур хәзрәт Җәләлетдинов җитәкләде. Гуманитар йөк меценатлар, Билал мәчете мәхәлләсе һәм Саба районының «Солдатка аш» волонтерлык оешмасы тарафыннан җыелды.

## Татарстан һәм Донецк мөфтиятләре бергәләп фәнни-дини конференция үткәрде

Донецкида «Нацизм һәм фашизмга көрәшүдә совет һәм Россия дини оешмаларының керткән өлеше» темага фәнни-дини конференция узды. Әлеге чараны Татарстан мөфтияте, Донецк Халык Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте Ислам мәдәнияте, фәне һәм мәгарифенә ярдәм фонды теләктәшлегендә Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгы һәм Россиядә игълан ителгән Ватанны саклаучылар елы уңаеннан оештырды.

Җыелышта Татарстан, Донецк Халык Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте имамнары, галимнәр, «Алга», «Тимер», «Батыр», Россия Герое, гвардия

майоры Александр Доставалов исемендәге башкорт батальоны, шулай ук 114 нче мотоукчылар бригадасының «Шторм» отряды вәкилләре һәм полк имамнары катнашты.

## Татарстаннан 1800 мөселман хаҗга китте

17 майдан Татарстан хаҗилары хаҗ кылу йолаларын башкару өчен Согуд Гарәбстаны Корольлегенә китә башлады. Иң зур хаҗилар төркеме – барлыгы 365 кеше – хаҗга 26 майда китте. Алар Татарстандагы «ДУМ РТ Хаҗ» рәсми хаҗ операторы аша «Комби», «Стандарт», «Комфорт», «Вип» программалары буенча сәфәр кылды.

2025 елда республикадан барлыгы 1800 кеше хаҗ кыла. Хаҗ кылучыларны фикһ – йолаларны үтәү кагыйдәләрен, гарәп һәм татар телләрен, Согуд Гарәбстаны Корольлеге кануннарын белгән тәҗрибәле җитәкчеләр озата барды. Моннан тыш, һәрбер төркемгә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан җибәрелгән 20 табиб беркетелде. Һәр кунакханәдә оештырылган медицина пунктлары тәүлек әйләнәсе эшләде.

## Мөфти Диния нәзарәтендә БИАның визит-профессорлары докторлар әл-Ләххәм һәм Сафти белән очрашты

Диния нәзарәтендә дәрәҗәле кунаклар – БИАның визит-профессорлары: ислам фәннәре докторы, Димәшкъ университетының Коръән һәм хәдисләр кафедрасы доценты Бәдигъ әс-Сәйид әл-Ләххәм һәм педагогика фәннәре докторы, «Әл-Әзһәр» университетын тәмамлаучылар Лигасы каршындагы Мәгариф һәм фән департаменты җитәкчесе, Ислам хокукы һәм дин тәгълиматы буенча белгеч, Мисыр галиме Хәмделла Сафти – булып китте. Монда аларны Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин каршы алды.

Камил хәзрәт кунакларга Диния нәзарәтенең һәм Россия мөселманнарының исламны үстерү өлкәсендәге соңгы казанышлары турында сөйләде. Ул шәехләрнең

игътибарын кульъязма Коръән әзерләү эшчәнлегенә җәлеп итте. Галимнәр кульъязма мосхафның язылыш дәрәҗәсен югары бәяләде.

## «Зәкят» фонды Корбан бәйрәме һәм Балаларны яклау көненә аз керемле гаиләләрдәге укучыларга һәм ятимнәргә ноутбуклар бүләк итте

Зөлхиҗҗә аеның 3 нче көнендә (30 май), Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды урта һәм өлкән сыйныф укучыларына 10 ноутбук бүләк итте. Балалар барысы да күпбалалы, аз керемле, тулы булмаган гаиләләрдән, ятимнәр дә бар. Ноутбукларда өстәмә рәвештә мәктәптә белем алу өчен кирәкле программалар да урнаштырдылар. Акция Корбан бәйрәменә, шулай ук 1 июньдә билгеләп үтелә торган Халыкара балаларны яклау көненә багышланды.